1926–1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН
№ 7 / 2022

# СӨЕМБИКӘ

ISSN 0869-1398

«Килен төшә бүген авылга...» ҖЫР ТАРИХЫ

АЛАР АЕРЫЛЫША миңа нишләргә?

балалар безгә БУРЫЧЛЫМЫ?! фикер

## Әнже ШӘЙХЕТДИНОВА:

«Матурлыктан туа матурлык».

# Әниемнең туй күлмәге...



Әниемнең туй күлмәге...
Сезнең гаиләнең матур
бер ядкаре.
Кадерле кешегезнең
яшьлегеннән бер кайтаваз.
Аның иң бәхетле бер көненең
шаһиты.
Сакланамы ул сездә?
Аны кулга алгач, йөзе балкып
киткән әниегез нәрсәләр искә
төшерә, нинди истәлекләр
сөйли?
Бездә яңа проект: әниегезнең
туй күлмәген киеп көзге
алдында бөтерелгән
мизгелне сурәтләгән
фотосурәтләрегезне көтәбез.
(«Минем кыз чагым син,
кызым!» – дип әйтәдер
әниегез сезгә карап.
Яратып, сөенеп, аз гына
моңсуланып...)
Тагын – аларның туй көненнән
бер мизгел дә көтәбез!

Миңа инде – 18. Әниемнең туй күлмәге тап-таман! Әнә нинди купшы, зәвыклы күлмәк сайлаган әнием яшьлек тантанасына! Туган нигездән килен булып төшәсе йортка кадәр 220 чакрым юлны (35 градус челләдә!) үтеп килгән кәләшне күреп калырга авылның яше-карты җыелган. (Шәһәр кызы – ул вакытта Чаллы шәһәрендә эшләгән чагы – нинди күлмәк сайлаган икән?!) Ә гаилә төзелү турындагы актны тапшыру тантанасы үтәчәк мәдәният йорты тирәсенә тау-тау таш өемнәре китереп аударганнар! Бәхетле яшьләр боларның берсенә дә артык игътибар итмәгән – әнием күлмәк итәген сак кына күтәреп, үкчәле туфлиләренең очына гына басып, горур төстә әтием янәшәсендә атлаган.

Айгөл КАМАЕВА.
Ютазы районы.

Фото: Зилә Мизгерева

*Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!*



© «Сөембикә» 2022





Фото: Анна Арахамия

Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электронное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кульязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.

**Баш мөхәррир**
Л. Н. Маликова

Редколлегия:
Зәлия Ахунова, Ирада Әюпова, Зилә Вәлиева, Гөлүсә Батталова, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Альбина Насыйрова, Алсу Нәбиева, Сәрия Сабурская, Гүзәл Сәгыйтова, Нурия Һашимова, Рафаэль Шәвәлиев.

**Редакциянең гомуми телефоны** 222-09-77

**Баш мөхәррир урынбасары** 222-09-78
Гөлнур Хәсәншина
**Җаваплы сәркатип**
Алсу Шакирова
**Әдәби мөхәррир**
Эльмира Закирова
**Сайт мөхәррире**
Камилә Димөхәммәтова

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.


**Тышлыкта:**
Энҗе Шәйхетдинова
Фото: Анна Арахамия

**Мөхәррирләр**
Чулпан Галиәхмәтова
Сөмбел Гаффарова
Лилия Гәрәева
Фәгыйлә Шакирова
**Верстка**
Резеда Галиуллина
**Корректор**
Фирдәвес Исмәгыйлева
**Фотокорреспондент**
Анна Арахамия
**Гамәли хезмәткәрләр**
Ильмира Сөләйманова
Павел Фадеев

Формат: 225х290 мм
Күләме 64 бит

Басарга кул куелды: 23.06.2022 ел.
Чыгу көне: 29.06.2022 ел.
Заказ О-1906
Тираж 8685

Учредитель:
Акционерное общество «Татмедиа»




ТР «Татмедиа» Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
**www.syuyumbike.ru**
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77

Язылу индексы
ПАП рәсми каталогы буенча:
Татарстанда П2204 (ярты еллык),
П8299 (берьеллык)
Татарстаннан читтә: ПО279

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикэ»
Расч/счет 40702810600020010309
кор/сч 30101810000000000805
в ПАО «АК БАРС» БАНК г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205805
КПП 165802002

16+
















Бер баскыч, ике, өч...

Хан мәчетенең баскычлары Болгарның Кече манарасын хәтерләтә, әмма монда аз гына иркенрәк. Алтмыш сигез, алтмыш тугыз, җитмеш!.. Мәчет манарасына – Кояш, җилләр каршына чыгып басасың да, бер мәлгә вакыт төшенчәсен югалтасың. Уйлар, гасырларны узып, үткәнгә йөгерә... Менгәндер, бу манарага ул да менгәндер! Сөембикә-ханбикә! Халкыбызның йөрәк ярасы... Күз күреме җирдә җәйрәп ятучы Ханкирмәнгә (Касыйм шәһәрен татарлар кайчандыр үзара шулай атаган), тыныч кына агучы Ока елгасына, яшеллеккә күмелгән яр буйларына, үзәннәргә бер генә күз салгандыр да, күңеле белән кабат Казан тарафына борылгандыр...

Без Рязань өлкәсенең иң борынгы шәһәрләренең берсендә – Касыймда. Олуг Мөхәммәд хәрби хәрәкәтләр вакытында бөек кенәз Василийны җиңә. Һәм ул үз җирләренең бер өлешен хан улы Касыймга бирә. Татар ханнары тарихы бу төбәктә шулай башлана... Касыйм ханлыгы белән 229 ел эчендә 14 хан хакимлек иткән. Безнең телдә аларның берсе – патша әмерен үтәп, буйсынмас Сөембикә-ханбикәгә өйләнгән һәм аны Касыйм шәһәренә алып киткән Шаһгали исеме ешрак яңгырый. Әйе, Сөембикәбез соңгы көннәрен үткәргән җир ул Ханкирмән...

Сөембикә-ханбикәгә иң беренче һәйкәлнең нәкъ менә Касыймда куелуы шуңа да гаҗәп түгел. Һәйкәлне ачу тантанасы Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулуны бәйрәм итү кысаларында тормышка ашырылды һәм Касыйм шәһәренең 870 еллыгына багышланды. Һәйкәл – башта тарихчы, җәмәгать эшлеклесе, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитетының беренче рәисе Индус Таһиров, Рязань өлкәсе татар милли-мәдәни мохтарияте рәисе, үзе дә Касыймда туып-үскән Илдар Бикуев, Сөембикә-ханбикә белән бәйле проектлар авторы Әлфия Рәхмәтуллиналарның уенда, хыялында йөргән, аны чынбарлык итү өчен еллар кирәк булган. Изге нияткә ярдәм итүчеләр дә табылган: Россия Федерациясе мөселманнарының Диния нәзарәте матди якны үз өстенә алган.

Һәйкәлне ачу тантанасы Касыйм шәһәре халкы өчен генә түгел, ә бөтен татар дөньясы өчен зур вакыйгага әйләнде. Чарада бик дәрәҗәле кунаклар – Россия Федерациясе мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти шәех Равил хәзрәт Гайнетдин, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессы Милли Шура рәисе Васил Шәйхразыев, Татарстан Республикасы мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, Россия мөселманнары Диния нәзарәте рәисенең беренче урынбасары, Мәскәү ислам институты ректоры Дамир Мөхетдинов, Россия Дәүләт Думасы депутатлары – Россия Герое Андрей Красов һәм Татар федераль милли-мәдәни автономиясе рәисе Илдар Гыйльметдинов, Россия парламенты Рәисе урынбасары Владимир Васильев, Рязань өлкәсе хөкүмәте рәисенең беренче урынбасары Анна Рослякова, Мәскәү шәһәренең милли сәясәт һәм төбәкара элемтәләр департаменты җитәкчесе урынбасары Константин Блаженов, Касыйм шәһәре башлыгы вазыйфаларын башкаручы Светлана Андреевалар катнашты.

– Кайчандыр Сөембикәгә: «Һәлак булачаксың: исемең онытылачак, синең хакта хәтер дә калмаячак», – дип янаганнар. Бүгенге вакыйга – халыкка тугрылыклы булып, изге гамәлләр кылган кешене беркайчан да догадан калдырмауларына бер дәлил, – диде Равил хәзрәт Гайнетдин һәйкәлне ачар алдыннан.

Ул мең кат хаклы!

Алтын җепләр белән чигелгән ефәк тукыма һәйкәл өстеннән шуып төшә. Сөембикә-ханбикәнең карашы нәкъ менә шундый булгандыр ул: анда – горурлык, тәвәккәллек, зирәклек...

Ханбикәнең кабере кайда икәне билгеле түгел. Шаһгали төрбәсенә күмелгән дигән фараз бар барын. Шулай икән – һәйкәл, димәк, аның янәшәсенә үк куелды. Ә исеме? Сөембикә-ханбикәнең якты исеме еллар узган саен безгә якыная гына!

Фото: Анна Арахамия

# Безнең тышлыкта



«Мәчет һәм чишмә өчен җитәкчеләребезгә бик рәхмәтлемен. Нинди генә сорау һәм үтенеч белән мөрәҗәгать итсәк тә, һәрвакыт ярдәм кулын суздылар, авыл халкы төп таянычым булды.»



10

Рәхмәт сиңа, Энҗе!

Гөлзадә Бәйрәмова

14



Ике генә үкенечем бар...

Алсу Шакирова

20



«Балалар безгә бурычлы түгел»

Чулпан Галиәхмәтова

22



Түкле аягың белән!

Лилия Гәрәева

ЭЧТӘЛЕК


## Заман һәм без

«Алар аерылыша, ә миңа нишләргә?..» 6
Чулпан Галиәхмәтова

Адымнар 16
Чулпан Галиәхмәтова

## Татар дөньясы

Туймазыда җырладык әле! 25

Мәхәббәтле оя 26
Эльмира, Сәвия, Алинә Садриевалар

Гаилә 29
Марат Кәбиров

## Мәдәни тормыш

«Киек казлар юлы буйлап очам...» 30
Халидә Гыйләҗева

Бәби исе 32
Миләүшә Каһарманова

## Яшәеш

Хатлар 38

57 кәҗә, 40 сыер һәм Альмира 40
Лилия Гәрәева

Кызлар яза... 43

Мәрьям әни 44
Мәдинә Авзалова

Чүлдәге әкият дөньясы 52
Әлфия Самат

## Хуҗабикә

Яшь әни: сорау—җавап 56

Глютенсыз диета кемгә файдалы? 58

Битне чәбәкләп яшәртәбез 59

Өйнең яме — гөлләрдә 62

46



Үләнче
Гөлнур Сафиуллина

50



Килен төшә бүген авылга
Эльмира Закирова

60



Курник
Эльмира Камалиева тәкъдим итә






Фото: www.freepik.com

# «АЛАР АЕРЫЛЫША, Ә МИҢА НИШЛӘРГӘ?..»



Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА

**Өлкәннәр өчен аерылышу – драматик кичерешләр тулы авыр процесс, әмма алар аңа үз теләкләре белән, тормышларын яхшы якка үзгәртү өчен бара. Ә балалар өчен ул – күнегелгән яшәү мохите җимерелүгә китергән фаҗига. Әни кешенең «әтиең безнең белән башка яшәми», дип әйтүен бала күп вакыт аңлап һәм кабул итеп тә бетерми. Җитмәсә, ике арадагы тарткалашуда үзен куллана башларга мөмкиннәр. Зурлар мәнфәгатьләрен кайгыртканда ул кайчак шахмат тактасындагы пешкага әйләнә дә кала.**

### *Соры балачак*

«Кечкенә чагым бик бәхетле узды. Әти-әнием белән бергәләп уздырган рәхәт мизгелләр әле дә йөрәк түремдә саклана. Ул чакта чынлап та бала идем, әмма гаиләбездә башланган аңлашылмаучылыклар мине үзгәртте. Безнең гаилә болай да бик эмоциональ иде. Әмма низаг еш чыга башлагач, моның дөрес хәл түгеллеген чамаладым, – дип сөйли Динә моннан 16 ел элек әтисе белән әнисенең аерылышуы турында. – Аларның суд юлында йөрүләрен белмәдем. Без әтидән киткәндә миңа 10 яшь тирәсе булгандыр. Менә ул чакларны ныклап хәтерләмим дә, хәтер тормыштагы авыр вакытларны «онытырга» тырыша бит ул. Гаиләдә бертуктаусыз кабатланып торган низаглар мине иртә үсәргә мәҗбүр итте. Югыйсә бала-чага уйнарга, мәктәп дөньясында гына кайнарга тиеш бит. Ә мин әти-әниемнең хәле өчен борчылдым. Ачулары килгәндә яннарына бармадым. Өйдәгеләрнең кәефен «укырга» бик иртә өйрәндем һәм аларга ярарга тырыштым. Мин белгән матур дөньяның җимерелүен аңлаганмындыр, мөгаен, өлкәннәрдән ерагаеп, үземә бикләндем. Ялгызлык халәте әти белән әни аерылышкач та бетмәде, киресенчә, тагын да көчәйде. Әни энем белән икебезне ялгызы гына үстерде, шуңа күрә көне-төне эштә булды, ә әти ярдәм итми иде. Әнигә авыр булганын, аның алҗыганын аңлый идем, шуңа аңа бик сырпаланасым килсә дә, янына бармадым. Ул миңа җитми иде. Мин болай да бик тыныч бала идем, әнигә борчу тудырмас өчен, «уңайлы» балага әйләндем. Үсмер чагымда сатып алырга теләгән әйберләр булса да, әнидән акча сорамаска тырыштым, үз хәлләрем турында сөйләп аны йөдәтмәдем. Балачагымның ул чоры соры, салкын булып истә калган. Әйтерсең ялгызым гына яшәгәнмен. Ялгызлык хисе көчле булган инде миндә. Әтинең мине яратуын белсәм дә, артык якын түгел идек, ә аерылышкач, аннан тагын да ерагайдым – аралашмадым. Аңа карата үпкәм зур иде, аерылышкан өчен генә түгел, башка сәбәпләр дә булды.



**Психолог-медиатор, «Доверие-Ышаныч» балаларга һәм яшьләргә психологик-педагогик ярдәм күрсәтү үзәгенең «Ювента» бүлеге җитәкчесе Маргарита ПОГОРОДОВА: «Аерылышкач, дус булып калган ата белән ана – бала өчен иң идеаль вариант».**

Йөргән егетем белән араларыбыз өзелгәч, гаепнең үземдә икәнен аңлап, психологка мөрәҗәгать иттем. Чынлап та, балачактагы кичерешләр тәэсир итми калмый икән. Психолог белән биш ел эшләү дәверендә күп нәрсәне аңладым. Миңа әти белән әнинең яратуы җитмәгән икән. Боларның барысын да психолог белән төрле алымнар ярдәмендә күңелемнән чыгардым. Хәзер инде мөнәсәбәтләребез яхшы, әти белән дә аралаша башладым. Ә бу бик мөһим! Психологлар әйтүенчә, әтигә үпкә бар икән, ир-атлар белән мөнәсәбәтләр кору авыр. Гаиләдә әти белән әнинең начар яшәве, аерылышуы, балаларны иртә үстерә. Ә бу бала күңеле өчен бик начар. Һәрнәрсәнең үз вакыты булырга тиеш. Шәфталу да, утыртып, ун көн үтүгә җимеш бирми. Кеше дә шулай. Аңа өлгерергә вакыт кирәк. Кискен үзгәрешләр яхшылыкка илтми ул. Һәм тагын бер әйбер: гаилә корып, балалар тапканчы, рухи яктан үсәргә кирәк. Кызганыч, безнең җәмгыятьтә үсми калган өлкәннәр бик күп. 50 яшьлек кешеләрнең хәл ителмәгән рухи проблемалары бар икән, бу инде өлгермәгәнлек турында сөйли. Шуңа гаилә корганчы, иң элек үзегезнең рухи халәтегезне кайгыртыгыз. Моңа җитди карарга кирәк, югыйсә корган гаиләгез таркалырга мөмкин...»

Балачагы Динәнеке кебек булганнар, кызганыч, безнең җәмгыятьтә бик еш очрый. Республикада аерылышучылар саны кимеми. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсеннән алынган мәгълүматларга күз салсак, узган ел 14876 гаилә таркалган. 2020 ел белән чагыштырганда, 31,1 процентка артык бу. Моны идарәдә ике ел элек пандемия сәбәпле, ЗАГС органнарының эше чикләнү белән бәйләп аңлаттылар. Шунысы да бар – икенче ел инде балалы гаиләләрнең аерылышу саны кими икән. 2019 елда 11628 булса, узган ел – 9585. Аерылышкан күпчелек гаиләләрдә икешәр бала, диләр идарәдә. Шул рәвешле, статистика буенча, узган ел 14215 сабый күнегелгән яшәү рәвешен үзгәрткән. Ә күпмесе психологик зыян күргән – монысы билгесез. Баланың психик халәтенә генә түгел, сәламәтлегенә дә зыян килергә мөмкин.

Кызымның иптәш кызы бик яхшы гаиләдән иде. Әти-әниләре тәрбияле, очрашкан саен матур итеп сөйләшәләр, хәтта ата-аналар җыелышына да бергә йөриләр. Берзаман Алисә (баланың исеме үзгәртелде – *Ч. Г.*) мәктәпкә җыйнаксыз килә башлады. Чәчләре таралмый, һәрвакыт чиста, зәвык белән киенеп йөргән баланың өсте-башы да үзгәрде. Ерактан ук елмаеп сәлам биргән бала исәнләшми дә, аска карап кына йөри. Кызым белән дә аралары бозылды. Баланы таныш түгел бер апа йөртте. Кызым Алисәнең начар билгеләр ала башлавын, укытучыга каршы эндәшүен дә сөйләштерде. Әнисе мәктәптә күренмәде. Беркөнне ул хатын миңа шалтыратты. «Кызымның хәле ничек икән, бүтән түзәр чамам калмады. Аның өчен бик борчылам», –





Балаларга һәрвакыт көчле **ата-аналар кирәк.**

дип сүз башлады ул. Баксаң, гаилә таркалган икән. Баланың әтисе финанс ягыннан бай кеше: һаман кыйммәтле уенчыклар алып, баланы үз ягына аударган, әнисенә каршы котырткан. «Миңа каршы эндәшә башлагач, бар, әтиеңә барып яшә, дип, баланы үзем элекке иремә тоттырдым. Хәзер йөрәгем яна. Аңа анда бик кыен икәнен уртак танышларыбыз ишеттереп тора. Көндәлек тормышта әтисе бик салкын, кырыс кеше. Кычкырып җибәрергә дә күп сорамый иде. Хәзер миннән аласы үчне баладан ала, ахрысы. Суд аша хәл ителгән: миңа бала янына якын килергә дә ярамый», – диде ул. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкиллек юлын таптап, баланы кире әнисенә кайтару турында язып тору озынга китәр, мөгаен. Әмма Алисә әнисенә кайтканда тотлыга һәм төнлә астын юешли башлаган иде. Әнисе аны бик озак психологка йөртте.

### *Әти-әниләр көчсезлеге*

Әти белән әни түгел, ир белән хатын аерылыша, дисәләр дә, ул балаларга тәэсир итми калмый. Аерылышуны 5–7 яшьлекләр, бигрәк тә малайлар, ә 2–5 яшьлек кызлар әтисенең китүен авыр кичерә икән. Гаиләсе таркалган балаларны тикшергәннән соң, социологлар менә шундый нәтиҗә ясаганнар: 37,7 процент бала укуда өлгерә алмый башлый, 19,6 процентына өйдә дисциплина җитми, 17,4 проценты аерым игътибар таләп итә, 8,7 проценты өйдән чыгып кача, 6,5 процент баланың дуслары белән конфликтлар туа. Дөрес, кайбер психологлар баланың шәхесе формалашуда шартлар яхшырса, ата-ананың аерылышуы яхшыга гына дип саный, чөнки гаиләдәге низаг баланың психикасына начар йогынты ясаудан туктый. Әмма күп очракта гаилә таркалу бала күңелен яраламый калмый. Бигрәк тә ул бала бердәнбер булса. Апалы-энеләләр бу борчулы хәлне җиңелрәк кичерә икән. Агрессияләрен, борчылуларын бер-берсенә чыгарып, алар эмоциональ киеренкелекне киметә.

«Балаларга кагылышлы бер сер бар: әти белән әни ачуланышканда балалар һәрвакыт үзләрен гаепли, хәтта үсмер чагында да. Мин начар, шуңа әти белән әни кычкырыша дип уйлый. Бала бу вакытта да әтиәнисен яратудан туктамый, ә менә үзен яратмый башлый», – ди психолог-медиатор, «Доверие – Ышаныч» балаларга һәм яшьләргә психологик-педагогик ярдәм күрсәтү үзәгенең «Ювента» бүлеге җитәкчесе Маргарита Подгородова.

Ир белән хатын арасында низаг еш була башласа, нәрсә эшләргә кирәк соң? Ата-ана иң элек шуны онытмасын иде: алар баланың психологик халәте, сәламәтлеге һәм юридик куркынысызлыгы өчен җаваплы. Бу гаилә кодексында да язылган. Балада нинди психологик процесслар булуын аңларга, җаваплылыкны балалар җилкәсенә салмаска, өлкән кеше позициясендә кала белергә өйрәнергә кирәк. Бигрәк тә гаилә таркалганда. «Ата-ана аерылышканда балалар читтә калырга тиеш түгел. Аларга барысын да аңлатырга кирәк», – ди психолог. Әмма төрле гаиләләр өчен киңәшләр дә төрле. Шуңа күрә без психолог белән гаиләләрне социаль яктан яхшы һәм начарга бүлеп карадык.

– Башкалар өчен үрнәк булган гаиләләр дә, тирә-яктагыларны шаккаттырып, кайчак суд юлын таптый башлый, – ди Маргарита Подгородова. – Аерылышкач, дус булып калган ата белән ана – бала өчен иң идеаль вариант. Әмма андыйлар бик сирәк. Әлбәттә, конфликт чыгуга, барып гариза язу дөрес түгел. Утырып сөйләшергә, чын күңелдән ireңне яки хатыныңны аңларга тырышып карарга кирәк. Үзара гына хәл итә алмыйсыз икән, психологик үзәкләрдә эшләүче медиаторларга мөрәҗәгать итәргә мөмкин. Безнең хезмәткәрләр ЗАГС бүлекләрендә дә утыра. Алар – арадашчы ролен үтәүчеләр. Әгәр дә инде эш аерылышуга барып җитә икән, һич тә баланы ике арада арадашчы итмәгез. Аңлагыз, бу аның психологик сәламәтлеге өчен бик начар. Балаларга кагылышлы тагын бер сер: аларга һәрвакыт көчле ата-аналар кирәк. Иң элек ул рухи яктан нык булсын. Мәсәлән, кечкенә бала уенчык алмаган өчен кибет идәненә тәгәрәп елый башлый. Елый, ә үзе өлкәннәрнең аны кысаларга кертүен, әнисенең аңлатуын көтә. Бунтарь үсмер дә әти-әнисенең көчле булуын тели. Өлкәннәр көчсезлеген күрсәтсә, бала чама хисен югалта башлый. Шуңа күрә дә аерылышкач, никадәр генә авыр булса да, бала күз алдында көчле булып калу зарур. Бервакытта да иргә булган үпкәләрне балаларга сөйләргә ярамый. Бала хисабыннан үз-үзеңне расларга тырышу бу!

### *Белгеч киңәше*

**Балаларга авыр икәнен ничек белергә?**

Ата-ана аерылышканчы гаиләдә ышанычлы мөнәсәбәтләр булмаган икән, бу хәл генә ситуацияне үзгәртә алмый. Бала үзе ачылып китеп сөйләшә башлар дип көтмәгез дә. Киресенчә, ул үзенә тагын да бикләнәчәк. Еш авырый, тәмәке тарта башларга мөмкин. Законга каршы килердәй гамәлләр кылу куркынычы да бар. Юк, ул карак булганлыктан урлашмаячак, бу адымга бары игътибар җәлеп итәргә теләп кенә барачак. Мондый баланы «урам малайлары» бик тиз эләктереп ала. Шуңа күрә ышаныч – гаиләнең нигезе ул. Әти-әнисе аерылышуын үтә дә тыныч кабул итүче бала да шик тудырырга тиеш. Бу очракта аны мәктәп психологына булса да алып барып сөйләштерергә кирәк.
Чит кешегә бала яхшырак ачыла. Әлеге проблеманы вакытында хәл итмәү киләчәктә хәтта баланың үз-үзенә кул салуына да китерергә мөмкин.

### *Бала кемгә?*

«Без бергә яшәмибез», – дип, баланы факт алдына гына кую дөрес түгел», – ди психолог. Чөнки бала бу сүзләрне аңлап һәм кабул итеп бетермәячәк. Шуңа күрә ул аңларлык яшьтә икән (2-3 яшьлек сабый әле барысын да аңлап бетерми, аның белән сөйләшү алай мөһим түгел), аның белән өчәүләп утырып сөйләшү зарур. «Син кем белән яшәргә телисең?» – дип, аның теләген сорау да комачау итмәс. Дөрес, балага 10 яшь тулгач кына суд аның фикерен сорый. Әмма Казан шәһәре Совет районы хакимиятенең опека һәм попечительлек бүлеге җитәкчесе Ирина Смирнова: «Хәзер 6-7 яшьлек балалар да кем белән яшисе килүен анык кына әйтә ала. Бу тенденцияне аңларга һәм кабул итәргә кирәк», – дип белдерде. «Баланы эти кеше белән аралашудан тыярга ярамый. Аерылышкан ир белән хатын арасында дошманлык юк икән, ике арада йөреп бала бозылмый», – ди психолог.

Балалар булган гаиләләрдә аерылышу күп очракта үпкәләү, рәнҗүгә кайтып кала. Гаилә таркалуга китергән төп сәбәпләр – хыянәт, эчкечелек, наркомания йә ирнең гаилә өчен җаваплылык тоймавы. Мондый хәлдә, билгеле, балалар әни белән кала. Әмма тормышта баланың әнигә дә кирәк булмаган очраклар бар. Бу инде бала өчен иң куркынычы. «Минем эш практикасында шундый гаилә бар иде. Ирнең башка гаиләсендә баласы бар, әни кеше үз тормышы белән мәшгуль. Балалар аның өчен авыр бер йөк. Балаларны иренә тагасы килә, иренең – аңа. Моны сабыйлар сизми калмый. Берсе үтә дә хәлсез, икенчесе төнлә астын юешләтә, кечкенәсе, бәхетенә, аңламый иде. Алар аңлашырга дип безгә медитациягә килде. Әмма сөйләшү барып чыкмады, минем каршыда тавыш чыгардылар. Медитацияне өзәргә туры килде. Ул балаларның язмышы турында берни белмибез. Безнең андый административ ресурсларыбыз юк. Әмма ул балалар искә төшкән саен үзәгем өзелеп куя. Минем эш дәверемдә баласы әнисенә кирәкмәгән ике генә очрак булды», – ди Маргарита Подгородова.

Әти-әнисе аерылышкан балаларга туганнары да ярдәмгә килә ала. Бу очракта алар көчле ата-ана ролен үтәүчеләр була. Мәсәлән, шул ук әби белән бабай. Тулысынча дөрес күренеш түгел, әмма бер чара булып тора.

Социаль яктан начар яшәгән деструктив гаиләләрне дә аерылышканда кануннар гына коткарып кала ала. Чөнки бер ата-ана адекват түгел икән, сөйләшү, аңлашырга тырышу – мәгънәсез. Бигрәк тә гаиләдә эчкече, психик авыру йә көч кулланучы булса. Тиран ирләр белән яшәүче хатыннар да бар бит әле. Алар үзләре генә интекми, балаларын да интектерә. Абьюзерларның мантыйклары башка төрлерәк, шуңа алар үзләрен һәрвакыт хаклы дип саный. Монда психолог түгел, психиатр кирәк инде. Чөнки бу кешеләр психолог киңәшләреннән кычкырып көләчәк кенә, йә, гомумән, белгечкә барып тормаячак. Бу гаиләләргә якыннары гына ярдәм итә ала. Вакытында полициягә хәбәр итеп, бу ирдән хатынын йолып алырга мөмкиннәр. Мондый әниләргә үзен һәм баласын закон алымнары белән якларга кирәк.

Әти-әни аңлашу тапмаганда балага мәктәп психологлары, спорт тренерлары ярдәм итә ала. Аларда балаларга карата битарафлык булырга тиеш түгел. Ни генә дисәк тә, мәктәп – белем бирү белән бергә тәрбия учагы да әле ул. Һәм рейтинг артыннан куганда бу онытылмасын иде.

Аерылышуның кайсы да балаларның психологик халәтенә зыян сала. Шуңа күрә бу хакта сөйләшер алдыннан балага авырлык китермимме, бу яшьтә булсам, мин нинди хисләр кичерер идем икән, дип, үзеңне аның урынына куеп карарга кирәк. Әти-әниегезнең ничек итеп сөйләшүен, нинди сүзләр белән юатуын теләр идегез? Шул сүзләрне балаларыгызга әйтегез. Гомумән, балалар тулы гаиләдә үссен иде. Ә моның өчен гаилә корганда кызның да, егетнең дә рухи яктан әзерлекле булуы зарур. Гаилә төзү уен эш түгел ул. Нигезе яхшы булганда гына йорт ныклы була. Онытмагыз: ул йортта балаларыгызның яшисе бар.



**Әмир МАМИН, «Татарстан Республикасы әтиләр союзы» оешмасы рәисе урынбасары**

Адель Заһретдинов төзегән оешмабызны патриархаль берлек дип кабул итү дөрес булмас. Әтигә дә, әнигә дә бертигез карыйбыз. Республикабызда традицион гаилә мөнәсәбәтләре популяр булса да, аерылышулар күрсәткече зур. Бу процесста балалар белән манипуляция ясаган ата-аналар да, кызганыч, аз түгел. Яшәү дәверендә тупланган малны бүлүдә ир белән хатын кайчак балаларны куллана башлый. Бездә булган мәгълүматларга караганда, ел саен мондый балалар «армия»сенә 4 мең тирәсе кеше өстәлә. Бу – бигрәк тә зур шәһәрләр, җиде ел яшәп аерылышканнар проблемасы. Безнең җәмгыятьтә гаилә таркалгач, бик сирәк очракта гына бала әтисе белән кала.
Без бик яхшы аңлыйбыз: бала билгеле бер яшькә кадәр әни тәрбиясендә булырга тиеш. Баланы әти тәрбияләргә тиеш дигән ир-атлар белән килешмибез, әмма баланы әтисе белән аралаштырмаган хатын-кызлар да дөрес эшләми. Аларның моңа әхлакый да, юридик та хокуклары юк. Бу күренешне баланың психикасын көчләү дип кабул итәбез. Әлеге проблема белән безгә бик еш мөрәҗәгать итәләр. Мессенджердагы махсус чатыбызда баласын күрергә зар булган өч йөз ата бар. Алар төрле социаль статуста. Араларында таксист та, депутат та, полиция хезмәткәре дә бар. Иң элек алар белән утырып сөйләшәбез. Ике ир-атның сөйләшүе, гадәттә, нәтиҗәлерәк. Җитмәсә, безнең оешмада бу эш белән үзләре шушы ситуациядә калып, аны уңай хәл иткән аталар шөгыльләнә. Безгә килгән әтиләр белән бала мәнфәгатьләрен кайгырткан төрле дәүләт структураларына мөрәҗәгать итәбез. Бу – аерым очраклар. Ә гомумән алып карасак, аерылышканнан соң бала бүлешү, аны ата белән аралаштырмау республиканың демографик вазгыятенә дә йогынты ясамый калмый. Оешмабыз булачак әтиләрне дә берләштерә. 25 яшьлек егетләр белән гаилә кору турында сөйләшкәндә, еш кына бу адымны ясарга ашыкмаулары турында әйтәләр. Аралашу барышында аңлашыла: кечкенә чакларында гаиләләре таркалган булган. Бу алар күңеленә яра салган. Әти-әниләре аерылышып, тулы булмаган гаиләдә үскәннәрнең 90 процентының гаиләсен киләчәктә шул язмыш көтә, ди психологлар.




# РӘХМӘТ СИҢА, ӘНҖЕ!

Динебездә: «Аллаһка ышанып һәм рәхмәтенә исәп тотып берәү ташландык җирне тергезсә, аның Аллаһ ярдәмен һәм ризалыгын алырга хакы бар», – диелгән. Күңеле матурлык белән тулы героебыз да – башкаларны кайгыртып, игелекле эш-гамәлләр кылып, тирә-юнендәгеләрне сөендереп, күңеленә рәхәтлек ала торган кешеләрдән.



Гөлзадә
БӘЙРӘМОВА



Ага чишмә челтер, челтер... Җырдагыча, үз көенә акрын гына ага. Гүя: «Минем ашыгыр җирем юк, мин бик озак еллар агам инде, әле тагын да озак, күп еллар агасым бар» дигән сыман талгын гына агып ятуын белә. Бер тауда ун чишмә түгел, бердәнбер чишмә. Шуңа да кадерле, якын ул авыл кешеләренә. Табигатьнең сихри матурлыгы әнә шулай чишмә җыры, әрем-тузганакларның җилдә акрын гына тирбәлүе, бал кортлары-шөпшәләрнең үз көйләренә безелдәп очулары, әтисенең туган авылы турында илһамланып сөйләве аша үтеп керә сабый күңеленә.

«Безнең авыл бик борынгы, кызым. Авыл аксакалы Сиражетдин бабаң сөйләвенчә, атамасының кайдан килеп чыкканын да төгәл генә белүче юк. Әллә урман якын булып, анда сәрдә үләне бик күп үскәнгә Сәрдә дип атадылар микән? Башта ул Елга буе Сәрдәсе дип аталган. Зиратта 1400 елгы кабер ташы булудан чыгып, авылга XIV гасыр урталарында ук нигез салынган дип әйтүчеләр дә бар. Мәскәүдән Екатеринбургкача сузылган олы юл авыл эченнән узган. Әби патша аны заводлар карарга барыр өчен салдырган, диләр. Ул сәүдә юлы булып та хезмәт иткән. Киң итеп салынганлыктан, алты ат йөге төялгән арбалар янәшә уза алган, Казан сәүдәгәрләре шушы юл аша Екатеринбург, Ырынбур, Уфа базарларына, Эрбет ярминкәсенә барганнар. Хәтта Әби патша үзе дә моннан узгалаган дип сөйлиләр. Дәүләт карамагындагы юлны кантон, волость урядниклары гел төзекләндереп торган. Авылда бае да, ярлысы да бар иде. Билгеле, илгә килгән бәла-казалар – ачлыгы-корылыгы, төрле үләт чирләре, янгыннар, сугыш афәтләре, дингә каршы көрәшүләр, ятимлекләр – безнең авылны да читләтеп үтмәгән. Сугышка киткән 100 ир-атның 50 се кире әйләнеп кайтмады. Авылның алма бакчасы, су буендагы яшелчә бакчасы әкияти бер матурлык булып әле дә төшкә керә... И-и кызым! Ничек тә мәчеткә манара куеп, чишмә буйларын матурлап, умарталыкны торгызып, авылга элеккеге төсен кайтарып калдырасы иде бит...»

Әтисе сөйләгәннәр, туган авыл тарихы, аның белән бәйле хис-кичерешләр үсмер кызның күңелендә шигырь булып бөреләнә, мәкалә-язма булып кәгазь битләренә төшә, һәм алар район газетасында бер-бер артлы басыла башлый. Туган як табигатенең казылма байлыкларга бай туфрак серен ачасы килү теләге аңа – химиядән, туган ягы тарихы белән кызыксынулары – тарихтан төрле олимпиадаларда катнашырга юл ача. Энҗе, республика күләмендә беренче урыннарны яулап, үзенең фәннәр белән шөгыльләнергә сәләтле икәнен раслый. Саба урта мәктәбен алтын медальгә тәмамлаган Энҗе Галимованы һәр укытучы үз фәне буенча күрергә тели. Әдәбият укытучысы – журналист, химия укытучысы белән авыру әтисе – медицина юлыннан китәр дип өметләнеп торганда, бөтен кешене шаккаттырып, авыл балаларына хас булмаганча, Казан дәүләт университетенең фәнни коммунизм бүлегенә укырга кереп кайта ул. «Алда коммунизм кыры күренә» кебек эчтәлектәге шигырь-җырларга табынып үскән, марксизм-ленинизм тәгълиматларын шигарь итеп йөргән буын чоры шул бу... Тормышның – тотрыклы, җәмгыятьнең матди байлыкларны төп яшәү чыганагы итеп карамаган чоры... Һәм ул шул бер эздән, бер салган юлдан барыр да барыр кебек иде. Җәмгыятьнеке дә, анда яшәгән кешеләрнеке дә... Белем-һөнәр алу, яраткан эшең булу, гаилә кору – бәхетле тормышның нигезе! Энҗенең тормыш юлы да башкаларныкы кебек үк: укуын тәмамлагач кияүгә чыга, бер-бер артлы ике малай туа, фатир да, машина да алына, вак-төяк мәшәкатьләр чыгып торса да, аларны хәл итү булдыклы, эшлекле гаилә хуҗасы – ире Данил җаваплылыгында. Ә ул исә ир канаты астында, ир җилкәсе ышыгында бәхетле яшәүче хатын-кыз, балаларының әнисе. Мәңге шулай булыр кебек иде бит югыйсә... Тәкъдир-язмышка башкачарак: без алдан күрә, тоя, укый алмый торган юллар да язылган була шул кайчак... Үлем белән бәйле булганы – үзәкне иң нык өзгәне, тормышның астын өскә китергәне. Әле кичә генә, әле берничә сәгать элек кенә барысы да шат, бәхетле иде... Гаиләләре белән килергә яраткан шәһәр читендәге бакча да шау чәчәктә, күңел дә ачык, якты төсләрдән балкып тора иде. Кисәк килеп чыккан авыру, ялны өзеп, гаиләне тиз генә шәһәргә җыендыра. Бер кулы белән рульне әйләндергән, икенче кулы белән юл буе эчен тотып кайткан Данил больница капкасы төбенә килеп җитүгә аңын югалта. 43 көнгә сузылган реанимация, һәм шул йомудан соң инде күзләрен башка ачмый Данил...

Ирен җирләп кайтканнан соң, уллары Эльмир белән Илфирга карап, Энҗенең күңелендә ике генә сорау туа: алга таба ничек яшәргә һәм кайдан башларга? Кайгың да, ялгызлыгың да, ятимлегең дә – ул бары синеке генә. «Бүгеннән син ireң җилкәсенә ышыкланып, машинада аның янәшәсендә генә утырып йөргән хатын түгелсең, Энҗе. Малайларыңа ата да, ана да булырга, тормыш рулен дә, машинаныкын да үзең әйләндерергә, үзең алып барырга тиешсең», – ди ул үз-үзенә һәм эшне машина йөртергә өйрәнүдән, права алудан башлый. Ярый әле булган белеме өстенә читтән торып юридик-финанс белеме дә алган ул! Шуңа сөенеп бетә алмый, банк системасына эшкә урнаша. Вакытының бер генә минутын да заяга уздырырга гадәтләнмәгән Энҗе көндезләрен банкта – төп эшендә эшләсә, төннәрен үз машинасы белән такси ролен үтәп, кешеләр дә ташый ул. Бер генә ай да, бер генә ел да түгел – биш ел! Ялгызлыкны, бушлыкны, юклыкны эш белән тулыландыра шулай. Нинди генә язмышлар, гыйбрәтле хәлләр ишетергә туры килми аңа бу чорда. Үзенекен башкалар сөйләгәннәр белән чагыштырып карый-карый яшәргә өйрәнә. Малайларның яшүсмер вакытта була торган проблемалары да, авыру-сырхаулар да – берсе дә аны да читләтеп үтми. Бер-бер артлы туып торган мәшәкатьләрдән чыгу юлын таба ала торган, кирәксә – Германиясенә дә, Израиленә дә барып кайтырлык тәвәккәллеккә ия ханым булып өлгерә. «Бар да үтә... Монысы да үтәр» дигән гыйбарә аның күңел түренә кереп урнаша.

Баш очында түбәсе, эшли торган эше булганга сөенеп, улларының киләчәктә ныклы терәк булырына өметләнеп, көннәргә – айлар, айларга еллар ялгана бара. Гомереңең кыл уртасында балкып янган шәме сүнгәннән соң хисләр инде кабат яңармас, яна алмас тоелса да, хатын-кызның

Фото: Анна Арахамия

# Авылга нур иңә, намаз укырга, дини белем алырга – Коръән укырга өйрәнергә теләүчеләр күренә башлый.



Улы Илфир мәчет ачылышында чыгыш ясый. 2018 ел.



җиде шәме булыр, берсе янмаса икенчесе янар, диләр... Аллаһ алучы да, бирүче дә: Даниле сыман аларны кайгыртучы, кешелекле, иң мөһиме – Энҗене чын күңелдән яратучы берәү табыла бит бу дөньяда! Бер як чишмә суларын эчеп, бер якның болын-тугайлары, урман-кырлары матурлыгын күреп, тоеп үскән Илфар Яхинны пар итә. Икесенең дә югалту ачысын тоеп, парлы гомернең һәр минутының кадерен белергә кирәген аңлап яшәр чактагы кавышу була бу. «Ике тол кавышкан төнне мендәрдә дүрт баш ятар» дисәләр дә, уйлар – бер, максатлар уртак. Энҗе әтисе белән ничек итеп чишмә буйларын чистартканын, анда умарталыклар булдырырга ниятләүләрен, балачак хыялын тормышка ашырырга теләвен акрынлап Илфарга сөйли. Илфар исә һәммәсен күңеленә сала бара: план-проект төзи, чишмәнең бурасын, басма-күперне кайтарту эшләрен белешә башлый. Тик аңарчы сазлыкка әйләнеп, чытырман-куаклар баскан тау итәген рәткә китерәсе, чистартасы – ташландык җиргә җан өрәсе, яшәртәсе бар! Табигать тә үзен зурлаганны, үзенә сак караганны ярата. Бу эшләргә җәй җиткәч, көннәр җылыткач тотынырга ниятләп йөргән көннәрендә инде үсеп җитеп, бизнеска кереп китеп шактый гына уңышларга ирешкән улы Илфир әтисенең туган авылында әтисе Данил исемендәге мәчет булдырырга теләге барлыгын белдерә. Бергәләшеп уйлаша торгач, үзләре гел кайтып йөргән Сәрдәдә, Энҗенең туган авылында ачарга уйлыйлар ул мәчетне. Җитәкчелек белән киңәшеп, кәгазь эшләрен җайлаштырып бетергәннән соң, төп эшне оештырырга авылның үз кешеләре Рөстәм Газизҗанов һәм Рәис Сабирҗанов алына. Авыл яшьләре белән өмә ясап мәчет төзелешен төгәлләп чыгалар. Озак та үтми, ничәмә-ничә еллар ишетелми торганнан соң, авыл өстендә беренче азан тавышы яңгырый, Саба районы Сәрдә авылында Шәйхетдинов Данил Фәрит улы истәлегенә улларының матди ярдәме белән «Данил мәчете» калка, аның ачылышында бөтен авыл катнаша. Өлкәнрәкләрнең күзендә яшь бөртекләре, чит җирләргә киткән авылдашлар да сөенеп кайткан, хәл кадәри кемдер нидер бүләк итә, район җитәкчеләре Энҗегә, аның гаиләсенә бөтен авыл халкы исеменнән рәхмәт белдерә. Авылга нур иңә, намаз укырга, дини белем алырга – Коръән укырга өйрәнергә теләүчеләр күренә башлый.

Билгеле, бөтен эш тә җирле җитәкчеләр белән килешенеп, киңәшләшеп башкарыла. «Мәчет һәм чишмә өчен җитәкчебез Зарипов Алмаз Зөфәр улына бик рәхмәтлемен. Нинди генә сорау һәм үтенеч белән мөрәҗәгать итсәк тә, һәрвакыт ярдәм кулын сузды, авыл халкы төп таянычым булды», – дип искә ала Энҗе. Үзләрен Аллаһ йорты – мәчет белән куандырган Энҗенең, аның гаиләсенең чишмәне яңарту, төзекләндерү, гомумән, авылны ямьләндерү ниятенә дә авыл халкы теләп кушыла, чөнки беләләр: Энҗе алынган икән – ул эш ярым-йорты гына үтәлмәячәк, ул үзе башлап йөри икән – читтә калып булмаячак. Иң элек өмә ясап, иске талларны кисеп, чишмә буен корыган агачлардан арындыралар. Сәрдә чишмәсе буена 84 төп төрле сорттагы куаклар, агачлар утыртыла. Бүгенге көндә зәңгәр чыршы, сирень, өрәңге, усак агачлары, лапчатка, нарат җиләге, барбарис, спирея куаклары шаулап үсә. Икенче яр буена – туя, миләш, имән, тау битенә исә Лесхоз ярдәме белән 300 гә якын нарат үсен-

тесе утырталар. Тау битеннән чишмәгә кадәр таш һәм ком белән тигезләп юл түшәлә. Ярны ныгытыр өчен, су буена блоклар һәм 26 КамАЗ машинасы таш салына. Яр буен тигезләп, инеш суын тирәнәйтеп, аларны тезеп чыгалар. Ташу вакытында су агызып китмәсен өчен, араларына үлән чәчеп, ныгытып калдыралар. Матур булып үсеп чыккан үләннәрне авыл яшьләре өмә ясап, кисеп, чистартып торалар. Су буе ничек басмасыз, күперсез булсын инде! Әлеге гаҗәеп күперне эшләтер өчен дә хәйран гына акча кертелә, шактый хезмәт куела. Елга ярына 10–15 метрлы субайлар кагып, күперне ташу агызмаслык итеп ныгытып куялар. Чишмәне буралап алып, әченә кое ясап утырталар. Бирегә килүчеләр чишмәгә карап хозурлансын, ял итеп утырсын өчен, ян-якларына эскәмияләр ясап куела. Болар барысы да ике-өч ел эчендә башкарылган эшләр! «Шундый үзәк өзгеч бер вакыйга да булды, – дип искә ала Энҗе ул көннәрне. – Чишмә башланган урында, күп казына торгачмы, чистартканда суы азайды. Барысы да бер улакка койсын дип, суы мул булып аксын өчен, берләштерергә генә уйлаган идек югыйсә. Табигать үзенә каршы барганны кабул итәме соң?! Мәчеткә, кыйблага карап, күз яшьләрем белән Аллаһка ялвардым, кулларым белән җирне сыйпап, Җир-анадан мәрхәмәт сорадым. Күпме хезмәт куелгач, инде эш бетә дигәндә генә! Ниһаять, акрын-акрын гына туфрак дымлана башлады, һәм, ышанасызмы: тагын бер чишмә бәреп чыкты! Озак та үтмәде шаулап су ага башлады! И сөендек инде!»


Билгеле, мәчетне төзеп, чишмә буйларын ямьләндереп куеп кына эш бетми әле, алга таба да аның яшәешен тәэмин итәргә кирәк. Һәммәсе дә чыгым, вакыт, карап тору таләп итә. Утына-суына түлисе, тирә-ягын тәртиптә тотасы. Энҗе монда да үзе башлап, берничә ел мәчет тирәсендәге, чишмә буйларындагы үләннәрне үзе чабып, чәчкәләр үстереп, аларга су сибеп, шәхси үрнәк күрсәтә. Тора-бара авыл халкы да кушылып китә, ел саен язга чыккач чишмә буен, мәчет тирәсен өмә ясап чистартып алалар.

Вакыты никадәр генә тыгыз булмасын, Энҗе туган авылына кайтканда чишмә буйларын урамыйча калмый. Бер уңайдан юл өстендәге мәчеткә дә сугыла. Бөтенесен барлап, күз уңыннан үткәрә: ул теләгәнчәме? Аның куллары, аның мәрхәмәтле карашы, йөрәге аша узган һәрбер агач-куак, чәчкәләр балкып-куанып каршы ала сыман. Авылдашлары да аңа рәхмәтле: булганны кадерләп саклыйлар. Хезмәтнең бәяләнергә, хөрмәтләнергә тиешлеген үз үрнәгендә күрсәтә алуына шат ул. Чишмә буенда мәчеткә карап үзалдына уйланып торырга, үткән тормышын барларга, эшләренә нәтиҗә ясарга ярата. Әтисе белән ерак балачактагы сөйләшүләрен, чишмә чистартуларын, әтисенең соңгы сүзләрен күңеленнән янә бер кат яңартып ала да: «Шөкер, васыятеңне үтәдем, әти!» – дип пышылдый. Билгеле, ул моның өчен уллары Эльмир белән Илфирга, тормыш иптәше Илфарга рәхмәтле.

Бүгенге көндә кемнәрдер туганлык җепләрен саклап яши алмаганда, Энҗе өчен олы апа булып, барысын бергә туган йортка туплап, әти-әни рухы тирәсенә берләштереп яшәтү – зур җаваплылык. Туган нигезне, авылларының хөрмәтле кешесе, озак еллар балаларга белем биргән укытучы әнисе Суфияны тәрбияләп яшәтү дә Энҗе җаваплылыгында, аның кайгыртуында була. «Апа кеше нинди була?» – дип сорасалар, мин нәкъ менә Энҗе кебек ярдәмчел, туган җанлы, олы йөрәкле була дияр идем. Әйе, изгелек капкалары күптөрле. Бары тик кул сузымы арада гына торган күңел түрендәге әлеге капканың келәсен генә күтәрәсе дә изгелек, матурлык нурларын тирә-якка сибәсе! Төрле киңәш белән килгән авылдашларына да вакытын кызганмый: юридик яктан киңәшләр бирә, проблемалардан чыгу юлларын күрсәтә. «Еллар ала алмый торган матурлык бар – ул күңел матурлыгы», – ди Энҗе Барис кызы Шәйхетдинова. Әлеге чын күңелдән әйтелгән сүзләр аның эш-гамәлләрендә чагыла. Әйе, күңеле матурлык белән тулы булган кеше генә изге эшләргә, башкаларның да күңелендә эз калдырырлык җуелмас матурлыклар тудырырга сәләтле. Матурлыктан матурлык кына туа ала.

...Заманнар үзгәрде, дистә еллар күрмәгән дустың яки башка берәү турында нидер белим дисәң, аның социаль челтәрләрдәге битенә күз салып алу да җитә: кем кая барган, нинди яңалыклары бар,ниләр белән шөгыльләнә?.. Дуслары кемнәр? Фотосурәтләр, язышкан язулар барчасын үзе үк сөйләп бирә. Әнә бер фотода Энҗе – уллары-оныклары белән бәхетле дәү әни, икенчесендә исә улы белән Германиядә, Дания, Швеция, Швейцария, Голландия, Италиядә... Ире Илфар белән Израильдә, Кытайда, Филиппин утрауларында, Тайваньда... Бер-берсенә сыенышкан, янәшәсендәге пары белән гомер буе бәхетле булырга теләп, һәр минутның ямен, кадерен белеп калырга омтылган ике җан... Һәм фотолар белән бергә Илфарның иң кадерле сүзләре, теләкләре:

«Иркәм минем, сине туган көнең белән котлыйм!!! Мин сине өзелеп яратам!! Алдагы елларда да шулай матур итеп яшәргә язсын, Алла бирса!!! Синең елмаюларың, көлүләрең миңа бәхет бирә һәрчак. Рәхмәт сиңа, минем Энҗем!!!»



■ Ире Илфар Яхин белән.





# ИКЕ ГЕНӘ ҮКЕНЕЧЕМ БАР...



Алсу ШАКИРОВА

**– Урамда төн. Мин Каравай бистәсе тукталышыннан өйгә – Жилплощадка ягына җәяү кайтып барам. 90 нчы еллар бу, шәһәрдә яшәгәннәр моның никадәр башсызлык булуын аңлар... Ләкин башка чарам юк. Заводта эшем бетүгә көн саен университетка чабам. Дәресләр кичке ун тулырга егерме минутта тәмамлана. Аннары мине төн уртасына кадәр сузылган юл көтә: өйгә кайтып кергәндә унике дә, бер дә, ике дә була кайчак. Көн саен шулай бит ул! Ләкин минем иң яраткан һәм университетта иң авырлардан саналган хисаплау математикасы һәм кибернетика факультетында (ВМК) укуымнан юл газабы да биздерә алмады. Ә өйдә кечкенә балам көтә, ике кайнана, ике кайната белән яшибез...**

**Бу хатирәләрне искә төшереп утыручы, кайчандыр саннар, хисаплар дөньясы белән хыялланган Илһамия ханым САБИТОВАның Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикография бүлегендә эшләве – үзе бер гаҗәп. Быел лексикография бүлеге, 25 елга сузылган саллы хезмәтләренә нокта куеп, татар теленең алты томнан торган аңлатмалы сүзлеген тәмамлаган. Бу – сүзлек эшләнү тарихы гына түгел, ә кеше язмышындагы аңлап булмаслык борылышлар, алтын урталык эзләү тарихы да.**

– Математика математика инде ул! Кечкенәдән төгәллек яратучан мин. Әтиемнең әнисе – дәү әни безнең белән Апас районы Тутай авылында яшәде. Үләннәр җыеп, киптереп, каз майлары кушып, төнәтмәләр ясый иде. Аларны үзенчә «тәрбия» дип атый. Бөтен авыл безгә шул тәрбияне сорап килә, әби ничек сөртәсен өйрәтә, өшкерә. Өшкертергә руслар да, чуашлар да йөри. «Сезнең динегез башка бит, ул мөселманча укый», – ди идем аларга. «Булыша бит...» – дип, барыбер йөриләр. Мастит, теш сызлау кебек авырулардан дәвалый, күздән чүп ала иде. Бервакыт энемнең эченә тимер кадалды. Районга җибәрмичә генә дәү әни аны үзе тәрбияләп аякка бастырды. Мин генә ышанмый идем... Кызым, бөтен авыл йөри бит инде, дип, мине өшкерергә маташа, ә мин каршы киләм, якын да китермим. Тотып карарлык әйбер булмагач, мин моны кабул итә алмый идем. Дәү әни рәнҗегәндер дә инде миңа, бәлки... Хәзер әбинең куркулык салу өчен кургаштан ясаган әйберләрен, бөтиләрен, хәситәләрен кулыма алам да, нишләп миңа да аз гына булса да күчмәде икән әбинең бу сәләте дип уйлыйм. Үкенәм...

Кияүгә чыкканда студент була әле Илһамия апа. Төп йортка килен булып төшә ул. Аның кебек төгәллек яраткан, математик фикерләү сәләтле кызга Ходай бөтенләй капма-каршы холыклы кешене насыйп итә. Альберт абыйны әтисе кечкенәдән җитмеш төрле һөнәр өйрәтеп үстергән, ел саен яңа бер шөгыль табып, төрле түгәрәк-

# «Институт тарихында беренче тапкыр диссертация якларга лаборант керде», – ди галим.

ләргә йөрткән. Соңыннан килене моның өчен рәхмәтле булыр дип уйлады микән ул чакта? Ирен алтын куллы дип мактый Илһамия ханым. Баянда уйнарга дисеңме, тегү-чигү, пешерү эшләреме – эх тә итмичә эшләп куя, һәрнәрсәгә кулы ята.

– Кирәк булса, тегү машинасында итәк тә тегеп бирә ала ул миңа. Кызларыбыз да әтиләренә охшаган. Серләрен дә иң беренче аңа чишәләр. Рәсемнәр, шәмаилләр ясыйлар. Минем өчен бөтенләй кирәкле түгел кебек аларның бу шөгыле, чыгып бакча казысалар яхшырак, дип көлеп йөрим. Практик ягын исбатлап бирсәләр генә килешми чара калмый инде.

Авыл мәктәбен тәмамалаган кызларда ул елларны «юрфак» дип хыяллану башлана. Мәртәбәле Казан дәүләт университетының дәрәҗәле юридик факультеты! Ләкин беркатлы авыл кызлары, «анда керә алмыйсыз» дигән сүзгә ышанып, география факультеты студентлары булып куялар. Ә күңел бөтенләй ятмый... Өч ел түзеп укый да, әти-әнисенә әйтмичә дә ВМК факультетының кечкенә бүлегенә документларын тапшыра. Менә Илһамия ханым яңадан беренче курс студенты. Соңыннан кызларына еш әйтә ул бу сүзләрне: «30 яшькә кадәр укыдым мин», – ди. Көндез – Казан авиатөзелеш заводында склад мөдире, кичен – КДУ студенты.

12 ел заводта эшли, тагын да дәвам итәр иде дә... Үзгәртеп кору еллары башлана, яңа җитәкчелек килә. Фикерләр, эшкә карашлар тәңгәл килми – Илһамия ханым эштән китәргә мәҗбүр була. Ә еллар узып бер очрашкач, җитәкчесенә рәхмәт әйтергә җай чыгара хәтта.

– Сез булмасагыз, гомерем буе заводта утырган булыр идем, дидем. Югыйсә эштән киткәч бер дә җиңел булмады... Болганчык еллар, эш табуы кыен. Сеңлем Мәгариф милли проблемалары институтында сәркатип булып эшли иде. «Апа, безгә бер кызык абый килде, аңа лаборант кирәк икән, барып кара әле шуңа», – ди. Бу «кызык абый» – танылган галим, филолог, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе әгъза-корреспонденты, Россиянең атказанган фән эшлеклесе Фуат Ганиев булып чыкты. Үзе минем белән танышканнан соң директор Мирфатыйх Зәкиев янына алып керде. «Белемең буенча кем буласың?» – дип сорый. Аңлатып күрсәткәч: «Һай, сеңлем, гомерең буе лаборант булып утырачаксың икән», – диде.

Шул вакытта ничек хурланганын әле дә оныта алмый. Ләкин бирешми! Илһамия ханым өчен галимнең бу сүзләре зур этәргеч була. Бергә эшләүче кызлардан нәрсә белән шөгыльләнгәннәре турында кызыксына – барысы да диссертация язалар. Бишәр, унар елга сузыла, диләр... Нишләп алай язалар икән дип аптырый ул. Һәм, тәвәккәлләп, үзе дә аспирантурага керә. Тиешле вакытыннан да алданрак кандидатлык диссертациясен яклаган хезмәткәре турында Мирфатыйх Зәкиев горурланып сөйли бу юлы! Компьютер белән телне берләштерүче фәнни эшен Илһамия ханым остазлары Камил Галиуллин һәм Фуат Ганиев җитәкчелегендә бик җиңелдән яклап чыга.

– Сүзлек төзү – математика кебек ул. Һәр сүзлекнең үз формуласы бар. «Кызлар, әйдәгез, бу сүзлекне шушы формула буенча эшлик», – дип тәкъдим итәм. Чөнки безнең эштә ноктасы да, өтере дә үз урынында булырга тиеш, бер хилафлык та калмасын. Башта структурасын төзибез, а+б+с дип тезеп китәбез. Сүзлегенә карап формуласы да катлаулырак булырга мөмкин.

Сүзлек төзү – фанатлар эше. Бу хезмәтне башкарыр өчен үз эшеңне чынлап яратырга кирәк. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге өстендә 1998 елда эшли башлаганнар. Ул вакытта бүлектә унбиш хезмәткәр булган. Соңгы алтынчы томның дөньяга чыгуын аларның күбесе инде күрергә дә өлгермәгән... Шуңа күрә сүзлек өстендә эш тәмамлануы, үз хезмәтләренең нәтиҗәсен күрә алу шатлыгы аеруча кадерле.

– Миннән бик яхшы икътисадчы йә зур гына оешманың баш хисапчысы чыгар иде, дим кызларга. Бөтен исәп-хисап эшләрен җайлы эшлим, күпме хезмәт хакы аласын да алдан санап куям хәтта. Өйдә дә шулай мин. Һәрнәрсә урынында булсын, төгәл булсын, анда-монда ятмасын. Өйдә озаграк торсам, өйдәгеләр туеп та китә *(көлә)*. Һәр ноктаны, һәр өтерне төртеп утырудан чыккан гадәттер инде бу дип уйлыйм. Шулай да, икенче югары белемемне финанс институтында аласым килгән иде. Тәвәккәллегем җитмәде дип үкенәм...

Әнә шулай ике капма-каршы юнәлеш көрәшә Илһамия Ислам кызында. Бизмәнне икесе ике якка тартучы бу каршылыклар иясенә бер алтын урталык табарга ярдәм итәдер дә, мөгаен. Хоббиның да тел белән бәйлесен сайлаган бит! «Сеңлемнең ире – румын татары. Ул алып кайткан китапларны укып, аларны кириллицага күчердем. Бер томлык әкиятләр тәрҗемә иттем инде, аларны бастыру – янә бер хыялым», – ди бит әнә.

– Теләсә кем сүзлек төзи алмый. Аңа тәҗрибә, сабырлык, теоретик һәм практик белем кирәк. Сүзлек төзүче универсаль булырга тиеш. Сүзлек математикага бик якын әйбер, ул төгәллек таләп итә. Илһамия Исламовна эшенә карата беркайчан да битараф түгел, һәрвакыт төгәл. Аның өчен һәр әйбер исбатланган булырга тиеш. Шул ягы сүзлеккә якын итә аны. Без күрмәгән хаталарны да тиз сизеп ала. Техник яктан төгәлсезлекләрне табар өчен аңа мөрәҗәгать итәм, ул диагональ буенча гына укып чыкса да, җитешсезлекләрне тиз күреп ала, – ди аның турында бүлек җитәкчесе Ринат Сәфәров. – Илһамия ханым фәнни яктан үсеш алган чорына килеп җитә. Аңлау дәрәҗәсе, тәҗрибәсе бик бай. Төпкә җигелеп тартып барырлык хезмәткәр ул безнең, аңа өметләр дә зурдан әле. Мин аны татар теленең тулы сүз ясалыш сүзлеген эшләр дип өметләнәм. Моны ул гына башкарып чыга ала.

Әйе, күңеле белән математик, гамәле белән филолог булган Илһамия ханым үзе дә моңа әзер инде – формуласын күптән уйлап куйган. Бу хыялы үкенечле булмаячагын төп-төгәл белә ул!

Фото: Анна Арахамия





# АДЫМНАР

Чулпан
ГАЛИӘХМӘТОВА

**Шимбә. Кичке сигез. «Яңа гасыр» каналы. Зәңгәр экраннарда бу вакытта «Адымнар» тапшыруы башлана. Менә инде чирек гасыр дәвамында татар тамашачысына республикада булган атналык вакыйгаларга күзәтү ясап, татар дөньясына аналитик мәгълүмат җиткерә ул. Милли күтәрелеш чорында туган тапшыру бүген ниләр белән сөендерә, уйландыра? Бу хакта «Яңа гасыр» каналының мәгълүмати һәм иҗтимагый-сәяси тапшырулар дирекциясе баш мөхәррире, «Адымнар»ның авторы һәм алып баручысы Сәрия ХӘБИБУЛЛИНА белән сөйләшәбез.**

**Сәрия, син үзең дә телевидениедә ике дистә ел эшлисең, «Адымнар»ны төп командадан кабул итеп алучы. Тапшыру 25 ел эчендә үз йөзен югалтмадымы, үзенә хыянәт итмәдеме?**

– «Адымнар» – 90 нчы елларда барган вакыйгаларның кайтавазы буларак барлыкка килгән тапшыру. 1997 елда бер төркем татар журналистлары республиканың ул вакыттагы Президенты Минтимер Шәймиевнең туган көненә яңа тапшыру чыгарырга ниятли. Беренчесе аның белән татар телендә әңгәмә форматында эфирга чыккан. Тапшыруга «Адымнар» дип исем биргәннәр. Заманына карасаң, исеме ул вакытта бик актуаль булган. Хәзер дә Минтимер Шәймиев башлангычында тормышка ашырылучы, күп телдә белем бирү мәктәпләрен «Адымнар» дип атауда аерым мәгънә бар. Ул чакта да, хәзер дә тел, милләт мәсьәләләре көн кадагында тора. «Яңа гасыр» каналының генераль директоры Илшат Әминов ул чакта тапшыруның исемен билгеләүдә, форматын раслауда катнашкан кеше. Гомумән, «Адымнар» – «Эфир» каналында татар телендә чыга башлаган берләнбер аналитик тапшыру. Ул чорда җәмгыятьтә аңа ихтыяҗ зур булган. Милли күтәрелеш вакыйгалары, җәмгыятьтәге проблемалар, гаделсезлекне яктырту – барысын да колачлаган ул. Мәгълүматны җиткерү алымнары белән дә, теле белән дә аерылып торган. Безне, бу тапшыруга практика үтәргә килгән кызларны, башкача – җөмләләрне кыскарак итеп, «адымнарча» язарга өйрәттеләр. Программа төрле елларда төрле телеканалларда, төрле иҗат төркемнәре тарафыннан әзерләнә, әмма асылы үзгәрешсез кала. Аналитик мәгъълүматны профессиональ дәрәҗәдә татар тамашачысына үз туган телендә  җиткерү. Тапшыру – каналда иң яратып карала торган программаларның берсе. Әйе, без тел ягыннан үзгәрдек. Соңгы елларда татар әдәби теленә кайттык. Яңалыклар хезмәтендә дә, «Адымнар»да да татар әдәби теленә ихтыяҗ зур. Без бит шундый тиз заманда яшибез. Хәтта сөйләшүебез дә кыскарды. Сизәсездер, сөйләшкәндә барлык авазларны әйтеп бетермибез. Ә телевидение тел саклауда эталон булырга тиеш. Аеруча милли телеканалда. Темалар да заманына карап үзгәрә. Без аларга тирәнрәк карый башладык. Телне гаиләдә саклау, мәктәптә өйрәнү, үзара сөйләү күнекмәләрен булдыру кирәклеге көнүзәк мәсьәләгә әйләнде. Без хәзер җитдиләндек тә: «мөгез чыгарырга» тырышмыйбыз. Бер вакыйганы төрле яклап карап, аңа карата фикерләр туплыйбыз. Бервакытта да вакыйгаларны берьяклы итеп кенә күрсәтмибез, проблемалы сюжетлар ясаганда ике якны да тыңлыйбыз. Тормышның төрле кимчелекле якларына юмор аша карауны «Кадак» сәхифәсендә саклап калдык.

**«Адымнар» шәхсән минем өчен Шамил Садыйков, Рәмис Латыйпов исемнәре белән бәйле...**

– 2000 нче елларда Казанга килгәндә ул тапшыру минем өчен буй җитмәслек югарылыкта иде. Университетта уку елларында хыялга әйләнде. Анда эшләгән яшьләр белән аралаша башлагач, монда эшләр идем дигән уй бар иде. Шулай туры килде: безне университеттан анда иҗади практикага җибәрделәр. «Татмедиа» акционерлар җәмгыяте генераль директоры Шамил Садыйков – минем остазым, телевидение өлкәсендә аны беренче укытучым дип саныйм.

**Миңа калса, «Адымнар» 25 ел элек хайплы тапшыру иде. Темалары колак торгыза торган булды. Татар телевидениесендә беренче хайп тапшыру дип әйтә аласыңмы аны?**

– Әйтә алам. Тапшыруда «сарылык» та бар иде кебек. Бу тапшыру чыга башлаган вакыт белән бәйле дип уйлыйм. Ул чор журналистикасы өчен феномен буларак истә калган. Әлбәттә, яңалык алып килгән тапшыру. Матбугатка кызыклы күзәтү ясауларын хәтерлим,

«Кадак» сәхифәсе, аннан соң Шомбай персонажын кертеп җибәрдек. Гомумән, хәзер дә башка тапшыруларда булмаганны эшләп карау теләге белән иҗат итәбез.

**Демократия җилләре искән вакытта чыккан тапшыруның сүз иреге белән проблемасы булмагандыр, мөгаен. Хәзер цензура дигән төшенчә бармы сезнең тапшыруда?**

– Минемчә, сүз иреге һәрвакыт бар. Бу теманы алмагыз, бирмәгез, дип беркем дә әйтми. Бергәләп атна вакыйгаларын барлыйбыз һәм актуаль темаларга репортажлар әзерлибез. Бу очракта журналистның күбрәк үзенә карата цензурасы бардыр – законнарны үтәү, этика чикләрен узмау, бер якны күрсәтәм дип, икенче якка зыян китермәү.

**Кадрлар мәсьәләсе ничегрәк соң? Телнең тәмен белгән, кыю, фикерле журналистлар соңгы елларда сирәгәйде кебек...**

– Минем өчен иң «авырткан» җир бу, Чулпан. Әле ярты ел элек кенә кадрлар мәсьәләсе кискен тормый дип әйткән идем, әмма хәзер фикеремне үзгәртергә мәҗбүр булдым. Белгәнегезчә, «Адымнар» тапшыруын Яңалыклар дирекциясендә эшләүче журналистлар әзерли. Яңалыклар – телевидениенең иң авыр хезмәте ул. Бу сынауны иң көчлеләр генә уза һәм гомерлек һөнәре итеп сайлый. Монда йә «төпләнеп» каласың, йә юк... Кемдер еш кына профессиональ яктан «янып чыга». Кичә эшли, бүген инде китәргә тели, ә берсекөнгә китә дә. Икенче яктан, татар телендә эшләүче журналистларны табу соңгы елларда авырлашты.
Әле без аның белән алдагы берничә елда тагын да ныграк очрашачакбыз. Телевидениегә килүчеләр күп, ә калучылар аз. Чөнки көндәлек авыр хезмәт, татар әдәби телең көчле булырга, сөйләмең колакка май булып ятарга тиеш. Татар телен беләм дип килүчеләр бар, әмма аларның дәрәҗәсе безнең таләпләргә туры килеп бетми. Яшьләрнең китап укымавы, социаль



Фото: Анна Арахамия





челтәрләрдә кыска итеп язышулары, гомумән, телнең куллану даирәсе кимү белән бәйле дип саныйм моны. Бу – зур проблема бүген.

**Бүген сезнең «Яңалыклар» эшләүче ун корреспондентның дүртесе иртәгә китәм дип әйтә икән, ничек эшләргә җыенасыз?**

– Быел кадрлар мәсьәләсен канал җитәкчелеге дәрәҗәсендә яңадан карадык. Телевидениедә татар телен саклап калырга телибез икән, журналистларга гына түгел, филологларга да игътибарны арттырырга тиешбез. Әгәр дә кеше туган телендә иркенләп аралаша, мәгълүматны тоя, үз фикерен туган телендә җиткерә ала икән, ул журналист була алачак. Кызганыч, яшьләрдә калькалы фикерләү бар. Бер генә тәрҗемәче дә телнең матурлыгын туган телдә сөйләшүче кадәр җиткерә алмый. Оригинал тел булмаса, материалның җылысы булмый. Күптән түгел КФУның филология институтында тел белгечлеге алучы студентлар белән очрашуда булып кайттык.  Аларны эшкә чакырдык. Дүрт ел элек безнең канал «Әйдә ТНВга» дигән грант булдырып, ике ел эчендә алты студент КФУга укырга керде. Быел дәүләт имтиханнарын тапшырып бетерүгә өчесе безгә эшкә киләчәк. Бик өметлеләр, иң мөһиме – татарча уйлыйлар. Тагын өчесе киләсе елга укуын тәмамлый.

**Сәрия, әле бит тел белү генә түгел, аналитик фикерләү сәләте дә кирәк. «Адымнар»да нәкъ менә шул сәләте булган журналистлар гына эшләргә тиештер, мөгаен. Күзәтүләрең буенча, әйт әле, яшьләрдә аналитик фикер йөртү ничегрәк?**

– Журналистлар арасында репортерлар һәм аналитик фикерләүче авторлар бар. Тумыштан репортер булган кешеләр бар. Алар вакыйга урыныннан менә дигән репортаж әзерли. Бар аналитик фикерләү сәләте киңрәк булган журналистлар. Аналитик материаллар эшлисең килә икән, укырга, даими анализларга, эзләнергә, чагыштырып карарга, тәнкыйди фикерләргә өйрәнергә тиешсең. Бездә әле татар халкының бай тарихын, милләт язмышын, милли мәсьәләләрен белү, милләтара мөнәсәбәтләр белән таныш булу да шарт. Ул бик мөһим һәм нечкә әйберләр. Гомумән, журналист катлаулы, уңайсыз сораулар бирүдән курыкмаска тиеш. «Син соравыңны бир, аның җавабы кайчакта теманы бөтенләй башка якка борып җибәрергә мөмкин», – дим мин. Кешенең эндәшми калуы да нәрсәнедер аңлата бит.

**Бүген «Адымнар»ның төп хәбәрчеләре кемнәр?**

– Фәйрүзә Мәҗитова, Гөлназ Сәйфетдинова, Рания Абдрахманова, Алия Хәйретдинова, Илдар Сафиуллиннар. Хәзер әкренләп Илгиз Шәкүров та безнең составка кереп бара. «Кадак» сәхифәсенең даими авторы һәм алып баручысы Данил Сәфәров. Режиссер кызларыбыз - Зөлфия Касыймова, Ләлә Рәхимова.

**Сәрия, ничек кенә әйтсәк тә, татар матбугатының, татар телевидениесенең төп аудиториясе авыл җирлекләрендә яшәүчеләр. Сез дә бит тиккә генә тапшыру саен авыл темасын яктыртмыйсыздыр.**

– Безне авылда да, шәһәрдә дә карыйлар. Авылда бер аудитория, шәһәр җирендә башкачарак. Әмма алар өчен уртак мәсьәләләр бар – милли тематика, җәмгыяви проблемалар. Аеруча Татарстаннан читтә яшәүче милләттәшләребез безне үз итә. Авылны, гореф-гадәтләрне саклауга кагылышлы сюжетларны чынлап та интернет аша күп карыйлар. Без тамашачы ихтыяҗын истә тотып эшлибез. Яңалыклар хезмәтенең ватсап номеры бар. Анда күп язалар. Авыл җирендә еш кына юллар, кибетләр булмаудан, эш юклыктан зарланалар. Репортажлар аша халыкны борчыган мәсьәләләр хәл ителә, йә аңа карата җәмәгатьчелек игътибарын көчәйтәбез, йә җаваплы оешмаларның игътибарын юнәлтәбез. Шундый очраклар була. Хәбәр килә. Без бу авылга кайтырга җыенабыз, ә ул абзый җаваплы кешегә кичтән «ТНВ чакыртам», – дип әйтеп куйган була. Без кайтып өлгергәнче, җаваплы кешеләр инде проблеманы килеп хәл итә дә башлый. Әлбәттә, шәп сюжетсыз калабыз, әмма безне искә алуга ук проблеманың чишелә башлавына сөенәбез.

**Сюжет әзер булгач, «Эфирга чыгармагыз» дип шалтыратулар булганы бармы?**

– «Мине алай бирмәгез», – дип шалтыратулар булганы юк. Проблемалы материал ясаган вакытта кайсыдыр як комментарий бирүдән баш тарта икән: «Без материалны барыбер эфирга әзерлибез, сезнең фикерегез булуы мөһим, әгәр дә сюжетта фикерегез яңгырамаса, үзегез үк, тулы материал булмаган, дип тәнкыйтьләячәксез», – дип, алдан әйтеп куябыз.

**Телевидение авыр хезмәт, тиз хезмәт. Команда эше. Сюжет вакытында чыкмый икән, аның җәзасын кем ала?**

– «Көне буе төшереп йөргән сюжет эфирга өлгерми икән, аны әзерләп торудан ни мәгънә?» – дим кайчак корреспондентларга. Хәзер мәгълүмат ташкыны бик зур. Бүген әзерләгән сюжет иртәгә актуаль булмаска мөмкин.
Ә менә беренче эфирга өлгермәгән сюжетларны алдагы чыгарылышка калдырган очраклар була. Соңгы итеп булса да өлгертәбез дип уйлыйсың, әмма телевидениедә техник моментлар бик күп. Сюжет эфирга өлгермәгән өчен штраф юк, әмма фактик хаталар, титрларда киткән ялгышлык өчен – бар.
Без бит республиканың төп каналы. Бездә дә хата китә икән, башкалардан нәрсә көтәргә? Ләкин хаталар барыбер була. Кеше хатадан хали түгел.

**Телевидениедә, бигрәк тә «Яңалыклар» дирекциясендә эшләп гаиләне алып бару авыр дип әйтәләр.**

– Минемчә, гаилә белән телевидениене алып бару – ул талант. Бездә андый талантлы кешеләр бар. Ләкин минем андый талантым юк, ахрысы. Әлегә. (*Елмая.*)

**Минем күзаллавымда син бик салмак, үтә дә тыныч кеше кебек. Ничек яңалыкларга кереп китә алдың?**

– Миңа яңалыкларда эшләү ошый. Аның үз ритмы, үз агышы бар. Бер-берсенә охшаган бер көн түгел, бер сәгать тә юк. Ул сиңа әллә ничә көнгә җитәрлек тизлек бирә. Ялга киткәч тә, әле берничә көн шул ритм белән яшәгән кебек буласың. Мин тыштан гына тыныч күренәм, эчтән кайнаган чаклар күп була. *(Көлә.)* Гәрчә, һәр карарны салкын акыл белән кабул итү яклы. Югары классларда укыганда анык кына нинди һөнәр сайлаячагымны белми идем. Казан дәүләт университетының журналистика факультетына да, Казан авиация институтына да имтиханнар тапшырдым, әмма журфакка керүем алданрак билгеле булды. Язмыш юлы журналистикага алып кереп китте.

**Үкенмисеңме?**

– Хәзерге акылым булса, журналистикага кермәс идем. *(Елмая.)* Үкенүме ул, еллар узгач зурларча нәтиҗәгә килүме, вакыты белән эштә профессиональ яктан бераз арумы, янумы – белмим... *(Уйланып тора.)* Бәлки матурлык һәм табигать белән бәйле һөнәр сайлар идем. Ландшафт дизайны, биология белән бәйле һөнәрләрне якын итәм.

**Журналистикада эшләү дәверендәге иң зур уңышың?**

– Һичшиксез, профессиональ яктан – «Адымнар» тапшыруының ТЭФИ премиясе алып, Россия дәрәҗәсендә танылуы. Ул безнең өчен көтелмәгән булды. «Адымнар» – татарча аналитик телетапшырулар арасында ТЭФИ алучы бердәнбер программа. Аны безгә Владимир Познер тапшырган иде. Ә көндәлек уңышларга килсәк... Мәсәлән, яңалыкларда авыру балага акча җыю турында материал эшлисең икән, кирәкле сумма кайвакыт шундый тиз җыела. Әтисеме, әнисеме, шалтыратып, сезгә шундый рәхмәтлебез, көтмәгән, ышанмаган идек, дип әйтсәләр, сөенәбез. Бер ай элек кенә шундый сөенечле шалтырату алдык. Тәүлек эчендә 500 мең сум акча җыелган иде. Кешеләргә яшәүгә өмет бирү, тормышта бүген җиңеп чыга алмастай тоелган мәсьәләләрне хәл итүгә өлеш кертү күңелле.

**Син матбугатның бүгенге хәленнән канәгатьме?**

– Канәгать түгелмен. Кыюлык, үткенлек, журналист тикшерүләре җитми дип саныйм. Журналист канәгать булырга, битараф калырга тиеш түгел.

**«Адымнар»ның «теше» үткенме?**

– «Теше» бар. Әмма аның үткенме, түгелме икәнен телевизор караучылардан сорарга кирәктер. Ә тамашачыларыбыз күп. Шалтыратып, электрон хәбәрләр җибәреп кенә калмыйлар, ышанмассыз, әле дә чын хатлар язалар. Эш өстәлемдә бер өем хат җыелган.

**«Адымнар»га теләгең...**

– Мин аны бик яратам. Ә яратканга бары тик яхшылык кына телиләр. Тапшыруда эшләүчеләрнең илһамы сүрелмәсен. Иң мөһиме – үз асылыбыз үзгәрмәсен: милли үзәнны үстерүгә кагылышлы темаларны яктыртудан туктамасак иде. Моның өчен дәрт тә, дәрман да булсын.



Фотода (сулдан-уңга): Данил Сәфәров, Фәйрүзә Мәҗитова, Сәрия Хәбибуллина, Илгиз Шәкүров, Гөлназ Сәйфетдинова, Рания Абдрахманова, Илдар Сафиуллин.

# «БАЛАЛАР БЕЗГӘ БУРЫЧЛЫ ТҮГЕЛ»

Үсмерлек чоры. Ата-ана өчен иң зур сынау вакытыдыр бу, мөгаен. Сүзеңне тыңлап, һәрвакыт янында сырпаланган бала көннәрдән бер көнне бөтенләй үзгәрә дә куя. Аның инде үз дөньясы... Бала белән бәйләнешне ничек саклап калырга? Үсмер белән үзеңне ничек тотарга? Бәлки, безнең геройларыбыз тәҗрибәсе дә сорауларыбызга җавап табарга ярдәм итәр. Рубрикабызның кунаклары – «Интертат» электрон газетасының журналисты Рузилә МӨХӘММӘТОВА һәм аның кызы СӘЛИМӘ АСКАРОВА.



**Сәлимә, синеңчә шәхес кем ул? Кумирың бармы?**

– Шәхес ул – башкалардан аерылып торып, үзе булып кала белүче. Аның уй-фикерләре, дөньяга карашы башкачарак, ул аның киеңү рәвешендә дә чагыла. Шәхес булгач, үзгәрүе кыен инде. Миңа калса, үсмерлек чорына – 10 яшьләргә кадәр – шәхес булып формалашасыңдыр. Кумирым юк. Әйе, кемнәрнеңдер тышкы кыяфәтләре ошый, ә холыкларын белмим. Ничек минем кумир булсын инде алар?!

**Ничек уйлыйсың, баланың шәхес булып формалашуында әти-әнинең тәэсире зурмы?**

– Әнинең тәэсире көчле булган булса, мин хәзер «Н. И. Фешин исемендәге сынлы сәнгать училищесы»нда укымас идем, журналист булам дип йөрер идем. Ул мине рәсем сәнгатенә бөтенләй бирмәс иде.

**Синең өчен ирек нәрсә ул?**

– Ирек ул – уй-фикерләреңне, кабул иткән карарыңны теләсә кайсы вакытта үзгәртү. Нигәдер өлкәннәр тормышларын үзгәртүдән курка...

**Ә әниең ирегеңне кысамы?**

– Ничек карыйсың инде. Кайчак мин шулай телим дип әйтәм дә, ул гаҗәпләнеп, кабул ителгән карарымда шикләнергә мәҗбүр итә. Бу миңа бер дә ошамый. Ул карар шәп иде, ә әни шуңа шикләнергә мәҗбүр итә! Юк, ул беркайчан да кистереп «юк» ди әйтми, каршы төшми, ә менә күңелдә шик уята белә.

**Димәк, әниең таләпчән түгел?**

– Кәефенә карап. Ә аның ул бик тиз үзгәрә. Сүзгә килсәк, үпкәлим. Ә мин озаклап, тәмләп үпкәләргә яратам. Ә ул берничә минуттан соң яныма килеп: «Син үпкәләдеңме әллә?! Әйдә, шоколад белән чәй эчәбез», – ди. Кәефне төшергәнсез икән, сез инде балага рәхәтләнеп үпкәләргә вакыт бирегез. Безнең күңел халәте өлкәннәрнеке кебек тегендә-монда сикереп йөрми бит.

**Сине еш контрольдә тоталармы?**

– Әйе! Бу минем җенемне чыгара. Дуслар белән урамда йөрергә чыгып китәм икән, әни 15 тапкыр шалтыратырга мөмкин. Шуңа беренче тапкыр шалтыраткач ук кайда, кемнәр белән булуыңны әйтү хәерле. Ә инде телефонны алмасам ничә тапкыр шалтыратыр иде икән?!. Әлбәттә, миңа мондый контроль ошамый, ул минем тавышыма чыга, шулай булса да, дусларымны исемләп атап чыгам, паркта нинди агач төбендә басып торуымны да әйтеп бирәм. Әни мине артык нык кайгырта.

**Һәрвакыт үз фикереңне әйтәсеңме, әллә инде эндәшми каласыңмы?**

– Әйтәм. Бәхәсләшәм. Башкаларның үз фикерләрен тагуларын яратмыйм. Балалар – башка кешеләр, аларның фикерләре дә башка булырга мөмкин. Зурлар шуны онытмасын иде. Алар сезнеңчә уйларга бурычлы түгел. Минем әни моны аңлый.

**Әниең синең өчен иң элек әниме, дус кызмы?**

– Дус кыз да, әни дә. Без дуслар кебек сөйләшәбез, әмма әни ролендә кемдер булырга тиеш бит. Бала белән әни арасында чикләр бардыр инде ул, әмма иерархия булмаска тиеш.

**Кайчан әниең белән ачылып китеп, рәхәтләнеп сөйләшергә яратасың?**

– Сәяхәт иткәндә. Гомумән, сәяхәтләр бик якынайта. Чәй эчкәндә сөйләшергә яратам. «Ашаганда сөйләшмиләр» дигән гыйбарәне кем уйлап чыгаргандыр, әмма ул тамырдан дөрес түгел. Ашаганда баш мие ял итә, димәк, рәхәтләнеп сөйләшергә була. Америка фильмнарында күрсәтәләр бит: бергәләп кичке аш ашаган чакта көне буе нәрсәләр булган, шул хакта сөйләшәләр. Миңа да шулай ошый. Әмма кайвакыт әни ашаганда газета укый.

**Ничек уйлыйсың, әти-әниләр балаларга күбрәк бурычлымы, әллә киресенчәме?**

– Әлбәттә, әти-әниләр. Алар бит безне тапкан. Без аларга рәхмәтле, әмма бурычлы түгел.

**Сәнгать училищесын тәмамлагач, башка шәһәргә китү турында уйлыйсыңмы?**

– Әйе, Петербургка китәсем килә. Бәлки, башка илгә үк китәрмен. Әни биш минут саен шалтыратып торачак, әмма җибәрәчәк. Минем белән китәргә дә әзердер ул дип уйлыйм.

**Рузилә ханым, үсмер Рузилә белән үсмер Сәлимә аерыламы?**

– Нык аерыла, чөнки заманы башка иде. Мин совет заманында – кысылган дөньяда үскән бала. Ул шәһәрдә, иркенрәк тормышта үсеп калды. Икебез дә дөньяны күрдек. Мин аны чит илләргә йөртергә тырыштым. Хыяллар, дөньяга караш бөтенләй башка төрле. Кайбер нәрсәләргә Сәлимәдән өйрәнәм дә хәтта, анык кызыграк та әле. Ул мине алдынгы карашлы әни дип бәяли. Аның бу сүзләре минем өчен мактау. Уку турында әйтсәк, мин яхшырак укый идем. Яхшы укысам гына авыл дөньясыннан чыгып китә алам дип уйладым. Әйе, Сәлимә дә китәргә тели. Бер карасаң, хыял-максатлар бертөсле кебек, әмма аныкылар күпкә зуррак масштабта. Холыкка килгәндә... безнең бертөрлерәктер ул. Икебез дә ирек яратабыз. Кыса башласалар, ачуыбыз килә.

**Димәк, Сәлимәгә чикләр куймыйсыз?**

– Мин таләпчән, әмма артык иреген кысам дип әйтә алмыйм. Ирек бирәм, әмма аны үсә башлагач ук кысаларга да керттем инде. Безнең өйдә махсус кагыйдәләр бар, ул аларны яттан белә. Кысаларны белеп тә, иреклe булып була дип аңлаттым аңа. Кич йөрү мәсьәләсендә безнең чикләр бар. Билгеле бер сәгатькә ул өйгә кайтып җитәргә тиеш.

**Һөнәр сайлаганда нинди дә булса этәргеч бирдем дип санайсызмы?**

– Күп әти-әниләр үз амбицияләрен балаларына күчерә. Шуларны күзәтеп, баланы һич тә ирексезләмәм дип уйладым. «Мин сиңа журналистикада гына ярдәм итә алам. Әмма син гомерең буе Рузилә Мөхәммәтова кызы булып йөриячәксең. Ул сиңа кирәкме?» – дидем. Аңа минем профессия кызык булгандыр дип әйтә алмыйм. Мин бит гел эштә, кичләрен театрларда. Шулай да әтисе музыкант булгач, музыка мәктәбенә бирдем. Аның ишетү сәләте көчле иде. Шул юлны сайлар дип уйладым. Укып чыкты ул, чөнки башлаган әйберне ташларга ярамый, дидем. Бәлки, гомерне әрәм итмәс өчен, ташларга да кирәктер... Әмма музыка мәктәбен тәмамлауга, фортепианоны сатабыз, диде. Саттык. Рәсем ясыйсым килә дигәч, Сынлы сәнгать мәктәбенә бирдем. Гомумән, баланың һөнәр сайлавында төп рольне әйбәт укытучы уйный дип уйлыйм. Безнең рәсем укытучыларыбыз бик көчле булды.

**Нинди чакларда рәхәтләнеп сөйләшәсез?**

– Ул бик ябык кеше. Пандемиянең бер файдасы булды: өйдә утырдык. Без Сәлимә белән көннәр буе сөйләштек. Нык якынайдык. Каядыр барсак, сөйләшәбез. Аннары безнең өйдә бер кагыйдә бар: кухняга телефон белән кермәскә. Мин газета белән керәм анысы, әмма ул гел шелтәли. Алып куям инде. Әмма газетаны тагын кайчан укырга була?!

**Хәзер балаларны кечкенә чактан ук шәхес булырга тиеш дип саныйлар. Сезнең шәхес тәрбияләүдә үз серләрегез?**

– «Син масса түгел, үз фикерең булган шәхес», – дим аңа һәрвакыт. Сәлимәне дөньяга иреклe карарга өйрәтергә тырыштым. Бәлки, традицияләргә бәйле булырга кирәктер дә. Әмма мин тиеш әйбер юк дип үстерәм. Дөресме ул, юкмы, белмим. Тиеш әйбер мине баса. Бала әти-әнисен карарга тиеш дип үстерделәр безне. Ә ул «тиеш» булырга тиеш түгел, ул «тиеш» ярату белән килсен.

**Димәк, сез Сәлимәне: «Син миңа бер стакан су бирергә тиеш», – дип үстермисез?**

– Ул сүзне әйтү башыма да килгәне юк. Баланы Ходайдан сорап алабыз. Аны имездән, тәрбияләүдән без рәхәт табабыз, бала түгел. Без аларны бурычка үстерәбез булып чыгамы инде алайса? Балага гомерлеккә йөк тагып куябызмы? Сәлимә мине караса да, яратып карарга тиеш, һич тә мин аны тудырганга күрә түгел. Әйе, шул ук модель, әмма караш башкача булсын иде.

**Сәлимә – сезнең бердәнбер кызыгыз. Көннәрдән бер көнне башка илгә китәм, дисә...**

– Җибәрәм. Ул бит иреклe кеше. Әгәр анда аңа комачауламасам, бар дөньямны ташлап, мин дә артыннан китә алам. Әмма аны үземә бәйләп куярга теләмим. Балаларыннан хезмәтче ясаган әниләр бар. Дөрес түгел бит инде ул! Баланың тормышына зыян китермәсәм иде дип телим. Дөньяны белеп булмый, Алла сакласын. Әмма бала тормышын үзебезнекенә бәйләп куярга безнең хакыбыз юк.

**Рузилә ханым, сез – милләтче журналист, әмма социаль челтәрләрегездә кызыгыз белән сөйләшүләрне рус телендә язасыз...**

– Аның өчен һәрвакыт сүгәләр инде. Минем бала русча сөйләшә, ләкин ул кирәк чакта татарча сөйләшә ала. Татар мохитендә югалып калмаячак. Кызганыч, балаларга татарча тереләк тәэмин итә алмыйбыз, алар үз ихтыяҗларын рус телендә сөйләшеп тә канәгатьләндерә ала, шуңа татарча сөйләшергә тырышмый да... Әйе, кызыма минем белән татарча гына сөйләш, дип шарт куя алмадым. Бу, бәлки, кимчелегемдер. Минем бит әле аны финанс ягыннан да тәэмин итәсем бар. Димәк, бала белән көне буе татарча сөйләшеп кенә утыра алмыйм. Ә мәктәптә үзегез беләсез нинди мохит. Үземне әнә шулай дип акладым. Мин аның белән – татарча, ул минем белән русча сөйләшә. Сүксәгез сүгәрсез, әмма бу мәсьәләдә принципиаль була алмадым.

Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА

Фото: Анна Арахамия





# ТӨКЛЕ АЯГЫҢ БЕЛӘН!















Лилия
ГӘРӘЕВА

«Төшкән җиреңдә таш бул!» Кияү йортына озатканда өлкәннәр яшь кәләшкә әнә шундый теләк теләгән. Никахыгыз гомерлек булсын дигәнне аңлата ул.

Туй һәм никах – кеше тормышындагы иң истәлекле вакыйгалардан. Хәленә карап, һәркем аны матур итеп, җиренә җиткереп уздырырга тырышкан. Килен төшерүче як мәһәр барласа, кыз бирүче як җиң сызганып туйга әзерләнгән. Туйга кадәр үткәрелгән йолалар – ярәшү, мәһәр, бирнә турындагы язма журналыбызның быелгы март санында дөнья күрде. Бу юлы никах мәҗлесе, туй, килен төшерү, су юлы күрсәтү кебек матур гореф-гадәтләребезне барларбыз.

## *Никах туе*

Туй йолаларының иң мөһим өлешен никах һәм туй алып тора. Никах ул – ике кешенең динебез кануннары нигезендә кушылуы, шаһитлар алдында бер гаилә булып яши башлауларын белдерү. Татарларда элек-электән туй кыз ягында уздырылган. Ул никах уку белән башланып киткән. Никахка кыз ягыннан да, кияү ягыннан да иң якын туганнарны чакырганнар. Кайчак бу тантанада бары тик ир-атлар гына катнашкан, хатын-кызлар чакырылса да, алар өчен табын аерым әзерләнгән. Казан артында хатын-кызларны ир-атлар таралышкач чакырып сыйлау гадәте дә булган. Никахны авылның мулласы укыган. Кагыйдә буларак, яшьләр үзләре әлеге чарада катнашмаган. Кыз келәттә яки башка бүлмәдә утырган, кияү, гомумән, килеп тормаган. Никахка кадәр ике шаһитның кыздан ризалык алуы – шәригать кануны. Әлбәттә, күп вакыт ул бары шулай тиеш булганга гына үтәлгән. Ике яктан да төп вәкил булып егет белән кызның әтиләре, әтиләре булмаса, якын ир туганнары саналган. Соңыннан мулла әлеге никах, мәһәр турындагы мәгълүматларны метрика кенәгәсенә дә теркәп куйган. Никах укылып, мулланы озаткач, туй мәҗлесе башланып киткән. Казан арты татарларында ул күңел ачудан битәр, күбрәк сыйлану рәвешендә узган. Табынга беренче булып итле шулпада пешкән токмачлы аш чыгарганнар. Аннары итле зур бәлештән авыз иткәннәр. Ә менә Пермь һәм Касыйм татарларында, мишәрләрдә, керәшеннәрдә табынга беренче булып чәй биргәннәр. Бәйрәм табынын бал белән май һәм чәкчәк төгәлләгән. Бал-май сакраль мәгънәгә ия – яшьләрнең тормышы майлаган кебек җиңел барсынга, бер-берләренә бал кебек татлы һәм май шикелле йомшак булсынга ишарә. Себердә яшәүче керәшен татарларында туй вакытында учакка бал һәм май сибү гадәте дә яшәгән. Казан арты татарларында исә табынга бал-май чыгару кияү ягыннан килгән кунаклардан акча җыя башлауны белдергән.

Себер татарларында туйларны сый-нигъмәт белән түгел, махсус бию белән башлап җибәргәннәр. Кияү ягыннан килгән кунак егете кыз ягыннан булган туташның бер як иңенә өчпочмаклап төрелгән яулык салган. Алар бер-берләренә иңнәре белән генә кагылып биегән. Биюне өлкәнрәкләр күтәреп алган. Гомумән, Касыйм, Себер татарларында, мишәр, керәшеннәрдә туйлар йолаларга баерак булуы белән аерылып тора.

Кыз ягында туй гадәттә ике-өч көн барган, мөмкинлекләре булганнар берәр атна да бәйрәм иткән. Туйның һәр иртәсе кыз өендә әзерләнгән табын белән башланган. Аннары кунакларны кызның туган-тумачалары үзләренә алдырган. Бу йола туй алдыру дип атала, татар авылларында ул әле дә яши. Биредә дә мул итеп аш-су әзерләнгән, кунаклар өчен мунча ягылган.

Туй барышында үтәлергә тиешле йолаларыбыз да бар. Мәсәлән, кайнана һәм аның якын туганнарын килен белән таныштыру шушы көнне башкарылган. Казан арты татарларында яшь кәләш кунак ханымнарга аш-су, чәй чыгарган. Алар исә, үз чиратларында, аңа акча бүләк иткән. Кайбер җирләрдә, мәсәлән, Казан, Лаеш, Мамадыш өязләрендә кайнана келәттәге кызлар арасыннан үз киленен танып, йөзен ачарга тиеш булган. Килене чәй белән сыйлаганнан соң, аңа беләзек яки тәңкә, алка, калфак ише берәр бүләк биргән.

## *Кияү келәте*

Никах укылганнан соң, яңа өйләнешүчеләр беренче төнне кыз ягында уздырган. Моның өчен махсус бүлмә яки бина әзерләнгән. Чиста, ак келәт булса, яшьләргә урынны шунда әзерләгәннәр. Кияү келәте дигән сүз әнә шуннан калган. Кияү келәте бик матурлап бизәлгән, стеналарга – чигелгән сөлгеләр, караватка чыбылдык эленгән. Кияү белән кәләш йоклыйсы урынны кем җәясен алдан кайгырткannар. Күп җирдә түшәкне кәләшнең тигез тату гаиләдә үскән дус кызлары яки кияүдәге туганнары түшәгән. Урын-җир әзер булгач, аңа улы да, кызы да булган берәр парны яткырганнар. Яшьләрнең дә балалары күп булсын, уллары да, кызлары да тусын дигән нияттән эшләнгән ул. Караватта ир бала тәгәрәтү очраклары да билгеле. Кайчагында кызлар, шаяртып, мендәр астына тәлинкә ише ватыла торган берәр савыт та куеп калдырганнар. Зиһенле булса, кияү мендәрне күтәреп, тәлинкәне алырга тиеш булган.

Кичен ат җигеп, кыз ягыннан вәкил кияүне алырга киткән. Аны берничә дусты яки туганы озата килгән. Кызның энеләре, ишекнең тышкы ягына басып, җизнәләреннән ишек бавы өчен хак сораганнар. «Ишек бавы бер алтын, безнең апа мең алтын», – дигән такмагы да бар аның. Җизнәләре энекәшләргә кызыл саплы пәке бүләк иткән. Туйга бәйле бу йолалар Гомәр Бәшировның «Туган ягым – яшел бишек» әсәрендә бик тәфсилле сурәтләнгән.

Кыз катына кергән кияүне башта чәй белән сыйлаганнар. Үз чиратында ул да ныклап әзерләнгән: аякчуларын

калын итеп урап, читеген тыгызлап кигән, билбавының очын бик тырышып яшергән. Шул рәвешле, булачак хатынын җитезлектә, уңганлыкта сынаган. Сембер губернасында яшәүче мишәрләр арасында кияүне чишендерү йоласы уен-көлке белән узган: кәләш аның бүреген салдырып, үз башына киеп куйган, билбавын чишкәндә аягына басарга тырышкан.

Иртән кияү кәләшенә беләзек яки алка бүләк иткән, урын-җирне җәючеләр өчен дә мендәр астына бүләкләр кыстырып калдырган. Бүләкләрне кияү мунчасын яккан кешеләргә дә әзерләгән ул. Мунчадан кайтышларына яшьләрне чәй табыны белән каршы алганнар. Казан татарлары – сары майда гына кияү коймаклары йөздергән, Әстерхан татарлары уймак кебек кенә итеп кияү пилмәне бөккән, Урал ягында яшәүчеләр челтәрсыман итеп кияү белене кызарткан. Гадәттә, өч-дүрт кич кунгач, егет үз йортына кайтып киткән, кәләше әти-әнисе янында яшәп калган. Атнага бер тапкыр, пәнҗешәмбе кичтән ул кабат кыз йортына куна килгән. Кияүнең болай йөрүе кияүләп йөрү дип аталган. Әлеге гадәтне татарларның күпчелеге саклаган. Әлбәттә, атна саен кияүне кунак итү шактый чыгым да таләп иткән, шунлыктан кияүләп йөрү вакыты гаиләнең матди хәленә карап хәл ителгән. Кайчагында берәр ай, ә кайчак бер ел да дәвам иткән. Кәләшен үз йортына алып кайтканчы, яшьләрнең урамда бергә күренүе гаеп саналган. Рязань, Тамбов өлкәсендә яшәүче татарларда исә яшьләрнең зәфаф төне кияү йортында узган, аларда кияүләп йөрү гадәте булмаган.

## *Килен төшерү*

«Мамык мендәрләргә күмелеп, / Килен төшә бүген авылга...» Эх, күңелләрне җилкендереп, авыл урамына кыңгыраулар чыңы тарала. Июль ае – килен төшерү вакыты. Әлеге матур йоланы гадәттә нәкъ менә шушы айда башкарганнар. Алда – пар ат җигелгән тарантаста – кияү белән кәләш, аның артыннан кәләшнең бирнәсе һәм бүләкләр төялгән ат, аннары – кунакларныкы. Берәү, икәү, өчәү... ак күбеккә баткан җигүле атлар, тузан туздырып, авыл урамына бәреп кергән.

Кәләшне кияү өендә каршы алу да тантаналы итеп оештырылган. Тарантастан төшешенә кәләшне мендәргә яки тунга бастырганнар, аяк астына келәм яки ак тукыма түшәгәннәр. Ул тарантастан берәр терлек-туарга – сарыкка яки бозауга таянып төшәргә тиеш булган. Бусагада кайнанасы киленен бал һәм май белән каршы алган: «Телең бал кебек татлы, холкың май кебек йомшак булсын», – дип теләк телегән. Өйгә кергәч, яшь килен беренче эш итеп чигүле сөлгесен чөйгә элгән (йорт бирнәсе, бусага бирнәсе дип аталган ул), аннары кулын онга батырып, учларын мичкә терәгән, кашык белән шулпа болгаткан. Бу инде яшь кәләшнең шушы йорттагы тормышка катнашып китүен белдергән. Шул ук көнне туган-тумача яшь килен белән танышырга җыелган. Казан татарларында килённең йөзен каплаган яулыгын кайнанасы ачкан, керәшеннәрдә һәм мишәрләрдә бу җаваплы эшне бәләкәй малайга тапшырганнар. Яшь килен хөрмәтенә мәҗлес оештырылган, ә кәләшнең әти-әнисен аерым чакырып кунак иткәннәр.

## *Су юлы күрсәтү*

Туйлар узып, кәләш кияү йортына төшкәннән соң, яшь килен, иңенә көянтә-чиләк салып, чишмәгә яки коега суга килгән. Кияүнең сеңелләре, күрше-тирәдәге яшь кызлар аңа су юлын күрсәткән. Башка авылдан килсә дә, шушы авыл кызы булса да, кияүгә чыкканнан соң беренче тапкыр аны суга ялгызын гына җибәрмәгәннәр. Чишмәдән су алганнан соң, теләк теләп, килен суга көмеш тәңкә салган, ә су юлын күрсәтүче кызларга чәч тасмалары бүләк иткән. Мишәрләрдә яшь килен тәңкә белән бергә, су иясенә атап, икмәк валчыгы да сипкән. Аннары чиләген өч тапкыр суга чумырып алып, шушы су белән битен-күзен юган. Бу йоланы башкаргач, аның йөзе көләч, күзләре балкып торачак дип ышанганнар. Урал буе татарларында исә яшь килен су буенда изүеннән тәңкә алып, берәр балага бүләк иткән. Казан артында яшәүче татарларда чишмәдән су алгач, яшь киленнең суыннан беренче булып иң өлкән кеше авыз иткән. Парлы гомер итсеннәр, тигезлектә яшәсеннәр өчен, суны ике чиләктән дә тигез йоткан ул. Авылның яше-карты урамга чыгып, яшь киленне күреп, танышып калырга тырышкан. Яшьләргә матур теләкләр телегәннәр, бәхет юраганнар.

Өйләргә су кергәннән соң, бу йола берара онытыла төшкән иде, хәзер аны яңадан тормышка кайтарып, үтәргә тырышалар. Авыл урамнарын гармун тавышына, җыр-моңга тутырып, яшьләрнең чишмәгә барулары бик матур күренеш бит.

## *Килен токмачы*

Килен төшергәннән соң, икенче көнне яки берничә көннән күрше-тирәдәге хатын-кызлар, туган-тумача мәҗлескә чакырылган. Казан артының Арча, Әтнә, Биектау районнарында бу йоланы «килен токмачы» дип атыйлар. «Килен коймагы», «килен боткасы» дигән атамалары да бар. Бу көнне яшь килен камыр басып, токмач кискән. Шушы токмачтан аш пешереп, кунакларны сыйлаганнар. Токмачны нәзек итеп кисә беләме, аш-суы уңганмы – киленне уңганлыкта, булганлыкта сынаганнар. Туйда катнаша алмаган күршеләрне, туганнарны яшь килен белән таныштыру чарасы да ул «килен токмачы».

Туйлар узып, ыгы-зыгы бераз кимегәннән соң, кызның әти-әнисе яшьләрне үзләренә кунакка алдырган. Кайчагында кода-кодагыйларны да чакырганнар. Алар хөрмәтенә төчегә генә тәбикмәк пешерелгән. Кияү тәбикмәктән авыз итеп, тәлинкәгә акча салып калдырган. Кунак вакыты ике яки дүрт көнгә сузылган. Моңарчы яшь килен әти-әнисе йортына ялгызы гына килә алмаган булса, әлеге йоланы башкарганнан соң, ул инде үзе телəгән вакытта килеп, хәлләрен белешкән. Әтисе йортында аны иң кадерле кунак итеп каршы алганнар.

Менә тагын июль ае – туйлар чоры җитте. Җигүле атларны инде машиналар алыштырса да, әле бүген дә яшь киленнәрне ак мендәргә бастырып, бал-май белән каршы алалар. Чорлар алышына, матур гадәтләр кала.

Язмада Флера Баязитова һәм Рәүфә Уразмановaның хезмәтләре файдаланылды.

Автор фотолары



« Видео: Фәгыйлә Шакирова. Фото һәм видеода: Арча районы Кышкар авылыннан Гөлшат һәм Ильяс Гәрәевләрнең туй мизгелләре.




# ТУЙМАЗЫДА ҖЫРЛАДЫК ӘЛЕ!

Россиянең төрле төбәкләрендә яшәп иҗат итүче татар фольклор ансамбльләре бу көннәрдә янәдән Башкортстанның Туймазы районына – «Бабай утары» этнографик музей комплексына җыелды. Сәбәбе күптән билгеле – Бөтендөнья татар конгрессы ярдәме белән узучы «Җырлыйк әле!» татар үзешчән фольклор ансамбльләре фестивале быел үзенең бишенче һәм шул ук вакытта беренче юбилей бәйгесен оештырды. Бу проектның идея авторы, «Ак калфак» Башкортстан төбәк татар хатын-кызлары иҗтимагый оешмасы җитәкчесе Люция ханым Вафина: «Елдан-ел популярлыгы артып килүче фестивальнең даны инде күптән Россия чикләрен узып, дөньякүләм таралырга өлгерде», – ди. Шушы бишьеллыгын фестиваль халыкара статуста каршы ала дип әйтү дә артык булмас. Казакъстаннан килгән ансамбль – моның ачык дәлиле.

Фестивальнең беренче көнендә, традиция буенча, Башкортстаннан килгән иҗат коллективлары үзара ярышты. Гран-при яулаган коллектив – Бишбүләк районыннан «Ак калфак» халык фольклор ансамбле – бәйгенең икенче көнендә төрле төбәкләрдән килгән кунаклар белән көч сынашты. Дүрт ел дәвамында Гран-прига лаек булган коллективлар катнашында милли костюмнар парады да бәйрәм күрке булды. Бу киемнәр – Бөтендөнья татар конгрессының җиңүчеләргә ясаган бүләге. Күз явын алырлык милли киемнәр ничек килешә үзләренә!

Күңел кылларын тибрәтерлек халык моңнарын, төрле җирлекләрнең буыннан-буынга күчеп килгән гореф-гадәтләрен үзенчәлекле итеп тамашычыга да, мәртәбәле жюрига да җиткерүче ансамбльләр арасыннан җиңүчене сайлап алу җиңел булмады, әлбәттә. Шулай итеп, фестивальнең беренче юбилей җыенында җиңүче дип Оренбургның «Ләйсән» халык вокал ансамбле танылды. Бүләкне аларга Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шура рәисе беренче урынбасары – Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты җитәкчесе Данис Шакиров тапшырды.

Фото: Анна Арахамия










Килен һәм кайнана… Ике арадагы мөнәсәбәтләрнең матурлыгы, ныклыгы, якынлыгы күбрәк кемнең зирәклегенә, акылына, тырышлыгына бәйләнгән? Ирењнең әнисе үзеңнекеннән тары ярмасы кадәр генә ким булырга тиеш, диелгән динебездә. Ә менә сез моңа ничек ирештегез? Нинди сынаулар, нинди юллар аша уздыгыз? Сөйләгез әле! Башкаларга – бигрәк тә яшьләргә гыйбрәт, сабак, үрнәк итеп сөйләгез.

«Сөембикә» журналы белән берлектә Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен үстерү мәсьәләләре комиссиясе «Килен һәм кайнана» дигән хатлар конкурсы игълан итә. Ул ел дәвамында барачак, һәм аларның иң әчтәлеклеләре журнал битләрендә урын алачак. Сездән хатлар көтеп калабыз!

# МӘХӘББӘТЛЕ ОЯ



Фото: Анна Арахамия

**Әти әнине ярата! Юк, алай түгел – алар бер-берсен яраталар! Безнең – киленнәрнең һәркайсы бу нигезгә аяк басып, бераз яшәүгә ачкан яңалык бу. Шулай бит ул: чит күз белән караганда гел күбрәк күренә… Әйе, безнең хәләлләребез ир-ат белән хатын-кыз арасындагы яратуның нинди булганлыгын күреп, гаиләдә яратуны тоеп үскән. Әни үзе әйтмешли – «мәхәббәтле оя»да! Сигезәү алар – алты ир бала һәм ике кыз. Һәркайсы берне алып, бергә барып – бер белән гомер итә. Әнинең яратуы безгә – киленнәренә дә мулдан. Аның белән һәркайсыбызны ихлас, әчкерсез мөнәсәбәтләр бәйли. Бу юлларга кушылып, биш килененең бишесе дә шулай дияр иде.**

### *Эльмира*

Мин – әнинең иң беренче килене. Без өйләнешкәндә Ринатка 28 яшь иде. Ирем генә түгел, калган туганнарының берсе дә ашыгып башлы-күзле булмады. Башта эшләделәр, аякка бастылар, йортлар, машиналар алдылар, аннары гына әти белән әнигә кайтып: «Өйләнергә җыенам», – диделәр. Бу нигездә һәр туй турында шулай бер атна гына алдан белделәр. Әти белән әнинең үзләреннән үк шулай башланган ул. Сүз уңаеннан, кавышу тарихлары бик кызык – аларны… җырчы Усман Әлмиев таныштыра. Кайнатам Ризаэтдиннең армиядән кайткан көннәре генә була. Безнең Кошманда концерт куйганнан соң, егетләр артистны олау белән Чәчкаб авылына озата китәләр. Әти дә аларга утырып бара. Чәчкабтан ерак түгел бер авылда аның сөйләшеп йөргән кызы була: ул шуны күреп кайтырга ниятли. Усман Әлмиев исә Саимә әниләрнең күршеләренә фатирга керә. Әти белән әни шунда бер-берсен беренче тапкыр күрәләр. Үзе белән юл буе сөйләшеп килгән Ризаэтдин әтигә Усман Әлмиев ул чакта ниләр әйткәндер, әмма егет ул кичне Чәчкабта куна кала – концерттан соң Саимә әнине озата кайта. Ике атнадан инде алар өйләнешәләр, тагын бер атнадан туйлары була. Ул чакта гадәттә киленнәрне яртышар ел эшләткәннән соң гына туйлар ясаганнар әле… Үз әнием ул чакта бала гына булса да, аларның туйларын хәтерли. Әкрам бабам-

нар туйны чәйгә алганнар. «Мич башы кырына тезелеп, Риза абый нинди матур апаны алган, дип карап утырдык», – дип сөйли әни. Безнең әни үзе дә кайнанасы белән бер тапкыр сүзгә килмәде: эти үлгәч тә алар бергә яшәделәр.

Бер авылдан булгач, Саимә әни белән, әлбәттә, очрашкан-күрешкән бар иде. Әмма монысы башка бит аның... Иртәгә туй буласы көнне кичтән сеңлем белән Ринатларга өй киендерергә төштек: тәрәзәләргә яңа челтәр-пәрдәләр элеп менәргә. И-и, куркыта, каушата, ояльдырта... Ишек бавына тотынган гына идем, ишек ачылып китте. Теге яктан әни чыгып килә икән. Кулында табак белән он. «Әйдә, кер, кер, иң яраткан киленем булырсың!» – диде ул шунда. Искә төшерсәм, хәзер дә күңелем тула. Ят йортка аяк баскан кыз бала өчен шулкадәр дә җылы сүзләр булган бит болар...

Алар йортта унберәү иде, мин уникенче булып килдем. Шулкадәр тиз ияләштем! Беренчедән, Ринатның сеңлесе Миләүшә белән без классташлар – өйдә тагын бер якын кешем бар дигән сүз. Икенчедән, әни миңа карата беренче көннән үк бик җылы булды. Декрет ялына чыкканчы Казанда тордым әле. Бер атна эшлим, бер атна авылга кайтып торам. Үзебезнең Югары Кошманга борыласы юлны узып китәм дә, туп-туры Ринатларга барып керәм. Иремнең өйдә юклыгын да беләм югыйсә – ул читкә, урман эшенә чыгып киткән чак иде. Туры алар капкасын ачып керүемә кайнанам бик сөенә иде... И-и, кайткан җиремә җыеналар: юалар, җыялар, пешерәләр-төшерәләр – миңа бер эш калдырмыйлар. Кечерәкләр өчен беренче көннән «дәү апа» булдым. Мин килгәндә Гүзәл 6 нчы класста укый. Гел онытылмый: икәү суга барырга чыктык шулай. Күршедәге дус кызына: «Синең дә шундый дәү апаң булсын идеме, Мәдинә?» – диде ул. Яратуы, якын итүе әллә кайдан сизелә! Әни аларны шулай көйләп куйган бит... Кайнанамның әнисе – дәү әни Ринатның зуррак энеләренә дә миңа «дәү апа» дип әйтергә куша иде, ә тегеләре көлә: «Ничек «апа» диик, ул бит бездән кечерәк», – диләр.

Ярты елдан соң Марат «өйләнәм» диде. Аннары Миләүшә кияүгә чыкты, аннары Айрат өйләнде... Ике елга дүрт туй! Берсенә дә: «Азрак сабыр итегез», – димәделәр. Әни бик хәстәрле кеше ул, шуңа күрә атна эчендә туй ясау аңа берни тормый. Безнең туйга табынга куйган җебетеп әзерләгән алмаларын әле дә онытмыйлар. Кисмәк-кисмәк ясап куйган булган.

Бала тугач та әниләрдә ун ай тордык әле. Бу вакытта Сәвия килендәш тә килгән иде инде. Безнең әни бик озак вакытлар гел шулай икешәр килен белән яшәде... Иртән торгач, әни белән өйдәгеләрнең бөтенесен кайсын кая озатабыз, аннан ул: «Кызым, әйдә, иркенләп чәй эчеп алабыз», – дия иде. Шуннан соң гына эшкә тотынабыз. Гаилә зур бит – кунак табыны кадәр өстәл тора иде өйдә. Килгән һәр киленнең анда үз урыны булды, һәм ул урынга берсе дә утырмый иде. Әни беребезне дә аермый – һәммәбезне бертигез якын күрә. Киленнәр күп бит инде. Яңасы килгән саен, авылда: «Монысы ничек?» – дип сорыйлар икән. «Әйбәт!» – дип җавап биргән ул. «Сиңа гына гел әйбәтләр килә инде!» – диләр икән. «Улларым бәхетле икән – мин дә бәхетле», – ди әни. Аның кебек кайнана булырга насыйп итсен: синең кәефең юк чакта дәшми кала белә. Ул һәрвакыт киленнәр яклы. «Бер сүз әйттермисең, алар түгел, без бит синең улларың», – дип ирләребез кайчак үпкәләп тә куя. «Килен-кияүләрегезгә карата йомшаграк булыгыз. Сүз ярасы салып, кешенең кадерле баласының хәтерен калдырмагыз. Кайчакта әйтәсе килгәнне дә әйтмәгез – шулай яхшырак булыр. Пәйгамбәребез дә дәшмәскә кушкан», – дип киңәш бирә ул безгә. Әни үзе нәкъ шулай яшәде! «Мин үзем дә кайчандыр килен булган кеше ләбаса», – ди.

Уллары кемне сайлады – һәрберсен яратып кабул итте әни. Кайбер киленнәрен сорарга баргач кына күрде. Илшатның Эльвирасына 18 яшь кенә иде. Шәһәр кызы – күбрәк русча сөйләшә. «Кызым, мин русча белмим, син татарча өйрәнерсең инде, яме», – диде аңа әни җайлап кына. Ул килендәшебез татарча чын әдәби телдә генә сөйләшә хәзер әнә. Авылны да яратты – гел кайтып йөри. Гөлфия килендәшебезне Айрат Мәскәүдән үк алып кайтты. Үзебезнең авыл кызы, әмма өйдән япь-яшь килеш чыгып киткән ул. «Мин әни янына кайтып кына эшкә өйрәндем», – ди Гөлфия.

Без бу йортка килгәндә дәү әни – кайнанамның әнисе дә исән иде әле. Кияве белән 27 ел яшәгән ул. Риза әти үзләренә бөтенләйгә күчеп килергә үгетләгәндә аңа әле 57 яшь кенә булган. Туганнарына кунакка барганда да: «Балаларны сагындым», – дип, кире кайта торган булган. Безнең әни дә шулай: Алинә белән Илнурның өч баласы мәктәптән, балалар бакчасыннан кайтканны да сагынып көтеп тора.

Әни кебек үк, эти дә безнең һәркайсыбызга «кызым» дип дәште. Нинди йомышыбыз төшсә дә, шунда ук үти иде ул. Әнигә дә һәр эшендә булышырга гына тора иде. Алар гомер буе бөтен эшне шулай бергә эшләгәннәр, барасы җиргә бергә йөргәннәр. Эти беркайчан әнигә авыр сүз әйтмәгән, тавыш күтәрмәгән. Илле елдан артык бик матур гомер иттеләр алар. Тату, дус булып!

### *Сәвия*

Мин бу нигезнең бусагасын беренче тапкыр 1989 елның август аенда атлап уздым. Ирем Марат аларның икенче уллары. Без әни белән икебез дә бер авылдан – Чәчкабтан. Кошманга колхоз идарәсенә бухгалтер булып эшкә килгән идем. Менә шушы тырыш, булдыклы, тату нигезгә килен булып төшәргә дә насыйп иткән икән... Башка чыккан киленнәр арасында төп йортта иң озак яшәүчесе мин булдым. Әле үзебезгә күчкәч тә, баламны күтәреп көн саен әниләргә килә идем. Рәхәт җиргә генә киләсең бит ул... Килендәшләрнең үзара дус кызлар, хәтта бертуганнар кебек якын булуында әнинең өлеше бик зур. Мин килен булып төшкәнгә 33 ел була менә – ялгышып та сүзгә килгәнебез юк. Иң кече килендәшебез – төп йортта яшәүче Алинәне кызыбыз кебек күрәбез. Безне бергә җыю, очраштыру өчен гел нинди дә булса сәбәп табып кына торды әни. Чакыра һәм якын кунакларын көткән кебек табын белән каршы ала иде. Килендәшләр бер-берсе белән якын булса, ир туганнар арасына да киртә үсми бит...



Безнең әни бик зирәк хатын: балаларын эш белән тәрбияләгән. Аларның берсе дә гомерен әрәмгә үткәрми. Һәркайсы тырыш, һәрберсенең үз эше бар. Бездә, гомумән, бөтен кеше ике эштә эшли... Тормышны алып баручы ирләр үстергән өчен без әнигә ничек рәхмәтле булмыйк ди?! Алар гомер буе әти белән әни сүзеннән чыкмады, бүген дә әни киңәше белән яшиләр. Бер борчуны да әнигә белгертмәскә тырыштылар. «Әнигә әйтеп тормагыз», – диләр иде. Әнинең 80 яшьлек юбилеен да аңа бүләк итеп оештырдылар. Балаларга без дә шундый ук тәрбия бирә алсак иде дип хыялландым мин үзем. Хәер, алар барысын да күреп, сеңдереп үстеләр. Каядыр барырга кирәк булса – эш белән, ялга яки кунаккамы – әни безнең балаларны һәрвакыт берсүзсез алып калды. «Баланы кайда калдырып торыйм икән?» дигән проблема беребездә дә булмады.

Әни белән бөтен шатлыклар уртак безнең. Хәер, хәсрәтә... Әти белән әнигә язмыш кайгыларны да тигез итеп бүлеп биргән. Әтисе белән энесе буранда адашып үлгәннәр әтинең. Әнинең әтисе сугыштан кайтмаган, бердәнбер энесе 19 яшендә сукыр эчәгесе шартлап үлеп киткән. Аларга уллары Рамил хәсрәте кушылды менә... Армиядән кайтканына бер генә атна иде. Сөлек кебек егет! Кеше кулыннан фаҗигале төстә гомере өзелде аның. Елыйелый әнинең күзләре начарайды. Әтинең йөрәге дә шул кайгыны күтәрә алмады...

### *Алинә*

Төп йортта яшәячәгемне белеп килдем, әлбәттә. Үз әнием дә бик озак вакытлар кайнана-кайната белән яшәде. «Алар каядыр китсә, өй буш кала», – дия иде. Бабай безне мәктәптән килеп үк ала иде, ә әби кайткан җиребезгә ашарга пешереп куя – әнигә дә рәхәт булгандыр. Өйдә олы кеше бар икән, балалар караулы дигән сүз. Менә без дә теләгән вакытыбызда концерт-театрларга да, кунакка да китеп бара алабыз – ул яктан җаныбыз тыныч.

Әни әтигә: «Малайларның калганнары башка чыкты, Риза. Төпчеген дә көчләмик: торасы килгән кадәр янибызда торырлар, чыгабыз дип әйтсәләр, каршы килмик», – дигән булган. Безнең Илнур белән андый теләгебез булмады.

Килен булып төшкәч кабат укырга кердем – югары белем алдым. Рәхмәт, сессияләргә бер авырлыксыз чыгарып җибәрде әни.

Яшьли килдем бит – күп эшкә әнидән өйрәндем. Кияүгә чыкканчы ипи салып караган кеше дә түгел идем: ул елларда җир пайларына I сорт он бирделәр – ипине гел үзебез салдык. Элек һәрьюлы тугызарны сала идем, дип сөйли әни. Камырга бик уңган ул безнең.

Төп йорттан кеше өзелми, авырдыр дип уйлый күп кеше. Мин авырлыгын тойганым юк. Бездә тәртип шулай куелган: бөтен эшне килендәшләр бергә җыелып күмәкләшеп эшлибез. Ул миңа кадәр дә шулай булган, мин килгәч тә үзгәрмәде. Язын өйне бергә юабыз, бәрәңге утыртабыз, чүпләрен утыйбыз, алабыз... Сөйләшә-сөйләшә эшләү шундый рәхәт безгә! Әти исән чакта ул көнне мунча яга иде, зур казанда аш пешерәбез, әни камыр куя... Балаларны да әни карап тора. Элек сарык йонын да бергә ала идек, хәзер инде машинабыз бар – үзем дә шактый остардым.

Аш-мәҗлесләрне дә бергә-бергә үткәрәбез: килендәшләрем соңыннан өстәлләрне чыгарып, савыт-сабаны юып, урнаштырырга да булышалар. Төп йорт килененә генә салыну юк бездә! Татулыгыбызга иң сөенгән кеше, әлбәттә, әни!

Бездә бер матур гадәт бар: соңыннан бәйрәмне үз өйләрендә каршыласалар да, Яңа ел кичендә бөтен кеше төп нигездә – әни янына җыела. Бу – язылмаган бер кагыйдә кебек. Китапханәдә эшләгәч, мин генә клубка иртәрәк китеп барам: авылда Яңа ел чыршысын без үткәрәбез бит.

Ураза, Корбан гаетләрендә дә шулай җыелабыз. Элек әти исән чакта абыйлар башта барысы да туры безгә килгән, аннан мәчеткә киткәннәр. Хәзер исә һәркем мәчеттә очраша да, гает намазыннан соң безгә кайта. Аларны зур табын әзерләп көтәбез.

Кайнана белән яшәгән киленнән: «Ә сездә акча кем кулында?» – дип сорау гадәте бар. Без Илнур белән башта акчаларны әнигә кайтарып биргән идек. Аннан карыйм – ничек кайтарып биргән, акча шул килеш тора. Илнур кебек үк безнең абыйлар барысы да соң гына башлы-күзле булган. Өйләнгәнче алар акчаларын әнигә кайтарып бирә торган булганнар, ә өйләнгән көннән башлап үзләре тоткаННар. Кем күпме кайтарган – һәрберсен аерым дәфтәргә язып барган әни. Банк кебек булган. Алар барысы да башка чыгасы кешеләр – үзләренә кирәк булачак, дип, ул акчаларның бер тиененә дә кагылмаган. «Терлек-туарны гомер-гомергә күп асрадык, үзебезнеке үзебезгә җитә иде», – ди. Марат абый бер җәйдә эшләп мотоцикл, икенчесендә машина алган. Аннан: «Әй, ашыктым, апалар янында йорт саталар – шуңа бик кызыктым», – дигән. Ә әни шул вакыт: «Синең акчаң бар бит», – дип, аңа үзе кайтарган акчаларны чыгарып биргән. Туйларында бөтен абыйларны шулай шаккатырган ул.

Тагын бер нәрсә бар: безнең ирләребез беркайчан да балаларны тавыш күтәреп ачуланмыйлар. Әмма аларның һәрберсе: «Әти ни әйтер?» – дип тора. Илнур: «Әти дә безгә бер генә карый иде», – дип сөйли. Бу да әни тәрбиясе!

Эльмира, Сәвия, Алинә САДРИЕВАлар.
Кайбыч районы,
Кошман авылы.

# ГАИЛӘ



Марат КӘБИРОВ, язучы

## мин шулай уйлыйм

Бер күршем бар минем. Ихлас шундый, самими. Миннән күпкә яшьрәк инде, утыздан өстә генә. Әллә кайдан сәлам биреп тора. Аның исәнләшүе дә гади генә түгел. Хәер, гади инде. Сүзләре гади. Ә балкып торуы гади түгел, «Сәлам, Марат абый, хәлләр ничек?» – дип килеп күрешүе үзе бер тылсым кебек тоела. Ул шундый якты, ягымлы, ихлас. Аның белән исәнләшүдән генә дә мин үземнең моң-зарларымны онытам. Мин дә яктырып калам. Тормыш бөтенләй икенче булып тоела. Дөньяның шундый саф күңелле кешеләре дә бар бит, мин шулар арасында яшим бит дип уйлыйм. Моны тоюдан күңелгә нур бөркелә. Дөнья яктырып китә. Тормыш матур булып күренә.

Бер мәлне теге егеткә әллә нәрсә булды. Мин кичкырын кайтам, бу подъезд алдында сыра эчеп тора. Подъезд алдында сыра эчүчеләр мәңге бетми инде ул. Пенсионерлар дөнья хәлләрен сөйләшә, ачыган алкашлар да булгалый, болай гына, эш көненнән соң йомшарып алучылар да очрый. Ә бу егетне шулар арасында күрү минем өчен гаҗәп тоелды. Алай гына түгел бит әле. Ул минем белән элеккечә якты итеп килеп күрешә, хәлләрне белешә, сыйларга тели. Мин эчүдән баш тартам. Ул кыстарга тырыша:

– Әйдә инде, аз гына, Марат абый…

Мин үземне фәрештә дип уйламыйм инде. Салган чаклар да булгалый. Салудан бигрәк, эчү турында язылган әсәрләрем күп. Шуңа кайберәүләр: «Ул эчәргә ярата», – дип, дан чыгарырга да тырыша. Яратам. Ләкин үземә кирәк чакта. Ә болай… Бу егетнең сүзләре мине уйланырга гына мәҗбүр итә. Эшендә бик яхшылар исәбендә булган, һәрвакыт балкып торган егет ник әле шулай – көн саен сыра чөмерүчеләр армиясенә килеп кушылды икән?

Сәбәбе гади генә булып чыкты. Гаиләсе белән бозылышканнар икән. Юк, бозылышып кына калмаганнар, аерылышканнар. Үзе әйтте.

Мин башта аңлый алмыйчарак тордым. Ул балалары белән шулкадәр ихлас итеп уйный, үзе дә балага әйләнгән кебек тоела. Минем бу уенны балалар мәйданчыгында сокланып күзәткәнем бар иде. Хатыны белән шулкадәр әйбәт мөнәсәбәттә, пар күгәрченнәр кебек дип әйтәм инде, бүтән чагыштыру башка килми, гөрләшеп кенә торалар.
Үзе дә көненә әллә ничә кабат тулы пакетлар күтәреп өенә кайта. Монысын мин аеруча хөрмәт итәм, чөнки үзем дә шундыйрак – суыткычны ирләр тутырырга тиеш, шунда гына хатыннар тәмле ризык әзерли ала дип уйлыйм.

Менә шундый асыл ир хатыныннан аерылган.
Бер атна тирәсе подъезд алдында сыра чөмерде бу. Мин аны кулымнан килгәнчә юатырга тырыштым:

– Бетеренмә болай. Юкка чыгарма үзеңне. Балаларыңны кара.

Ә ул моңсу гына каршы төште:

– Балалар белән күрешергә дә рөхсәте юк әле… Сагындым шундый…

Соңыннан эчүен ташлады. Элеккечә исәнләшеп йөрсә дә, һәр хәрәкәтендә ниндидер моңсулык, адашкан кешедәгечә таркаулык бар иде. Эшенә бара, кайта, тәмәке тартып торабыз. Мин аны юаткан булам. Киңәшләр биргән булам. Өметеңне өзмә әле, хыянәт итешмәгәнсез бит, яңадан тормыш көйләүгә дә мөмкинлек чыгар әле, дим. Юатуның файдасы юк инде мондый чакларда. Син үзеңне тарихсыз калган халык, үткәне җуелган шәхес кебек тоясың. Җуелган да түгел хәтта, үткәненең бөтен мәгънәсе сыгып алынган кебек. И-и, ул халәтне берничек тә аңлап та, аңлатып та булмый…

Беркадәр гомер узды. Мин авылга кайтып озак кына торып килдем. Теге егет күренмәде. Ә бер мәлне… Ә бер мәлне ул Казан урамында минем яннан узып барган җирдән машинасын туктатып яныма килде. Балкып килә шундый: колачлары җәелгән, күзләрендә – очкын, йөзендә – елмаю.

– Марат абый, сәлам! Хәлләрең ничек? Без бит бергә яши башладык. Гаилә белән. Синең киңәшләреңне тоттым мин. Әйбәт килеп чыкты. Хәзер без бергә. И-и Марат абый, рәхмәт сиңа!

Минем дөньям теге вакытлардагы кебек балкып китте. Тормыш матур булып күренде. Тик мин үземнең нинди киңәшләрем белән ярдәм иткәнемне генә аңлый алмадым. Әйе, мин аның яклы идем. Чит хатынга карамасын, үз гаиләсенә ачкыч тапсын дип уйлый идем. Үз хатының, үз балаларың белән яшәү әйбәт бит инде ул. Бу хакта әйткәнмендер инде, бәлки. Тик ул нибары сүз генә бит… Ләкин аны минем сүзләрем түгел, ә кабат үз гаиләсе белән яши башлавы балкыта иде. Үз гаиләң үз гаиләң инде ул. Яратып өйләнгән хатының, мәхәббәттән туган балаларың… Мин һәркемгә шундый бәхет телим. Бәхетле кешеләрнең нуры кемгәдер төшми калмый ул...

Ул – рәссам, шагыйрә. Иҗаты – космос... Питерда яшәп, татар халкына хезмәт итә: Ватан темасы, туган җирне ярату хисләре шигъриятендә кызыл җеп булып сузыла. Анда фәлсәфә дә, рух тантанасы да, лиризм да бар. Петербург циклы аерым бер җылылык, лиризм белән өртелгән. Шигырьләреннән затлылык, тирәнлек бөркелә. Бу көннәрдә үзенең 70 яшьлек юбилеен билгеләп үтүче Баулы кызы Халидә Гыйләҗева – Төньяк башкалабыздагы илчебез, үз кешебез ул. Ире – рәссам Рәшит Гыйләҗев белән берлектә Санкт-Петербургның Васильев утравындагы квартира-галереясында дистә елдан артык инде «Гыйләҗев пәнҗешәмбеләре» уздыралар: шагыйрьләрне, музыкантларны, рәссамнарны җыялар. Әлеге проект татар халкының мәдәниятен һәм сәнгатен популярлаштыруга хезмәт итә. Халидә ханымны күркәм юбилее белән котлыйбыз. Иҗатында, тормышында зур уңышлар телибез!



Халидә ГЫЙЛӘҖЕВА

# «КИЕК КАЗЛАР ЮЛЫ БУЙЛАП ОЧАМ...»

## *Ике көч*

Аллаһтан иңгән ике көч
Җәфалый, талкый мине.
Берсе күкләргә күтәрә,
Берсе тырмата җирне.

Моңнар – салават күперем,
Сарай корам җырымнан.
Бакчамда үлән туй итә,
Мич сер көтә кулымнан.

* * *

Ташка бәрелеп Нева чайкала:
Йолдызлык, гасырлар чагыла.
Казан һәм Петербург язмышны
Тарихка үрәләр сак кына.

Йөрәгем сызлавы басылмый
Иң татлы төшләрдән, хыялдан.
Мин ана арыслан шикелле
Сабырлык төсенә буянган.

«Адмиралтейск инәсе» нур чәчә,
Фәрештә канаты тигәндәй.
Киләләр, китәләр бу җиргә,
Ә тарих кала шул дигәндәй.

Нева да чайкала, суларда
Сарайлар, гөмбәзләр чагыла.
...Ә хәтер бабамнар каберен
Зиярәт итмәкче сак кына.

* * *

Мин мәңгелек ишегенә
кагылдым беркөн,
Әнкәмне алып,
март ае да югалтты күркен.

...Ул җирнеке түгел инде,
яктылык кына,
Тик җанымда яши көн күк,
яктырып кына.

Яфрак кыштырдавы булып,
кошлар моңы күк...
Әткәм йорты!
Баулы җәе – әнкәм тыны күк.

Ә тавышы кайлардадыр,
югары, өстә...
Мин яратам сине, әни!
Син мәңге истә!

## *Йокы алмый мине*

Питерымда йокы алмый мине,
Күңелемдә шигырь бөреләнә.
Һәрбер сүзнең яңгырашын тоям,
Уйлар бөтерелә башта янә.

Чыклы ярдан шуышкан карашларның
Әллә кая барып җиткән мәле.
Гөмбәзләргә бәрелә-бәрелә үтәм:
Питерым да уяу икән әле.

Аһ, туктале, төн бит урамымда,
Шигърият, син кая илтәсең, йә?
Сфинкслар күзәткән йөрәгемә
Бу дөньяның сере бикләнсен лә...

## *Ышанамын*

Акча туплап кына рәхәт килмәс,
Кеше малын, хәер, ник саныйм, ди.
Гамәлләрен ир-ат яхшылыкка
Юнәлтмәсә, ничек ышаныйм, ди.

Күкрәүләргә ышанамын, җирне
Дер селкетеп үтсә, икмәкле итсә.
Явызлыкка түгел, могҗизага
Ышанамын, мәхәббәткә илтсә.

* * *

Сүзләрнең аһәңен ишетәм,
Догалар шикелле тезелә.
Аллаһның күзләрен күрәм күк,
Яуда әҗәл якында – сизелә.

...Йолдызың булырмын мин синең,
Буйларың җитмәслек берничек.
Үземне югалтмам һичкайчан,
Күкләрне үтсәм дә мең кичеп.

Сүзләрнең аһәңен җыр итәм –
Догалар шикелле тезәмен.
Аллаһның күзләрен күрәм күк
Кичкәндә үлемнең үзенен.

Үземне таныймын, таңнарда
Тынлыкны тыңлыйм да сөйләшәм.
«Шагыйрә булыплар яшәве
Бик рәхәт ласа!» – дип эндәшәм.

Сүзләрнең аһәңен ишетәм,
Догалар тезәм күк таңнарда.
Аллаһның күзләрен күрәмен –
Бакыйлык лаеклы Аңарга!

## *Хыял нурлары*

Әй, Кояш!
Яктырт шәһәремне хыялым күк
Һәм тормышны әкият итсәнә!
Әти-әниемне кайтар миңа,
Әйтә күрмә берүк: «Китсәнә...»

Әй, Күк!
Тауларны коч, әйдә, күкрәгеңә,
Балачакка мине кайтар да.
Баулым белән туганлаштыр берүк,
Шаккатсыннар хәтта ятлар да.

Әй, Йолдызлар!
Мин яшәгән еллар, гүзәл чорлар –
Сөю китабының битләре.
Киек казлар юлы буйлап очам,
Бармы илгәзәклек чикләре?..

**Фирүзә ҖАМАЛЕТДИНОВА**
**тәрҗемәләре**

* * *

Караңгылык, тынлык кына сөйләр
Синең хакта миңа – күнектем...
Яфрак сөйләр миңа синең хакта –
Мең хәбәрләр синнән мин көттем.

Өрәңгеләр шаулар синең хакта
Сулкылдаган чакта бу йөрәк –
Шушы шигырь ишетелсен сиңа:
Тап мине син! Тап син тизрәк!

Юк, бик еракта да түгел бит мин,
Ялгызлыкны уртак бүлеште –
Йөрәк янында мин гомер иттем,
Шунда калу миңа тиешле...

* * *

Кузгала хәтер...
Нур сыман ява –
Саф, аяз күкләр изге дөньяга...
Мин керәм сыман аяз һавага –
Сәламең булып якты нур тама.
Без икәү гүя дөнья алдында –
Ни булды миңа?
Ни булды миңа?

* * *

*Ни генә кыланмый Ходай –*
*Суны бар итә уттан –*
*Мәгънәсен һич аңламыйча*
*Китәбез дөньялыктан.*
Гомәр Хәйям.

Күрче, Ходам, шушы дөньялыкны! –
Тулы җан юк – алар яртылаш...
Адәм заты Җирдә сөю эзли,
Бу хис – алар өчен бер кояш!

Мин хатын-кыз булып Җиргә килдем,
Теләгәндер шулай бу Ходай –
Ярты гомеремне сиңа бирәм,
Минсез гомерең булыр урталай.

Аерылып яшәү язган икән,
Таба алмассың ла син мине –
Синең урынында – бушлыгымда
Яшәтәм мин изге шигырьне.

Күрче, Ходам, шушы дөньялыкны!
Тулы җан юк – алар яртылаш!..
Адәм заты Җирдә сөю эзли,
Бу хис – алар өчен бер кояш.

* * *

Канатлысын сүзнең мин табармын –
Үз канатым сына күрмәсен;
Ышанырмын бары мәхәббәткә –
Ялган-гайбәт инде йөрмәсен!

Мин яшәрмен бары шигырь белән! –
Алтын чыңы яннан кит, олак!
Тәңрем, Сиңа дәшәм кешеләрне,
Булсаң да син бездән бик ерак...

Авыр чакта сүзләр шигырь булыр,
Шулар булыр миңа юаныч –
Югалмасын шушы йөрәгемдә
Мәхәббәткә булган ышаныч.

* * *

«...*Тәннең һәм хиснең серле*
*кануннары тормышыбызны*
*үз ихтыярына күндергән*
*шикелле үк, иҗатыбызны да*
*үзенә күндерә...»*
Оноре де Бальзак

Күрешүләр насыйп булмый калса
Дөньялыкта – уят хыялыңны!
...Без бергә бит! Күзләремә кара!
Мин сыйпармын кайнар толымыңны,
Хәтта хыялда да очрашмас хәл килсә,
Очрашырбыз төшләр күргән чакта.

Югалтуның көчен үзем җиңдем,
Исән калдым янып тере утта.
Язганымның һәрбер сүзе төнлә
Юл яктырта күрсен янып, дөрләп...
Иңсен шигырь безнең мәхәббәткә,
Бу мәхәббәт сыйсын
Бер шигырьгә.

* * *

Ак кар эреп үлән шытып чыгар,
Һәм тузганак җилдә тибрәнер –
Ак парашют тагын
Сабыйларын
Яшәр өчен җилдә җилгәрер.
Мин дә парашютлы бер орлык бит!
Тик назлы җил насыйп булмады –
Тик бер мәлгә
Давыл алды мине,
Һәм җиргә мин төшеп кунмадым.
Санын белмисең бу елларның –
Очам... Очам...
Кая кунармын?

**ЗӨЛФӘТ тәрҗемәләре**

* * *

*Уйлап кына шатлык*
*кире кайтмас,*
*Кайгы мөмкин*
*кабат туарга.*
Марино Фальеро.

Таң сыкравы авыр җәзамыни?!
Җан еласа, аңым бәйләнә.
Шигырь тама каләмемнән, гаклым
Тагын бер кат дөнья әйләнә.

Аң иясе мең мәсьәлә чишә,
Хакыйкатьне тотмакчы кеше.
Минем ялгышларга юк аңлатма,
Синең белән миндә чишелеше.

Үксүеннән җаным туктар булса,
Тау-коелар күчерү ни тора!
Мине сөйсәң, Ходай ишетер дисәң,
Тик тынгылык миңа син сора.

**Сания ӘХМӘТҖАНОВА**
**тәрҗемәсе**





# БӘБИ ИСЕ



Миләүшә
КАҺАРМАНОВА

(Хикәя. Ахыры. Башы 6 нчы санда.)

Уйларга вакыты җитәрлек булды Ләйсәннең. Атна буе ничек кенә төпле уйларга, акыл белән эш итәргә тырышса да, җимерек бaрактан, эчкечеләр оясыннан чыгып качу, шул михнәтләрдән котылу теләге бик көчле иде, һәм бу теләк, күңеленең ниндидер бер җирен айкап торган каршы тойгыларны басып, томалап куярга тырышты. Намусын җиңәргә, тынычландырырга теләп, еш кына үз-үзе белән «бәхәсләшеп» тә алды.

«Нишләргә тиешмен бу хәлдә? Мин бит берәүне дә үтермим, урамда бала калдырып китмим... Авыр хәлдәге кешеләргә ярдәм генә итәм шулай. Кызымның киләчәге... кызым хакына риза булыргадыр... мөгаен...»

...Уңай җавап алырын белә иде Асия. Бүген булмаса – иртәгә. Иртәгә булмаса, якын киләчәктә. Һәрхәлдә, булыр иде ул җавап. Уңай. Һәм хаталанмады да, тормышны яхшы белә шул апаң.

...Иң кыйммәтле клиникада тикшерү үттеләр. Акчаң булганда сиңа берәү дә йөз җыерып карарга кыймый икән лә. Матур елмаеп, ягымлы сөйләшеп, һәр теләгеңне үтәп кенә торалар. Тикшерелгәч, бераз дәваланып алдылар. Аннан төп процедуралар оештырылды.

Бик сагаешып, нәтиҗәләрне көттеләр. Тәлгать борчылулардан картаеп, каралып китте. Еш кына эштән кайтты да карашлары белән Ләйсәнне эзләде. Моны сизеп-күреп йөргән Асия: «Кешеләр икенче, өченче мәртәбәдә генә чак уңышка ирешә. Сабыр итик», – дип, ирен тынычландырырга тырышты.

Тынычландымы-юкмы, һәрхәлдә, нык үзгәрде ире. Элек ял көннәре генә күрешеп, аларында да нәрсәдер белән мәшгуль булсалар, хәзер ике күзе өйдә. Кичке алтыда «тып» итеп кайтып керүе җитмәгән, төшке ашка да монда чаба башлады. Үзе бер буш кул белән кайтмый. Ике суыткычның да шыплап тулы икәнен белә торып, һаман да пакет-пакет азык-төлек, яшелчә-җимеш ташый. Һәм, әлбәттә, бәләкәч Чулпан өчен берәр әйбере була. Бу «әйбер» башта гөнаһсыз тундырмадан гына башланса, соңгы көннәрдә зур йомшак уенчыкларга, хәтта купшы күлмәкләргә барып җитте. Асиягә башта иренең бу кыланмышы кызык тоелса да, тора-бара җанына тия башлады. Көнчелек песие күңелен тырнап алды. Тик әлегә баш кайгысы түгел. Әлегә башка мәшәкать беренче планда. Әгәр дә процедураны кабатларга туры килсә...

Туры килмәде. Беркөн кич соңлап кына кесә телефонына шалтыраттылар. Алып караса – Ләйсән. «Бәй! Кайда соң ул бу вакытта?»

– Ләйсән, кайдан шалтыратасың? Син кайда?!

– Өйдә мин, өйдә, Асия апа, шауламагыз, – яшь хатын пышылдауга күчте. – Сез ятмадыгызмы әле?

– Ятарга йөрим. Нәрсә булды, Ләйсән?

– Безнең бүлмәгә кереп чыкмассызмы икән, тик Тәлгать абый ишетмәсен, яме.

Барып керсә, Ләйсән диңгез шикелле киң түшәгенең уртасында аяк чалып кötеп утыра. Кызчыгы көчектәй генә булып йомарланып мышный.

– Нәрсә булды, Ләйсән? Куркыттың...

– Гафу итегез, Асия апа, сезнең вакытыгыз булганны көтеп йөрдем дә... Соң кайтасыз йә бөтенләй өйдә булмыйсыз кичләрен. Шуңа шалтыратыйм дидем, барып шакып торганчы.

– Йә... – Асия ике күзен тутырып Ләйсәнгә төбәлде.

– «Йә» дип... ну... шул инде.

– Нәрсә «шул инде»?

Апасының аңламавына аптырады. «Нәрсәсен төшенә алмый соң ул?»

– Авырлы... мин.

Күтәп ала алмый йөргәне артык көтелмәгәнчә булды Асия өчен...

– Т-точнымы?

– Точны. Үткән атнада ук тест алып караган идем – күрсәтә. Уже билгеләре дә сизелә, токсикоз башланмакчы.

– Тә-әк... Болай булгач – булды! Булды! – Торып учларын уып бүлмә буйлап үтте, чыдамый чәбәкәйләп җибәрде. – Булдырдык бит болай булгач, Ләйсән! Тукта, Тәлгать абыеңнан сөенче алыйм әле!

Артыннан ишек ябылып өлгермәде, кире килеп керде һәм:

– Маладис, Ләйсән! «Бишле» сиңа! Иртәгә врачка барырбыз. Инде аша, ял ит, йокла – синең эшең хәзер шул, – дип чыгып та китте.

Шул көннән, дөресрәге, шул кичтән соң бу өйдә бернәрсә дә элекке кебек була алмый иде инде. Һәрхәлдә, Асиягә шулай тоелды. Хәзер аларның яшәү рәвеше, уйхыялы, максатлары, хәтта тын алышы да икенче. Хәзер аларның барысын бергә туплаган, ныгытып бәйләп куйган сәбәп – булачак бәби бар.

Ләйсәнне баштанаяк игътибар үзәгенә әйләндерделәр. Бигрәк тә Асия апасы. Нәрсә ашый, нәрсә кия, ничәдә йокларга ята да, нинди көйләр тыңлый. Хәзер боларның барысы да ныклы күз-колак астында. Йөклелек тә үзенекен итте, яшь хатын вакыт-вакыт юк-бардан көйсезләнде, әле елыйсы килде, әле сәбәпсезгә көенеп йөрде. Иртәнге укшулар, хәлсезлек, исләрне күтәрә алмау, азык сайлау аның болай да какча йөзен ак кәгазь төсенә кертте. Җитмәсә, әнисенең башын икенче нәрсә биләгәнне сизенгән кызчыгы да ризасызлык белдереп көйсезләнде. Сузылып яткан әнисен йә тышка чыгыйк, йә уйныйк, дип тарткалап торгызды, үпкәләп елады. Бу хәлләр Асиягә ошамады. Бигрәк тә баланың, бу йортта бар икәнлеген белдереп, тавышын чыгаруы, шул кызны тынычландырам дип, иренең йөгергәләп йөрүе. Ничек инде, бармак башыдай бала аның өендә үз хокукларын булдырып утыра ала? Бу мәсьәләне җәһәт кенә хәл итәргә кирәк иде. Һәм хәл итте дә Асия. Тиз арада шәхси балалар бакчаларының берсе белән бәйләнешкә кереп килеште дә, Ләйсәннең авызын да ачтырмастан, Чулпанны җилтерәтеп алып барып та куйды. Өйдән «уйнарга» дип кенә чыгып киткән сабый, ят урынга барып кергәч, нидер сизенеп, Асиягә сырынган иде дә, тегесе чат ябышкан кечкенә куллардан итәген тартып алгач, күзләрен челт-челт йомгалап еларга да куркып катып калды. Шуның белән бу җимешнең язмышы хәл ителде дә. Хәзер өйдә тынычлык урнашты сыман. Ләйсәннән башкалар өчен. Аның исә, киресенчә, җанынннан тынычлык китте. Чулпанының күзләрендә нур сүрелгәнен, сулып, пошынып киткәнен күрмимени ул?! Моңа кадәр көн-төн күз алдында гына булган сабыеның да аңлаешсыз аерылышудан, әнисен сагынып зарыгудан, чит балалар, ят апалар белән аралаша алмый азапланудан аптырап калганын аңламыймыни? Җитмәсә, апасы: «Синең шалтыратуыңнан зыян гына булыр, борчыма баланы да, тәрбиячеләрне дә», – дип, бакчаның телефон номерын да бирмәде, янәсе, кирәк булса, аңа чыгачаклар. Утыра менә сабыеның хәлен дә белә алмыйча. Тик берни эшли алмый. Хәтта, әнә бит, кечкенә Чулпан да Асиягә каршы торып булмасны төшенә – күнә. Тик ана күңеле сизми буламы инде! Ләйсәннең йөрәге сызлау да юкка булмаган әнә. Беркөн өй телефонына шалтыраттылар, гадәттә ул телефонның тереме-юкмы икәнлеге дә беленми иде, күрәсең, эшли. Алыргамы-юкмы дип икеләнсә дә, үтә дә ярсып кат-кат зыңлагач, трубканы күтәрде.

– Алло?! Лесная унөчме? – теге очтагы хатын-кыз тавышы сабырсыз.

– Әйе.

– Бу балалар бакчасыннан. Сез калдырган номерны ала алмыйбыз, адрес буенча шушы телефонны чак таптык.

– Ә нәрсә булды? – Ләйсән сагайды.

– Балагыз авырды, скорый белән хастаханәгә алып киттеләр...

– Ничек?..

– Әйтә килдек бит, бала аралаша алмый, юньләп ашамый, сөйләшми дип. Бүген менә йөрде-йөрде дә ауды. Монда врач юк, медсестра гына...

Ләйсәннең тыңлап торыр хәле калмады:

– Нинди хастаханәдә?! Нинди?!!

Җавапны ишеткәч тә трубканы шапылдатып куйды да, Асия номерын җыйды. Тик аннан «Абонент не доступен», диделәр. Нишләргә? Такси! Тукта!.. Ләйсән өскә, бүлмәсенә йөгерде. Асиянең катгый тыюларын онытып, ике баскычны бер итеп югарыга сикерде. Халатының аскы төймәләре атылып очты хәтта. Кәгазь битенә язып куелган саннар тезмәсен калтыранган бармаклары белән телефонында җыйды да, теге яктан: «Әү, Ләйсән?..» – дигәнне ишеткәч, җебеп төште: «Тәлгать абы-ый...»

...Кичкә Тәлгать белән Асия арасында җитди генә тавыш купты.

– Нигә син хатын-кыз эшенә тыгыласың?! Кем сораган синнән?!

Күп очракта дәшми калырга күнеккән Тәлгать тә түзмәде:

– Син кеше баласын интектерүдән туктыйсыңмы? Кыз зарыгудан аңын җуйган, аңлыйсыңмы шуны?

– Бармак башыдай баланың капризына юл куйыйкмы?! Бәлки, ул иртәгә әллә нәрсәләр таләп итәр!

– Балага бары әнисе кирәк – шул гына!

– Ул бит өйдә көне буе әнисенә тагылып йөреп аны йончыта! Сиңа сәламәт бала кирәкмимени?! – Асиянең чигенер исәбе юк.

– Кемнең, икенче бала табам дип, беренчесен чыгарып ташлаганын күргәнең бар? Үзебезне ничек үстерделәр соң, миңа 3 яшьтә энем әнкәйнең кулында, өченчебез карынында булган... – Тәлгать, шуның белән сөйләшү тәмам икәнлекне белдереп, бүлмәдән чыгып ук китте.





Шушы хәлдән соң Асия Ләйсәннәр белән йөрүнең күп өлешен иренең җилкәсенә салырга тырышты. Шунлыктан хәзер ир кешегә яшь хатынны табибка, дәвалау үзәкләренә һәм хатыны уйлап тапкан тагын әллә кайларга йөртергә туры килә. Еш кына бергәләп театр-концертларга, ял паркларына йөриләр. Мондый сәяхәтләргә Асия кушылмый, аның мөһимрәк эшләре бар.

Ял көнне төшкә табан гына йокыдан торды да Асия, тегеләрнең юклыгыннан файдаланып, иркенләп кофе эчеп алгач, солярийга бармакчы булып, чыгып машинасын җылыта иде. Чырык-чырык иткән тавышларга әйләнеп караса, Чулпанны ике яктан җитәкләп, җай гына сөйләшеп килгән Ләйсән белән Тәлгатьне күреп телсез калды. Шушы бөтенлек, идиллия күренеше әллә нишләтте. Озын, мәһабәт гәүдәле күркәм ир янында яшь, сөйкемле хатын. Җитмәсә, авыры да беленеп, тагын да серлерәк, ягымлырак күренә. Урталарында кечкенә бала көлә-шаяра сикергәләп килә. Тәлгате хатыны белән диярсең: авызын җыеп ала алмыйча нәрсәдер сөйли, йөзе елмаюдан балкып тора. Ә бит үзләренең шулай парлап йөргәннәре дә юк. Җитмәсә, бала белән... Асиянең җанын көнчелек тырнап алды. Килүчеләр дә машина эчендәге Асияне шәйләделәр. Ләйсән кызын уртадан үз ягына күчереп җитәкләде дә, башын иеп, пышылдап кына: «Саумысыз», – дип үтеп китте. Тәлгать исә әсәрләнеп тора бирде. Асия дә кузгалып китә алмый иде.

– Нәрсә? Гаиләңне прогуливать итәсеңме таңнан? – Машина пыяласын төшереп, шулай дип мыскыллады ул ирен.

– Беренчедән, инде төш җитеп килә, икенчедән, шушындый матур ялда чынлап гаилә белән йөрергә кирәк, ә матурлык салоннарына чабарга түгел. – Аннан кинәт карашын хатынына төшерде. – Төш дигәннән, төшкә аш ашатучы кеше булырмы икән бүген?

Асиягә җитә калды:

– Әнә, «гаиләң» ашатсын! – дип ысылдады да кузгалып китте.

...Тәлгать Ләйсәнне хатын-кызлар консультациясенә УЗИга алып килде. Бергә кереп, карындагы сабыйны да күрмәкче иде дә, яшь хатын «оялам» дип ризалашмады. Менә шуңа Чулпан белән туңдырма ялап вакыт кыскарталар.

– Тәлгать бабай, әнкәем нишләп озаклый?

– Аны врач карый.

– Нәрсәсен карый? – Аннан, ир кеше җавап уйлап өлгергәнче, үзе үк әйтеп тә куя, – эчендәге бәбине карый, әйбит.

– Ыһы. Аны кайдан беләсең, бөрчәкәй?

– Беләм инде, әнкәем әйтте. Көн дә колагымны куеп бәбәйне тыңлыйм бит. Миңа «ток» итеп тибеп җибәрде кичә, – бу кызыктан үзе чыңгылдатып көлеп җибәрде. Аптырап, Тәлгать тә кушылды. Көлеп туйгач, «бабасын» «җәзалауны» дәвам итте:

– Ул бәби сезнекеме?

– ...

– Әнкәем, бәби Асия әби белән Тәлгать бабайныкы була, диде. Син аны нишләтәсең? Уйнатасыңмы?

– Уйнатам инде... Үстерәм зу-ур итеп, – 4 яшьлек баланың болай ачыктан-ачык сөйләшә белүенә исе китте Тәлгатьнең.

– Асия әби аны әрләр инде, шуннан бәби елар инде...

– Ниш-шләп?..

– Ул бит гел әрли...

Ир артта бытылдаган балага борылып ук йөзенә бакты:

– Кайчан әрләде сине Асия? Әй, Асия әбиең?

– Кичә... бүген дә... Ишшыу теге вакыт. Гел әрли ул, шуннан ул киткәч әнкәем елый... мин дә елыйм...

– Ә нигә әрли соң? Нәрсә өчен?

– «Балаңны тыймыйсың, көзгене пычраткан, идәнне кырган», дип. Миңа бүлмәдән чыгарга кушмый, кәнфиткә тидерми... үзе матур гына кәнфитләрне өстәлгә куя да... үзе ашатмый...

Күңелсезләнүдән, бөтенләй олыларча авыр сулап ук куйды Чулпан. Ә Тәлгать исә ишеткәннәреннән кая керергә белмәде. Бик гарьләнде. Чыгып утырган Ләйсәннән «Нәрсә диделәр?» дип сорарга да онытып, газга басты.

...Арыды инде Ләйсән, йончыды. Йөкле булып йөрүдән дә, җан газапларыннан да, Асиянең акыл өйрәтүеннән дә. Корсагы борынына җитеп зурайды, хәрәкәт итү, яту, утыру авырлашты. Алары гына берни түгел иде дә, менә бу җан әрнемәсә. Әмма эчтәге бер сызлану, өзгәләнү үтмәде дә, бетмәде дә. Киресенчә, ул ана карынындагы сабый белән кушылып үсте, зурайды, авырайды гына. Һәр көн кич түшәккә ятты да, кызын кочагына алып, үз-үзе белән «сөйләште»:

«Менә, минем балам бар, ул – Чулпаным, башкасы минеке түгел...»

«Түзәргә кирәк, бу – вакытлыча, мин – бары инкубатор!»

«Миңа ул бала беркем дә түгел, мин аны яратмыйм. Аны бервакытта да күрмәячәкмен!»

«Ә түзә алмасам, оныта алмасам?.. Ничек кенә йөрәктән йолкып алырга соң?.. Әй Ходаем, нишләп кенә ризалаштым бу тәмугка...»

«Ул хакта уйларга тиеш түгелмен. Уйламыйм. Все! Мин һәм Чулпан гына!»

Соңгы сүзләрен кычкырып ук әйтте, ахры, оеп барган кызы күзләрен ачты:

– Елыйсыңмы, әнкәй, Асия әби әрләдеме әллә?

– Юк, берәү дә әрләмәде, еламыйм... йокла, кызым, – кызын кысыбрак кочты Ләйсән, – йомшагым, йомгагым минем.

– Әнкәй, – Чулпан төнге лампа яктысында әнисенең күзләрен күрергә тырышты, – әйдә бәбине Асия әбигә бирмик... ул бит яман.

– Чулпан...

– Бирмибез. И псе! Бәбине алабыз да, Тәлгать бабайны алабыз да, китәбез дә барабыз.

Ләйсән түзми «пырх» итеп көлеп җибәрде:

– Тәлгать бабайны? Ул нигә безгә?

– Аны алыйк, ул бит әйбәт. Ул мине ярата, күтәрә, тәмнүшкәләр аппирә, куклалар бирә. Ул сине дә ярата, әнкәй, мин аңа әйтермен...

– Кит, юк сүз сөйләмә.




Рәсем: Наталья Васильева

– Асия әби, «Уф, кайчан китәсез инде», ди. Без китсәк, Тәлгать бабайга кыен була бит, аны Асия әби әрли инде.

– Йә, җитәр, әллә нәрсәләр сөйләп бетердең. Йоклыйк.

Баланың өстен рәтләп ябып куйды да, үзе аның сүзләреннән арына алмады хатын. Чынлап та, Асия апасы белән бигрәк авыр шул. Бөтенесен күреп, искәртеп, тукып кына тора. Үзе дә тәмам ялыкты, күрәсең. Баштарак «бала булачак» дигән канатлы уйлар белән сикергәләп йөрсә дә, тора-бара бу мәшәкатьтән арыды, өендә чит кешеләр булудан туйды, ахры. Хәзер аңа тупас эндәшү, җикереп-кычкырып җибәрү берни тормый. Мәңге йөзе болытлы. Элекке шаян, юмарт апа кая булгандыр? Кызын да күзгә төшкән чүптәй күрә, әрләп, тыеп, куркытып хәлдән тайдыра. Шул баланың бөрешеп елаганын кызык күрә диярсең. Ул хәтле дә балалар яратмагач, нигә бала тели икән соң? Тәлгать абый өчен генәме? Тәлгать абый... Әллә ничек итеп карый ул Ләйсәнгә... Карашыннан кыен да, рәхәт тә. Бер күз сирпүдән бар хәлеңне, тойгыларыңны сизеп торгандай. Һәрвакыт Ләйсәнгә кирәк чакта ярдәмгә килә. Аның янында булганда тыныч, яклаулы кебексең. «Ләйсән, Чулпан» дип, шундый иркә итеп эндәшә, елап җибәрерсең. Тагын да шул карашы... Онытылып, уйланып, текәлеп китүләре әллә ничек. Хатыны да аңламый дисеңме соң? Күралмавы йөзенә бәреп чыккан бит инде. И Аллам, кайчан гына котылыр шушы йорттан. Әллә нинди шайтан коткысына килеп юлыкты. Бала белән бергә шушында намусын да, йөрәген дә калдырып китәр инде. Аннан мәңге саргаеп көн итәр... У-уф-ф...

Көне, сәгате җиткәч, бала үзенең якты дөньяга чыгарга теләвен белдерде. Белдереп кенә калмады, тудыручысын уттан алып суга салып, көн ярым газаплагач, йөрәген урталай ярып килеп тә чыкты. Шалкандай эре, тере ир бала иде. «Иде», чөнки Ләйсән аны күрмәде, бары тавышын гына ишетте. Чытырдатып йомган күзләрен бер генә ачып караса да, шәфкать туташы кулында тыпырчынып елаган кечкенә тубырчыкка барып ябышудан курыкты.

Асия бала тудыру бүлмәсенә керүдән баш тартты, Ләйсәнне палатада көтеп кенә утырды. Шәхси клиниканың шунысы уңайлы, үз өендә кебек иркен йөреп, аралашып була. Баланың туганын көтеп көтек булды, яшь хатынның авырып ыңгырашуларын инде ишетмәслек хәлгә җиткән иде. Ниһаять, булды шикелле, бәби тавышы яңгырады. Күп тә үтми, биләүләп, китереп тә җиткерделәр үзен. Шәфкать туташы тантаналы рәвештә баланы Асиягә тоттырмакчы булып:

– Котлыйм сезне, улыгыз белән, – дип сузган иде дә, тегесе һавалы, салкын холкына хас булмаган җитезлек белән артка чигенде:

– Мин... миңа түгел, салыгыз караватка, ятып торсын.

Шәфкать туташы сәерсенүдән кашларын сикертте, шулай да баланы махсус урынына урнаштырды һәм: «Таныша торыгыз», – дип чыгып китте.





Асия аптырап басып тора бирде. Борынын таныш ис кытыклады. Бала чактан җанны биздергән, күңелдә авыр хатирә булып уелып калган әчкелтем бер ис. Бәби исе бит. Әйе шул, бәби исе. Кинәт шушы истән, шушы ис чыккан урыннан чыгып качасы килде. Бәләкәй генә җан иясе белән икәүдән-икәү бер бүлмәдә калу аны куркытты. Хатын ипләп кенә үрелеп биләүдәге сабыйның йөзенә карады. Күзләре йомык, борын да авыз. Авызы да, нәрсәдер эзләп, бертуктаусыз ачыла да ачыла. Менә ул берни дә тапмагач, көчәнеп кызарды да, дулап торып елап җибәрде. Бу тавыш Асияне бөтенләй каушатты. Ул нишләргә белмичә палатадан коридорга ташланды, анда да туктый алмыйча баскычтан аска йөгереп төште дә, ишекләргә бәрелә-сугыла тышка килеп чыкты һәм комсызланып, тирән итеп сулап җибәрде.

– Нәрсә булды? Ни булды Ләйсәнгә? – ул арада ишек төбендә таптанган Тәлгать хатынын тотып алып, чүпрәк курчак шикелле селкетте. – Асия, нигә эндәшмисең?

Хатын иренең кулларын иңбашыннан йолкып алып селкеп җибәрде:

– Нәрсә булсын – бала туды. Нәрсә җилтерәтәсең мине?

– Бала ничек? Ләйсән ни хәлдә? Син нишләп йөгереп чыктың соң? – Тәлгать үзен дә, хатынын да тыңламый әллә.

– Мин кайдан белим, кер дә кара.

Ир эчкә томырылды, хатын эскәмиядә учлары белән битен каплады.

Бәби йортка кайтты. Ата кеше улын каршылап, өендә төсле шарлар, тасмалар элде. Бала керәчәк бүлмәне картина кебек бизәде. Махсус кибет хезмәткәрләре килеп, иң сыйфатлы балалар мебелен, түшәк кирәкярагын, арба-бишекләрен, уенчыкларын тутырды. Бәби үз оясына кереп яткач, ул хатынын аш бүлмәсенә чакырды, ниһаять, икәүдән-икәү кара-каршы утырышып алдылар. Тәлгать хатынына игътибар белән бакты:

– Арыдыңмы? – аның тавышы бәрхеттәй йомшак, кайгыртучан иде.

– Арымый әллә. Больницада няня белән уңайлы иде, монда ялгызым нишләрмен икән?

– Ял ал, бәбиле хатыннарга ял бирәләр бит. Борчылма, җайлап өйрәнерсең, мин дә булышырмын, без икәү бит, – ирнең ирексездән авызы ерылды, мондый сүзләрне сөйләве рәхәт иде аңа. Тик бу хатынына ошамады.

– Нинди ял? Эш ташлатып, мине өйгә бикләмәкчесеңме? Атна эчендә хәлдән тайдым. Син ал ялны, ата буласың килде бит.

Тәлгать ишеткәннәренә ышана алмады:

– Н-ничек м-мин?.. Бәбине хатын кеше карый инде, әнкәй кеше!

– Алай булгач, няня яллыйбыз, дәваханәдә карашкан хатынны чакырыйк, яхшы хак түләсәк, нишләп килмәсен.

– Асия! Бәбигә әнкәй кирәк!

– Ул нәрсә аера әле?! Тамагы тук, асты коры гына булсын. Бер-ике яшькә җитсә, теләсә нинди шәхси бакчага бирергә...

– Син мине ишетмисең, ахры, бернинди няня да, бакча да түгел, үзебезнең балага үзебез әнкәй һәм әткәй булачакбыз – аңлашыламы? – Тыныч итеп, әмма теш арасыннан кысып чыгарды боларны Тәлгать. Күзләре яман янды, өстәл өстендә яткан зур учлары йодрык булып төйнәлде. Ирен бу хәлдә күргәне булмаган Асиягә йомшаклык күрсәтүдән башка чара калмады:

– Сиңа бала кирәк дип күпме тырыштым, рәхмәтең шулмы?.. Булып өлгермәгән нәрсәдән әллә күпме проблема, – күз яшьләренә буылып, торып ук китте, йокы бүлмәсенең ишеге «шап» итеп ябылды.

Тынычлык китте өйдән. Йокы китте. Бала өйдәгеләрнең берсенә дә тик утырырга бирмәде. Тик утыру гына түгел, иркенләп ашап алырга да җай булмады. Алай итсәләр дә, болай итсәләр дә ошатмады. Әллә шешә сөтен, әллә тотуларын, әллә биләүләрен яратмады – белмәссең, ярсыды да елады, ярсыды да елады. Ир белән хатын, чәчләрен йолкыр хәлгә җитеп, зәңгәрләнеп-күгәргән сабыйны бер-берсеннән тартып алып үзенчә тирбәткән, юаткан булды, тик файда озакка бармады. Өченче көн дигәндә инде сабыйга кушылып Асия дә шыңшый башлагач, Тәлгать дәваханәдәге няняны үзе шалтыратып чакырды. Килде хатын. Сабыйның таш булып каткан корсагына массаж ясап, алай итеп, болай итеп эчен бушаттырды, җылы суда коендырды. Шуннан бәләкәч тә имеп алып, изрәп йоклап китте. Шул минутында «әткәй» белән «әнкәй» дә ике якка тәгәрәде.

Тик бу бәхет озакка бармады. Белдекле апаның монда яшәрлек мөмкинлеге юк булып чыкты. Яхшы хак вәгъдә итсәләр дә, ул эшеннән һәм укучы балаларыннан бүленә алмады. Аның урынына икенче бала караучы таптылар, ике көн түзде дә, анысы да сәбәп табып китте. Өченчесе Тәлгатькә ярамады, чөнки аның кулында бала үзләрендәгедән ким шауламады. Дүртенчесе, юындырганда су эченә төшереп җибәреп, сабыйны чак тончыктырмады. Бишенчесе... алтынчысы... «Бигрәк бәләкәй шул, имчәсам, биш-алты айлык булса икән», – дип, күпләре баш тартты. Иң ахырда, сабырлыгын җыеп, Асиянең үзенә бишек янына басарга туры килде.

Унынчымы–унбишенчеме көн (хәзер инде ул көнтөннең исәбен дә югалткан), елап арыган сабый сулкылдый-сулкылдый йоклап киткәч, Асия аягөсте басып торудан буыннары каткан аякларын чак өстерәп, ванна бүлмәсенә атлады. Үтеп барышлый, элекке гадәтенчә, коридордагы зур көзгедә үзенең чагылышына күз салды. Салды да шаккатты. Каршысында танымаслык бер хатын басып тора иде. Яңаклары эчкә суырылган битен, йокысызлыктан эчкә баткан күз кабакларын бармак очлары белән сыпырды. Гомер буе маникюрлы тырнакларын Тәлгать тәүге көн үк ашык-пошык кистереп ташлаткан иде, бармаклары да кыскарып, гарипләнеп калгандай күренә. Башында прическа дигәннең әсәре дә калмаган, күптән тарак күрмәгән чәчләре ничек җитте шулай кыстырылып, аннан-моннан асылынып төшеп тора. Өстендә дә сөт исе, бала косыгы, сидеге сеңгән халат...

Күз алдындагыдан башы әйләнде Асиянең. Бу бит ул. Ул! Кайчандыр бала чагындагы, тәртипсез дөньясында

балага батып утырган әнисе кебек, теге шапшак Гөлназ кебек, пешмәгән Ләйсән кебек... Юк! Юк, юк һәм тагын бер кат юк! Моның булуы мөмкин түгел! Асия – алар түгел! Аның мондый ямьсез, арыган буласы килми! Хатын җан ачуына аякларына элгән башмакларын очырып ыргытты да ваннага йөгерде. Тиз генә өстендәге чирканыч киемен салды. Фу-у! Әлеге ис – бәби исе. Ул тәнгә дә, чәчләренә дә сеңгән иде. Асия тәнен ышкып-ышкып исле сабыннар белән юарга кереште.

...Тәлгатьне өйдә тынлык каршылады. Бу ни хәл? Кайда гүләп елаучы сабый? Кайда ачуы йөзенә чыккан хатыны? Телефонын алды.

– Алло! Асия, сез кайда?

– Без... Мин эштә.

– Ничек... эштә? Ә бала?..

– Тәлгать, кайткач сөйләшербез, – теге яктагы тавыш бераз тынып торды. – Бер-ике сәгатьтән өйдә булам.

– Ә-ә.. А... – бәйләнеш өзелде, – с-сия... – Тәлгать аптыравыннан кулындагы телефонына текәлеп тора бирде.

Чак көтеп алды хатынын. Җете кызыл машина давыл кебек килеп туктар-туктамас ишеген тартып ачты:

– Кайда бала?!

Асия тыныч иде. Ул бу сөйләшүгә алдан әзерләнгән, күрәсең.

– Тәлгать, ярсыма, хәзер барысын да җайлап аңлатам...

– Башта әйт: кайда бала?!

– Бала приютта. Вакытлыча приютта, – ире шаккатып торган арада, хатын тизрәк әйтеп калырга ашыкты. – Мин аны бераз хәл алганчы дип кенә тапшырып тордым. Анда аны яхшы карыйлар, тәрбиячеләр, медиклар...

Яңа гына аңын җуеп авып барган кебек булган ир, уйламастан, хатынны бер тартуда салоннан җилтерәтеп чыгарды.

– Кайда бала?! Нинди приютта?!!

– ...

– Утыр рульгә! Хәзер үк барып алабыз!

Ул арада Асия да телгә килде. Телгә генә түгел, асылына да килде ул.

– Юк, Тәлгать! Мин көне-төне янында утыра алырлык бала караучы тапмый торып, аны үзебезгә алмыйм! Сиңа рәхәт, эштә тик йөрисең, ә мин нәрсә, бала чүпрәге юучымы әллә?! Шуның өчен икешәр институт бетердемме?! Шуның өчен егылганчы тырышып карьера булдырдыммы?! Бишек янында бичурага әйләнер өчен шушындый дөнья җыйганмынмы?!

– Ә син нәрсә, бала үстерүе җиңел дип уйлаган идеңме?! Мин ярдәм итмимме?! Эшкә алып китә алмыйм бит инде! – Ир елый язып ачыргаланды.

– Алып кит! Теләсә кая илт! Син теләдең аны! Син!! – Хатын чәчәк түтәле читенә лып утырып, елапшыңшып кычкырды. Кулына эләккән чәчкәләрне йолкып алып бәрде, туздырды. Бу ямьсез күренешне баш селкеп карап торган ире аның каршысына чүгәләде:

– Асия... – иягеннән тотып үзенә каратты, – Асия, син бит аны бөтенләй яратмыйсың, шулай бит?.. Әйт дөресен... Кирәкми бит ул сиңа?..

Хатын чәбәләнүдән туктады. Беразга тынды. Аннан чекерәеп карады да:

– Әйе, – диде, – яратмыйм. Аңа бернинди тойгым юк. Арыдым... ялыктым. Инде карар әмәлем калмады... Хет үтер, Тәлгать... Хет үтер...

Ир калкынып басты. Бер мәлгә башын югары күтәреп һавага карап торды, аннан адашкан адәмдәй тирә-ягына күз салды, аяк астында бөрешеп утырган хатынына карады һәм ят, салкын тавыш белән эндәште: «Адрес».

Ләйсән үз фатирында көн итеп ята. Бер бүлмәле генә булса да, үзенеке. Моннан аны беркем дә төн уртасында куып чыгармый, сүкми, куркытмый. Үзе бикләп чыгып китә, ачып килеп керә. Җан рәхәтендә яшә дә яшә дә бит, әгәр ул җан рәхәте булса икән. Юк шул, юк. Булганы да юк һәм, аңлавынча, инде булмас та. Онытa алмады ул. Оныта алмады. Әллә онытырга теләмәдеме? Ярсып елаган бала тавышы колакларында чыңлап тик торды. Ә ул ис. Әчкелтем-татлы, башны әйләндерер татлы ис. Бәби исе. Шул исне тояр, кайдандыр тотып алыр, эчкә йотар өчен комсызланып иснәде, күзләрен йомып, тыны беткәнче һава сулады. Тик ул бәхетнең чыганагын тапмады...

Йокысы качты Ләйсәннең. Ябыкты. Болай да эндәшмәс җан бөтенләй йомылды. Көзгегә карамый ул хәзер. Анда тере күләгә булып торган, баласын саткан хатынны күралмый. Ә бу яктагы хатын Чулпаны өчен генә яши.

Көн дә телефонын алды да, җуеп ташланган, әмма хәтердә уелып калган саннарны җыйды. Җыйды да шалтыратырга көч тапмады. Җыйды да җуйды, җыйды да җуйды. Ярамый! Асия апа бервакытта да шалтыратмаска, килмәскә, очраганда да танымаска дип кат-кат кисәтте. Кисәтте генә түгел, бик җитди проблемалар белән янады. Болай да хәсрәтләре азмы инде.

Шундый мавыгу уйлап тапты: төн уртасында караңгылыкка текәлеп бала тәрбияләп йөрүче Асияне күз алдына китерә. Ул сабыен сөя, иркәли, үчтекиләп сикертә. Мондый күренешне башка сеңдерүе авыр булды башта. Һавалы, салкын хатынның кулларына бала ябышмый, килешми интектерде. Тик Ләйсән үзен бу хәлгә ышандырырга мәҗбүр итте. Сабыйны иркә кочакта, яклауда итеп уйласа, аңа җиңелрәк иде. Шулай булырга тиеш, әлбәттә шулайдыр. Анда бит Тәлгать абый да бар. Тәлгать абый... Тәлгать... Тә...

– Тук-тук... Тук...

Очсыз-кырыйсыз уйларын бүлеп, кемдер сак кына ишек какты.

– Тук-тук... – Чынлап та, бик сак иде ул. Әйтерсең, кемнедер рәнҗетүдән, куркытудан саклана.

Ләйсән торып халатын киде дә, аяк очларына гына басып ишеккә атлады. Иплəп, тышта торганнарга сиздерми генә килеп «күз»гә терәлде:

– А-аh!.. – Шунда ук хәле бетеп шуып та төште.

Ишек артындагылар телгә килде:

– Ләйсән, ач... бәби ачыкты...








*Сугыш вакытында, 1942 елның 1 февралендә туганмын. Сугышка үз теләге белән киткән кавалерист-командир әтием Ленинград янындагы сугышларда катнаша. Яралангач, аны Казан госпиталенә салалар.*

Әни госпитальдәге әти янына барып җитә алмый. «Бик суык көннәр иде. Поездлар начар йөрде. Сине күтәргән килеш вокзалдан кире борылып кайттым», – дип сөйли иде ул. Аларга башка күрешергә язмый.

Безнең балалык, яшьлек еллары бик авыр чорларга туры килде. Ашарга ипи җитмәде, алмашка кием булмады. Җәйге матур көннәрдә урамга чыгып йөгерәсе, уйныйсы килә, тик юып элгән күлмәкнең кипкәнен көтәргә кирәк. Кием-салым гына түгел, мәктәптә укыганда китап-дәфтәр дә җитешмәде. Әнием исә һәр кичне: «Иртәгә сезгә нәрсә ашатырмын», – дип кайгыра иде. Шулай да һәр иртәдә мәктәпкә кайнар ризык ашатып җибәрде. Он җитмәгәч, ипигә алабута үләне, бәрәңге кушып пешерә. Шуңа да икенче көнгә аның тәме үзгәрә иде. Без үскәндә ипи җирдә аунап ятмады, бик кадерле иде ипекәй. Язгы көннәрдә колхоз кырларыннан өшегән бәрәңге эзләп, сазга батып кайтулар да истә. 8 нче класста укыганда гына хуш исле чын ипи ашадык.

Әниебез аш-су остасы булганга тракторчыларны ашатуны аңа йөкләделәр. Кырда эшләүче механизаторларны эзләп табып, кайнар ризык ашату Әмир абыем белән безнең өстә иде. Кайбер көннәрдә унар чакрым ара үтәбез. Балалыгым, беркатлылыгым белән, әнидән әтинең фронттан язган хатларын укыта идем. Инде ятлап бетергән ул хатларны тагын бер кат укып чыккач: «Әтиең кайтыр, кызым», – дип мине юатучы әнинең күзләре гел яшьле булуга аптырый идем. Әти кайтасы булгач, нигә еларга инде? Хатларыннан үз исемемне, миңа аталган сәламен ишетәсем килгәндер инде. Әтигә охшаган кешене күрсәт әле, дип йөдәткәндә әнинең җаны телгәләнгәндер... Боларны хәзер – гомерләр үткәч аңлыйм...

Мәктәпне тәмамлаган елны кичләрен шәфкать туташлары әзерли торган сигез айлык курсларда укыдым. Ул вакытта безнең гаилә миңа билгеләнгән пенсиягә көн итте. Соңыннан «Авангард» газетасында корректор, тәрҗемәче булып эшләдем. Казан, Красноярск медицина институтларында укыганда баштагы елларда – шәфкать туташы, дүртенче курстан соң табибә булып хезмәт куйдым. Бүгенге көндә 50 еллык стажым бар. Сугыш чоры авырлыкларын бергә кичергән Нәбиулла абый Мәскәү авиация заводын тәмамлап, заводта авиаконструктор, автоконструктор булды. Әти сугышка киткәндә 5 яшьлек булып калган апам Фәсәгатьбану гомере буе сыер сауды, алты бала үстерде, депутат итеп сайланды.

Сугыш башланганда Әмир абыема әле 3 кенә яшь булган. «Әтине алып кайтыгыз», – дип елап, әнине һәм туганнарны бик интектергән ул. Армиядә хезмәт итеп кайткач, Әмир абый электрик булып эшләде, Байконурга командировкаларга барды. Әни яшәгән йортны төзәтеп, аны матурлады.

Еш ук булмаса да, туган авылыма кайткалыйм. Хатирәләремнең барысы да сугыш чорына барып тоташа. Миллионлаган гаиләләр кебек үк, ул да күңелемдә мәңге төзәлмәс бер яра.

*Гөлфизә ЗӨЛКАРНӘЕВА.*
*Түбән Кама шәһәре.*

*Тәтеш районы Кече Тархан авылының бер читендә матур гына, җыйнак кына өй урамны ямьләп тора. Бу йортта авылның бик тә мөхтәрәм кешеләре – шатлыкта да, кайгыда да бер йодрык булып яшәүче Зәйнәп апа белән Зөфәр абый Мөхтәровлар гомер итә.*

Гаҗәеп туган җанлы Зөфәр абый белән Зәйнәп апаны якын итүче бер без генә түгел – ике яктан да туганнар аларга кайта. Зәйнәп апа да, Зөфәр абый да туганнарны бертигез якын күрә – ачык йөз, тәмле тел белән каршы алалар, озатып калалар, сагынып көтеп торалар. Аларга эч серләребез дә сыя, акыллы киңәш тә бирә беләләр.

Зәйнәп апа турында аерым язасым килә. Үтә нечкә күңелле, һәр сөйләгән сүзен үлчәп, тәфсилләп сөйләр. Гайбәт ишегә һич кушылмас. Зирәк акыллы, һәркемнең дә җаен табар, күңелен күрә белер. Сүзе үтемле, үзе бик сөйкемле. Хатын-кыз – гаилә учагын саклаучы... Менә шул учакның җылысы һәркемгә җитә, һәркемне сыендыра, бәхетле итә.

Фото: Анна Арахамия

Зөфәр абый белән Зәйнәп апаның үзара мөнәсәбәтләрен күрү үзенә бер рәхәт. Матур гаиләнең сере – бер-береңне күз карашыннан ук аңлаудыр. Зөфәр абый белән Зәйнәп апаның да бер-берсенә ягымлы караш ташлап алулары, йомшак итеп кенә эндәшүләре, сүзгә килгәндә дә кабынып түгел, җайлы, салмак кына бәхәсләшүләрен күреп күңел нечкәрә, сокландыра...

Тумышлары белән алар икесе дә бер авылдан, бер-берсен кечкенәдән үк белеп үскәннәр. Гаилә корып яши башлагач та тормышлары сикәлтәсез генә булмаган, язмыш аларга хәсрәтнең иң ачысын әзерләгән. Гаиләдәге мөнәсәбәтләр никадәр җылы, нык булса, аннан килгән җылылык та шулкадәр көчле була. Шул көч аларга балаларын югалту кайгысын да, тормышларын көлгә әйләндергән хәсрәтне дә, авырусырхауларны да җиңәргә ярдәм итә.

Шулай аңлашып яшәүләренә менә инде 60 ел... Хөрмәт, ярату хисләре бу гаиләдә хатынга карата да, иргә, балаларга, оныкларга карата да тулысы белән чагыла. Зөфәр абый кызларына да, яратып, бәбекәем, дип кенә эндәшә. Чит кешегә дә, наныкачым, дип әйтә. Аның күңел җылысы якыннарына гына түгел, якын-тирәдәгеләргә дә җитәрлек.

Кызлары Зөлфия белән Зөһрә дә әти-әниләре янына эзләрен суытмый. Ерак араларны якын итеп, кайтып-китеп, барлык эшләрендә дә булышалар. «Әле тагын озак еллар әти белән әнинең тигезлегенә, саулыгына сөенеп яшәргә насыйп булсын», – ди алар.

Улларын сабый чагында югалткач та, өйләре белән бар мал-мөлкәтләре янып, бернәрсәсез калганда да, Ходайдан көч-куәт сорап, тормышларын яңадан торгызалар. Аның ямен-тәмен белеп яшиләр. Тагын бәхетсезлеккә тарыйлар. Кызлары Гөлсинә каты юл һәлакәтенә очрый, аны яңадан аякка бастырырга үзләрендә түземлек, сабырлык табалар. Кызганыч, ләкин моның ахыры бик аяныч... Бүгенгәчә Зөфәр абый белән Зәйнәп апа янына кайтып хәлләрен белеп торучы, әле дә аларга хөрмәт белән «әти-әни», дип торучы ире Фәнисне, 6 яшьлек улы Марсельне калдырып, Гөлсинәне җир куенына иңдергәндә дә сабыр итә белә алар... Беркемгә дә үпкә-кинә белдермиләр, рәнҗемиләр... Тәкъдир, диләр...

Инде Гөлсинәнең улы Марсель дә – армия сафларында хезмәт итеп кайткан егет. Әтисе, яңа әнисе белән әбибабасы янына кайтып-китеп йөриләр.

Зөфәр абый гомер буе колхозда шикәр чөгендере үстерде, 40 ел буе бер тракторда эшләде. Күңел биреп, тырыш хезмәт куйган өчен Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләделәр үзен, Мактау кәгазьләренең исәбе-саны юк... Эшләгән дәверендә авылдашларының үтенечен бервакытта кире какканы булмаган аның. Бергә эшләгән иптәшләре арасында да, авылдашлары, җитәкчеләр каршында да Зөфәр абыйның абруе гел зурдан, шөкер. Аның өздереп гармунда моңлы көйләр уйнавын тыңлаганда, авыр булса да, тормышының һәр чорын, һәр мизгелен камил итеп яшәве күз алдына килә. Дөрес кеше ул!

Бу матур гаилә гомер юлын сынаулар, югалтулар аша узса да, бер-берсенә терәк булып, иңне-иңгә куеп атлаганга гына бәхетледер... Мөхтәровлар гаиләсе әле тагын озын-озак еллар бәхетле тормыш юлын дәвам итсә иде. Кызлары, кияүләре, оныклары, инде оныкларының да балалары яхшы хәбәрләр, изге гамәлләр белән генә сөендереп, шатландырып торсалар иде.

*Фирдәвес АБДУЛХАНОВА.*
*Казан шәһәре.*

***Безнең әни, җиде баласы да башлы-күзле булып, үз тормышлары белән яши башлагач, төп йортта үзе генә калды.** Авылдагы ике улы, килен һәм оныклары көн дә килеп, бөтен эшен эшләп торсалар да, аның тормышы авыр, әни җәфа чигеп яши кебек тоелды безгә.*

Без аны, кыстый-кыстый, бер кыш кына булса да шәһәрдә яшәп карарга күндердек. Күндерүен күндердек тә ул... Монда килеп бер ай да узмады, әни бөтен җирне каплап киткән ап-ак карны тәрәзә аша күреп: «Каз өмәләре башланды инде хәзер, озакламый сугым суярга да вакыт җитә», – дип куйды.

Яңа елны каршылаган көнне: «Әбиләрем нишлидер инде бүген, мин өйдә булмагач, кемгә җыелырлар», – диде моңсу гына. Ә февраль бураннары башлангач: «Абзарны түбәсенә кадәр кар басып китте инде хәзер, кәҗәләрем, тавыкларым ни хәлдәдер», – дип уфтанып алды. Язга таба бөтенләй йомшарды: телевизордан спектакль карыймы, радио тыңлыймы, күзләренә яшь килеп, моңаеп тик утыра...

Нигә соң безнең әни мондагы җиңел, мәшәкатьсез шәһәр тормышына күнегеп китә алмады? Нигә соң кыш буе туган авылына ашкынды? Хәер, бу сорауларга җавапны авылыма кайткан саен үз күзләрем белән күрмиммени?

Без кайту белән әни янына иң якын ахирәте Гөлҗиһан апа килеп керә. «Әниегез сезне кыш уртасыннан алып китә инде, – ди ул. – Тиргәп бетерәм мин аны: юкка-барга көенеп, барысы өчен кайгырып тик йөри ул». Күп тә үтми, икенче як күршесе Галия апа сөт тотып килеп керә. Капка төбеннән үк: «Шушы Салиафа, – ди, – балалары кайтса, яшәрә дә китә. Әле кичә генә аяк сызлый дип ята иде... Карале, кая йөгерәсең? Утыр әле, сөйләшеп алыйк». «Туктале, вакытым юк, күмәч саласым бар», – ди әни кулын селтәп һәм алачыкка кереп югала. «Шулай инде, балалары булгач, без кирәкми», – дип куя Галия апа. Тавышында – әниебезне хөрмәтләү, сүзләрендә – шулай булырга тиеш тә дигән мәгънә.

Эштән кайтышлый уллары белән киленнәре хәл белергә керә. Аннан оныклары йөгереп килеп җитә: «Әби, нинди эшең бар?» «Су кертәсеңме, улым?» «Ерак түтәй» белән «Якын түтәй» килеп, әнидән җылы алып, үзләре аңа җылы биреп китәләр...

Җылы биреп китәләр?.. Йә, Хода! Шушы түгелмени инде барлык сорауларыма да җавап?! Менә бит әни шәһәрдән ни өчен ашкынган! Менә бит кайда икән аның үз учагы, үз туфрагы, аның үз тамырлары! Ә без аны шушы туган туфрагыннан, аның үз дөньясыннан йолкып алып, башка җиргә, ят туфракка күчереп утыртмакчы булганбыз. Тик шунысын истән чыгарганбыз: күчереп утыртканда агачның тамырлары өзелә бит, яңа җирдә ул үсеп китә алмаска да мөмкин.

*Марс ЯҺУДИН,*
*Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.*
*Чаллы шәһәре.*

***Хөрмәтле укучыларыбыз!***
***Сездән хатлар көтеп калабыз.***
***Безнең адр ес: Казан,***
***Декабристлар урамы, 2.***
***e-mail: ssuum@yandex.ru***



# 57 КӘҖӘ, 40 СЫЕР ҺӘМ АЛЬМИРА

Лилия ГӘРӘЕВА

**Альмира белән безнең танышлык катыктан башланды. Әйе-әйе, гап-гади авыл катыгыннан. Куп-куе, хуш исле, искиткеч тәмле иде ул. Елын инде хәтерләмим, әллә 2017, 2018 ел булдымы икән – «Тәмле марафон» җиңүчеләрен тәбрикләү тантанасына чакырдылар. Әнә шунда авыз иттек тә инде Альмираның яңа сауган сөттән оеткан катыгын. Бәләкәй генә буйлы, бөтерчектәй җитез, ачык йөзле бу ханымны шул чагында ук үз итеп калдым.**

Быел менә тагын очраштык. Әлеге дә баягы һаман да шул аш-су осталары марафоны иде ул. Бу юлы инде, ай-ваена карамый, Альмираларга үзем кайтырга уйладым. Ай-ваена дип язам, чөнки җәй көне авыл кешесенең кунак көйләрлек вакыты бармы соң аның?

Казанга терәлеп торабыз дисәләр дә, бара торгач шактый киттек. Әнә каршыбызда Кама култыгы кояшта иркәләнә. Яшел болыннардан зәңгәр рәшә күтәрелә. Ерактарак сыерлар утлап йөри. Ишләре шактый үзләренең, көтүчеләре генә күренми дисәк, авылда хәзер чыбыркылы көтүчене электрлысы алыштырган икән. 10 гектар болынны әйләндереп алган көтүлектә тездән чәчәкле печән. Кыр тургайлары өздерә генә. Җаннар ял итәрлек матурлык!

Альмираның бүген сыр ясый торган көне. Газ тирәсеннән ерак китә алмый.

– Качотта, маасдам, брынза, чечил, халлуми, «Российский», ак күгәрек белән, зәңгәр күгәреклесен... – бармагын бөгә-бөгә ясаган сырларның аталарын атый ул. – Сыр ясар өчен вакыт кирәк. Бер литр сөттән әзерлисеңме, йөз литрданмы – биш сәгать ярым янында торасың.

Сырны кәҗә сөтеннән әзерли Альмира. Әнә шул кәҗәләренә кызыгып кайттык та инде без аларга. Күршең белән ачуланышасың килсә, кәҗә ал,

диләр дә... Альмираларның бераү генә дә түгел бит әле алар, унау гына да түгел... 57 кәҗә Миңнуллиннар хуҗалыгында! Сакалбайлар турында сүз башлаганчы, хуҗабикәнең үзе белән таныштырыйм әле сезне.

Альмира Миңнуллина – Әгерҗе районының Иж-Бубый авылы кызы. Сигезенче классны тәмамлагач, Әтнәдәге Тукай совхоз-техникумына укырга керергә килә.

– Әгерҗе кайда да Әтнә кайда? Андый техникумнар үзегезгә якынрак җирдә дә булгандыр бит? – дим, гаҗәпләнеп.

– Әсәндә бар иде. Никтер Әтнәне үз иттем, – ди ул. Бәлки, язмыш дигән кодрәтле көч сәбәпчедер моңа. Югыйсә әле уналтысы яңа тулган япь-яшь кыз Татарстанның бөтенләй икенче почмагындагы бер авылга укырга килер идеме? Әгерҗе белән Әтнә арасы 300 чакрымнан артык. Хәзер булса, әллә ни аптырамас та идең, бу бит әле сиксәненче еллар. Лаеш районының Сиңгел авылы кызы белән дуслаша Альмира. Берничә тапкыр аларга кунакка да кайткалый. Ә бер кайтканында бу якларда гомерлеккә кала. Урлыйлар кунак кызын! Бер күрүдән ошата аны Илсур. Шулай итеп, әле унҗидесе дә тулмаган кыз ун балалы ишле гаиләгә килен булып төшә. Илсуры – төпчеге, төп йортта калырга тиешлесе! Паспортны да кияүгә чыккач кына барып ала Альмира. Унҗиде яшендә – олы кызлары Илсөярне, унсигезе тулганда уллары Илфарны таба. Төпчекләре Айсылуга әле 12 генә яшь. «Оныкларым белән бергә үсте кызым», – дип шаярта әнисе. Ул – өч бала әнисе, алты оныкның әбекәе. 18 ел кайнанасы белән яши. Ал да гөл генә яшәдек дигән кешеләргә ышанмый Альмира. Авыл тормышында гел җайлы гына итеп яшәп булса икән ул!

Миңнуллиннарның бу зур хуҗалыгы үз тарихын 2011 елдан башлый. Бер сыер, ике тана белән ачып җибәрәләр гаилә фермаларын. Һәм, әлбәттә инде, кредиттан... Терлек сарайлары төзү өчен әҗәткә керергә туры килә. Бәрәңге бакчаларына 40 метр озынлыктагы ферма төзеп куялар. Хәер, бина төзегәндә – 30 проценты, сөт суыту җайланмасы алганда

Фото: Анна Арахамия

## Авылда эш юк диләр. Ә безнең менә эштән күп нәрсә юк.

50 проценты дәүләт ярдәме булып кайта кайтуын.

– Без гомер-гомергә мал-туарны ишле асрадык. Өчәр сыер сауган елларыбыз да булды. Бу эшне беләбез, шушы тормышка күнеккәнбез, шуңа күрә курыкмыйбыз да, исәнлек кенә булсын, – ди Альмира, әзер сырларны формасыннан бушата-бушата. – Ул елны савым сыерларыбызны саткан гына идек. Тотындык сыер эзләргә. Акларын да алдык, караларын да, нәселлесен, нәселсезен. Беренче елны ук егермегә җиткездек. Бермәлне кырык бер булдылар, урын җиткереп булмый башлады. Хәзер исә төгәл генә санын белмим дә инде. Илсур кайткач, үзе сөйләр әле. Сыерлар белән ул шөгыльләнә безнең.

400 литр сөт алып, шәһәргә киткән икән гаилә башлыгы. Көтәбез. Ә аңарчы хуҗалыклары белән танышып чыгарга өлгерәбез. Абзарлар артында нидер шакылдый. Уллары Илфар трактор төзәтә. Печән вакыты якынлаша. Зур хуҗалыкны терлек азыгы белән тәэмин итү тулысы белән шушы егет өстендә.

– Ничек соң сиңа авыл тормышы? – дип сорамакчы булам. Күп сөйләшә торган егет түгел икән бу – башын да күтәрми, гел эшләвендә. Авызын ачып, бары ике сүз әйтте: «Исәнмесез! Сау булыгыз!»

Аның өчен җавапны әнисе бирә:

– Авылда төпләнде инде улыбыз. Казанда автотранспорт техникумын тәмамлагач, шунда ук эшкә калырга үгетләгәннәр иде дә, теләмәде бит. Таш арасында ничек яшим, диде. Йорт төзеп, башка чыгардык. Хатыны белән өч бала үстерәләр. Уң кулыбыз да, сул кулыбыз да ул безнең. Читтән кеше кушмыйбыз, бөтен эшне өчәүләп эшлибез.

Чирәмдә уйнаклаган кәҗә бәтиләре белән мәш килгән арада, капка төбенә «Ларгус» килеп туктый. Илсур абый (минем өчен абый тиешле ул) беренче рейстан кайткан! Бераз капкалап аласы да, тагын бер рейс ясыйсы.

– Алалармы? – дим.

– Җиткереп булмый! – дип җаваплый. Менә шулай – кемдер җитештергән продукциясен ничек сатарга белми, болар – ничек җиткерергә диләр. 20 сыерның сөте бит ул! Ә болай мөгезле терлекләренең гомуми саны 47, ди.

– Сатып алучыларны каян табасыз соң? – дип кызыксынам.

– Алар безне үзләре эзләп таба, – диләр. – Авыл хуҗалыгы күргәзмәләрендә катнашабыз бит. 18 төрле сөт ризыгы алып барабыз.

– Менә бүген 400 литр сөтнең 70 литры гына калды, – ди Илсур абый. – Хәзер аны Альмира аерта да, иртәгә каймак, эремчек булып бара ул. Эремчек сатылып бетми икән, корт кайнатабыз. Берсе дә әрәм булмый.

Үз гомерендә бик күп эшләр башкарырга туры килә Илсур Миңнуллинга.

– Эшнең төрлесен эшләдек инде, эштән курыккан юк! – ди ул. – Армиядән кайткач та колхозда эшли башлаган идем. Терлекче дә булдым, склад мөдире дә, бригадир да... Урманчылыкта эшләдем. Крестьян-фермерлык хуҗалыгы директоры итеп билгеләделәр аннары. Әҗәткә баткан хуҗалыкны аякка бастырдык, хәзер үзебезчә яшәрбез дисәк... Инвестор килеп, барысын да таратып китте.

– Синең бәхеттән таралган ул, Илсур. Ятар идең әле шунда чиләнеп, – дип юата аны Альмира. – Район башлыгы сорагач, миллионнан артык әҗәте белән алды бит ул аны. Заманында бик күп акчалар иде бу. Безнең бәхеттән «Гаилә фермалары» дигән дәүләт программасы эшли башлады. Тәвәккәлләдек инде.

Ә аңарчы Миңнуллиннар сәүдә белән дә шөгыльләнә әле. Өчәр кибет ачалар. Бу эшләренә керешкәч тә, берара кибетләрен ябмый торалар.

– Өлгереп булмады. Ипи кабул итәргә генә дип керәсең дә, кичкә кадәр кибеттән чыга алмыйсың, – ди хуҗабикә. – Сатучы яллап та карадык. Авыл халкының бер сәер үзен-

## Туклыклы үзлекләре һәм структурасы белән кәҗә сөте ана сөтенә охшаш.



– Сыер сөтенә караганда кәҗәнеке тәмлерәк, – дип, хатынының сүзен җөпли йорт хуҗасы да. Бу сүзләрне әле кайчан гына кәҗәне һич кирәксенмәгән кеше әйтә димәссең дә.

чәлеге бар. Әллә кая, кимрәк хезмәт хакына берәр оешмага барып эшләсә эшли, сиңа килми. Көнәнә 1200 түлибез югыйсә. Авыл җире өчен әйбәт кенә чыга. Юк, килергә теләмиләр. Аптыраш инде менә! Телне аркылы тешләгәнче, ябыйк, дидем Илсурга.

Кибет, дигәннән, үзе өчен бер кызык вакыйганы искә ала Альмира ханым. Бервакыт кибетләренә бер ир-ат керә. Сөт бәяләре белән кызыксына, сөтне кайдан алуларын сораша. Йөзе бик таныш тоелса да, кем булуын искә төшерә алмый гына бит Альмира. Өйгә кергәч кенә зиһене ачылып китә: «Фәрит Мөхәммәтшин бит!»

Көннәрдән бер көнне тик торган җирдән авырып китә Альмира. Куллары бозыла, томаудан интегә. Озакка киткәч, табибка барса... Гомер буе сыер сауган ханымда сыерга аллергия икән ләбаса! Сөтенә генә дә түгел, сыерның үзенә! Тузан да, үлән дә ярамый булып чыга әле, өстәвенә. Менә тамаша! Куе сөтле чәй эчеп күнеккән кешегә сөтсез чәйнең тәмсезлекләре! Авылда кәҗә асраучылар бар барын да, аларның сөтеннән ис килгән шикелле. Токымлысының сөтендә ис юк диләр дә... Илсурының кәҗә дигәнне ишетәсе дә килми. Соң, егерме сыер янына тагын нинди кәҗә инде?! Шулай да зирәк ханым шыпырт кына игъланнар күзли. Алабугада берәү сата икән. «Барып кына карыйк, бәлки алмабыз да», – дип киткән Миңнуллиннар берьюлы биш кәҗә ияртеп кайта. Әнә шулай итеп хуҗалыкта зааненский токымлы ак кәҗәләр барлыкка килә. Болар сөтне күп бирә, ләкин сыр ясау өчен нубийск токымлысы яхшырак. Икенче партияне Тукай районына барып алалар. Хәзер Альмираның зааненский, нубийский, альпийский токымлы кәҗәләре янына Америка ламанчасы белән чех токымлылары да өстәлгән.

– Яхшы кәҗәне табуы читен аны. Бер кәҗәне сиксәнешәр меңгә саталар, – ди Альмира, янында бөтерелгән бәләкәчләрне алдына алып яратып. – Зааненский сөтне күп бирә, нубийскийның сөте майлы, тәмле дә, альпийский токымлысыныкы сыр өчен әйбәт...

Кәҗәкәйләре унбердән артмаганда кул белән сауган, хәзер инде савым аппараты бар.

– Үзең өчен бер кәҗә дә җитәр иде инде, – дим.

– Кәҗә сөтен күп сорыйлар шул. Күбрәк авыру балаларга дип алалар. Кәҗә сөтеннән ясалган ризыклар да тәмлерәк, туклыклырак, – ди әңгәмәдәшем.

– Кәҗә саталар, дисәң, «кайда?» дип тә сорамый хәзер Илсур, «токымы нинди?» – ди. Әллә кайдан да барып аласы, – дип көлә Альмира. Менә шулай ул эш, бер бөтереп алсамы?

Зур залларына керсәк, бөтен җирдә йон йомгаклары. Аптыраулы карашларыбыздан ук Альмира нәрсә сорыйсыбызны аңлап ала.

– Болары – хоббием.

– Әле синең хоббига да вакытың каламы? – дип тел шартлатам. – Тәүлегеңдә ничә сәгать соң синең?

– Әллә тагын, кем санаган соң инде аны? – дип көлә генә Альмира. – Яраткан эш ардырмый бит ул. Бәйли башласам, чебен дә очмасын миңа, ашарга да сорамасыннар, эчәргә дә... Иртәнге өчкә кадәр бәйләп, дүрттә сыер саварга чыгып китәргә дә мөмкинмен.

Ул безгә бәйләм башмакларын, свитерларын, мамык шәлләрен күрсәтә. Хыялы белән дә уртаклашырга өлгерә. «Урын булса, бер мамык кәҗәсе дә асрар идем...»

Без килгәч, эше күп калды инде бу уңган ханымның. Әле никах табынына гөбәдия пешереп бирүен дә сораган булганнар, бер читтә камыры күпереп утыра. Кичке савымга кадәр теге 70 литр сөтне дә аертасы бар. Йөз бройлер чебешенә бәрәңге пешереп төясе... Бер җәйдә алты йөз чеби дә үстерергә җитешә ул. Интернетта татарча узган марафоннарда да катнашып бара... Авыру әнисен дә бага. Шаккаттыгызмы? Менә без дә шулай. Эш күплеге дә аның кадәр гаҗәпләндерми, хуҗаларның эшкә булган мөнәсәбәте гаҗәпкә калдыра. Сыер асрау читен, бер файдасы да юк, дигәнне күпләрдән ишеткәнебез бар. Ә Миңнуллиннар, киресенчә, сыер табышны күп бирә, тиз бирә, диләр. Бер зарланып карамыйлар. Ел да санаторийда ял итәргә дә вакыт табалар әле.

...Кама буе болыннары, зәңгәр рәшәгә өртелеп, юл буе безне озата бара. Искиткеч матур урыннар. Мондый җирдә яшәүчеләр бәхетсез була алмыйдыр ул. Минем геройларым да үз җирләрендә үзләренчә яшәүче бәхетле кешеләр. Бәхетләренә берүк күзләр тимәсен.

# КЫЗЛАР ЯЗА...

ШИГЪРИЯТ


Лена ШАГЫЙРЬҖАН
**«Язмыш келәме»**




Бу китапка Татарстанның халык шагыйре, Г. Тукай премиясе лауреаты Лена Шагыйрьҗанның 1992–2001 елларда иҗат иткән шигырьләре, поэмалары тупланган. «Шигырь кирәкме?» дип баш вату ул «дин кирәкме?», «белем кирәкме?» һәм ахыр чиктә «тормыш үзе кирәкме?» дигән мәгънәсез сорауга кайтып калыр иде. Шигъриятсез яшәгән кешене мин Сабантуйсыз калган авыл белән тиңләр идем. Яки беркайчан да көзгегә күз салмаган кеше белән... Яки курчак уйнамаган бала... Дәва эзләмәгән хаста... Төш күрмичә генә йокы симерту... Тәм тоймыйча гына ашау... Кызыкмы? Күңелләме? Аллам сакласын!» – дип язган ул үзе.

ПРОЗА


Фәүзия БӘЙРӘМОВА
**«Һиҗрәт»**




Танылган әдибә, тарихчы һәм җәмәгать эшлеклесе Фәүзия Бәйрәмованың яңа әсәрендә XX гасыр башында Төркиягә күчеп киткән милләттәшләребезнең тормышы һәм язмышы тасвирлана. Хәзерге Омск өлкәсенең Тара төбәгендә гомер иткән татарларның дин-ислам хакына ерак сәфәргә чыгулары, аларның юлда күргән, кичергән авырлыклары, аянычлы югалтулары, Төркиядәге кичереш-хәлләре... Себер татарлары өстеннән давыл булып үткән күчләп чукындыру газаплары, нәселләрен шушы фаҗигаләрдән саклап калу өчен, туган яктан мәңгелеккә аерылу тарихы тетрәндергеч вакыйгалар аша бирелә.

ШИГЪРИЯТ

Сәйдә ЗЫЯЛЫ
**«Язлардан язларга кадәрле»**




Аның белән азмы-күпме таныш булган укучы белә: Сәйдә Зыялының иҗатында һәрвакыт шигърият белән чәчмә әсәрләр янәшә бара. Күпсанлы повесть һәм хикәяләре – моның ачык дәлиле. Бу китап та «сайланма әсәрләр»не хәтерләтә. Әмма аның иҗатының нигезен барыбер шигърият тәшкил итә. Алар шагыйрәнең язмыш сукмаклары буйлап юл саба. Нинди генә гыйбрәтле тукталышлар очрамый аңа?! «Сагыну», «Мәхәббәт», «Хыянәт», «Үкенү»... Бары ике җан өчен кыйбла булырдай изге тукталышлар... Шагыйрә безне әнә шулар буенча сәяхәт итәргә чакыра.

ПРОЗА

Нәҗибә САФИНА
**«Каеннар ник кара таплы»**




Татар әдәбиятында «шагыйрь прозасы» дигән төшенчә аерым игътибарга лаек. Ялкынлы шагыйрә йөрәге иң нечкә хисләрне дә проза юлларына сала белә. Нәҗибә Сафинаның бу китапка тупланган хикәяләре дә аның проза жанрына табыну дәрәҗәсендә хөрмәтен күрсәтә. Автор ул хикәяләр аша тормыш тудырган фәлсәфи сорауларга җавап бирергә омтыла. Җавап көтүчеләре кемнәр диегез әле? Яшүсмерләр! Китап үзе дә «Каеннар ник кара таплы?» дигән сорауга символик җавап кебек. Чыннан да, ә каеннар нигә кара таплы соң?

ШИГЪРИЯТ

Рифә РАХМАН
**«Синең җанга узсам...»**




Җыентыкта урын алган шигырьләр темаларының киңлеге, хис-тойгылар өермәсе кузгата алуы, авторның дөньяга, вакыйгаларга, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләргә үзенчәлекле карашын чагылдыруы белән аерылып тора. Лирик герой бай тормыш тәҗрибәсе туплаган, язмышында хәсрәтләр дә, шатлык-куанычлар да мул булган, яшәүнең кадерен һәм тәмен аңлаган хатын-кыз сурәтендә күз алдына килеп баса.

ПУБЛИЦИСТИКА

**«Шимберем – олы тарих эзләрендә»**




Документаль чыганакларга нигезләнеп язылган бу китап борынгы татар авылы – Әтнә районы Яңа Шимбер тарихына багышлана. Төзүче-автор Тәэминә Биктимированың туган авылы ул. Аның тамырлары, гомеренең чишмә башы – шушында. «Кайда гына булсам да, нинди гүзәл җирләрне, калаларны күрсәм дә, авылымны, туган туфрагымны сагынып яшәдем. Уйларым белән аның үткән кайтавазын ишетәсем, еракта югалып калган эзләремне яңартасым, күңелемнән нәсел-ыруымның изге рухы белән күрешәсем килә», – ди ул. Автор бу максатына ирешкән.

# МӘРЬЯМ ӘНИ



Мәдинә
АВЗАЛОВА

## Бу дөньяда ул япа-ялгыз. Күрше апасы булмаса, ничек яшәр иде?!

Фото: www.pexels.com

Аның күзләре зәп-зәңгәр. Диңгез төсендә. Мәрьям апа сөйли-сөйли дә, аңа карап: «Гел әнисе инде...» – дип куя. Каршыбызда дәшми генә, сүзгә кушылмый гына безне тыңлап утырган ир-егет колясkасын йокы бүлмәсенә таба шудырып, күздән югала. «Үзе әйбәт малай ул, – ди әңгәмәдәшем, моннан күп еллар элек булган вакыйгаларга кайтып. – Тик нишлисең, тормышы шулай килеп чыкты».

Күз ачып йомганчы узып киткән кыска гына гомерендә niләр күрәсеңне Аллаһы Тәгаләдән гайре берәү дә белми шул. Барысы да һич уйламаганда-көтмәгәндә һәм бик тиз була. Матур гына яшәп яткан гаиләдән башта әти кеше китеп бара. Иртә китә. Ул чагында Маратка әле 7 яшь тә тулмаган. Аннары әнисе... Яман авыру аны ярты ел эчендә аяктан ега. Авыр минутларында янында күршесе Мәрьям апа була. Үләр алдыннан ул аңа соңгы васыятен әйтә: «Баламны ташлама!» – ди. Балалар йортында үскән хатынның бер якын кешесе, туганы булмавын белә күршесе. Әлбәттә инде, малайны карар, булдыра алганча тырышыр. Кулыннан килгәнчә... Тулы ятим калган балага карата дәүләтнең үз законнары да бар бит әле аның.

Әнисенең үле гәүдәсен алып чыгып киткәндә, баланың аның аякларына капланып елауларын Мәрьям апа әле дә онытмый. Исенә төшергәндә күзләренә яшь килә. Иганәчелек бүлеге хезмәткәрләре

эшне тиз тота. Малайны шәһәр читендә урнашкан балалар йортына озаталар. Киткәндә Марат күрше апасының кочагына ташланып, үкси-үкси елый. «Озакка алып китәләрме, кайчан кайтам мин өемә?» – дип өзгәләнә бала. «Елама, яныңа барып йөрермен, еракка китмисең. Ә кайткач гел яныңда булырмын», – дип тынычландырырга тырыша апасы.

Сүзендә тора: малайны онытмый. Аның ничек үскәнен, нинди уйлар белән яшәгәнен, кем булырга хыялланганын... барын-барын белә ул. Марат аннан берни дә яшерми. Апасы аның өчен иң якын кеше, бу дөньяда аннан башка сер бүлешер беркеме юк аның. Малай, малай дибез... Ә малайга инде, баксаң, 18 яшь тулган.

...Армиядә хезмәт итеп, дөнья күреп, ил гизеп кайткан егет кайчандыр иң кадерле кешеләре яшәгән фатир ишеген ачып кергәндә ниләр уйлагандыр, ниләр кичергәндер, анысы билгесез.
Ә менә Мәрьям апа егет булып җиткән зәңгәр күзле малайның исән-имин туган нигезенә әйләнеп кайтуына чиксез бәхетле иде. Күз-колак булып торырга да уңай, биргән вәгъдәсен онытмый ул.

Марат бер оешмага шофер булып эшкә урнаша. Әтисе дә шофер иде. Авариягә очравы да әлеге дә баягы эше белән бәйле. Әнисе исән булса, «шофер булмыйсың», дип кырт кисәр иде дә бит... Тик егетнең әллә ни сайланыр мөмкинлеге юк. Уку турында уйламый инде ул хәзер. Аның да бар иде лә хыялы... Табиб буласы, әнисе кебек үлем түшәгендә ятканнарны дәвалыйсы килә иде аның. Булмады. Андый мөмкинлекләр безнең кебек ятимнәргә бирелми дип кул селтәде дә, үз җаена барган тормыш мәшәкатьләренә чумды. Мәшәкать дигәне шул инде... эш. Иртә таңнан чыгып китә, кара төн уртасында кайта. Өстәлендә һәрчак күршесе кертеп калдырган ризык булыр. Фатир җыештырылган, тәрәз төбендәге тамчы гөленә су сибелгән. Шул гомердән бирле карап торган бит әнисенең яраткан гөлләрен! Әнә тагын күлмәкләрен юып, үтүкләп куйган. Нинди кеше бу, ә?! Андыйлар, булса да, меңгә бердер ул.

– Син миңа әнием кебек. Сиңа шулай дип әйтсәм ярыймы?

– Әйт, – ди күршесе, – тик «Мәрьям әни» дип әйт. Әни ул бер генә була... – Инде алай булгач сүземне тыңла, бөтен акчаны эшләп бетерә алмассың, әзрәк үзеңне кара. Өйләнеп җибәр әнә. Яшең бара, – дип киңәшен бирәсе итә ул.

– Соңыннан ник әйткәнемә үкенеп бетә алмадым, – дип дәвам итә сүзен әңгәмәдәшем. – Әллә инде йөргән кызы булган, әллә шулай тиз танышты: биш-алты ай да үтмәде, өйләнеп тә куйды. Кызы баштан ук ошамады миңа. Ни сөйләшүе, ни үз-үзен тотышы... Бик әрсез дә күренә. Тора-бара кыланмышларыннан бөтенләй күңел кайтты. Беркайда эшләми, көне буе өйдә, дус-ишләрен җыя да ишекне бикләп куя. Ә Марат – эштә. Бер тапкыр шулай керсәм (ишекләрен бикләргә онытканнар, күрәсең), өстәл

## Авырлыктан чыгу юлын адәм баласы үзе сайлый. Тик юлы гына дөрес булсын.

янына тезелешеп утырганнар да, кәеф-сафа корып яталар. Салмыш үзләре. Туздырмакчы идем, куып чыгардылар. «Син кем әле монда? Команда биреп ятасың», – ди хатын. Маратка икенче көнне әйттем аннары, юньлегә түгел бу, дидем. Юаш малай ул. Дәшми генә мине тыңлап торды да: «Сөйләшеп карармын», – дип, башын аска иеп кереп китте. Сөйләшкәндерме, юкмы – белмим, һәрхәлдә, сизмәдем. Хатыны кунарга кайтмыйча кайдадыр йөри башлагач, Марат уянып киткәндәй булды. Шулай итеп, яши башлауларына бер ел да узмады, хатын бөтенләй юкка чыкты. Шул... аннан аерылыштылар. Бармый баланың тормышы, – ди ул офтанып, – бармый.

Күрәсең, язмыш адәм баласын эзгә-эз сагалап йөри. Иң яманы, иң авыры соңыннан була. Яше утыздан узып барган ир-егетнең төшенкелеккә бирелгән чакларын еш күрсә дә, Мәрьям апа әллә ни игътибар итми торган иде. Кемдә булмас андый хәл. Янында аннан башка бер кешесе юк ич Маратның. Тик берсендә ул аның күз яшьләрен күреп, түзә алмый: «Ни булды сиңа, бала?» – дип сорыйсы итә. «Авырта, сызлый, үтерә инде, Мәрьям әни. Ни эшләргә дә белмим», – дип, сәер төскә керә башлаган сул аягына төртеп күрсәтә. Мәрьям апа текәлеп карап тора-тора да, сискәнеп китә. «Хастаханәгә керәк сиңа...»

Тик алар соңга калган булып чыга. Егетнең аягын саклап кала алмыйлар. Гангрена башланган. Хастаханәдән ул бер аягында, култыксага калып кайта. Ә бераздан... коляскага.

– Нишләр инде, ни хәлләр итәр дип нык борчылган идем. Үземнең дә мәшәкать муеннан. Кызым, улым, оныкларым дигәндәй. Һәркайсына ярдәм, игътибар кирәк. Таң тудымы, иң беренче шушы баланы искә төшерәм. Уянды микән, тамагына ашады микән... Кызганам мин аны. Ничек шулай булды ул? 1 нче группа инвалид ул хәзер. Эшләми, гел өйдә...

Башың, кулың эшләсә, өйдә дә әллә ниләр майтарырга була икән. Марат эшсез тормый. Кемнең кер юу машинасы ватыла, кемнең телевизоры – күрше-күлән аңа мөрәҗәгать итә. «Үз эшеңне ачып җибәр, дип әйтәм мин аңа, – ди Мәрьям апа, тавышын бераз күтәрә төшеп. Егет ишетсен ди торгандыр инде. – Сөйләшергә, кеше белән аралашырга дигәндә... юк инде аннан», – ди ул кулын селтәп.

Шулай күренә. Минем дә Марат белән сөйләшү барып чыкмады. Мине күргәч, тизрәк бүлмәсенә кереп китү ягын карады. Хәер, каршымда – аны үз баласыдай якын күргән, авыр минутларында гел янәшәсендә булган, аның өчен ут йотып торган күршесе – олы йөрәкле, гаҗәеп киң күңелле «Мәрьям әни»се булганда, бәлкем, белгән кадәре дә җитәдер.



# ҮЛӘНЧЕ



Гөлнур
САФИУЛЛИНА

**– Түндербаш – болиголов крапчатый дигән үлән турында бөтен кешенең дә ишеткәне бардыр. Яман шештән дәвалану өчен кулланалар аны. Мин түндербашны Ульяновск ягына барып җыям. Икееллык агулы үсемлек ул: бер елны тишелеп чыга, икенче елны гына чәчәк атып, орлыгын коя. Төнәтмәсен аракы яки спиртка салып ясыйсың. Иң файдалы өлеше – чәчәкләре. Әмма аны киптергән килеш кулланудан файда юк: составында кониин бар – ул шунда ук очып бетә. Түндербашны җыйганда спиртны үзең белән алып барасың: чәчәкләрен кайчы белән кисеп аласың да, шунда ук банкага саласың. Аны кулланганда гына түгел, ясаганда да бик сак булырга кирәк. Түндербаш төнәтмәсе салынган банкага «агу» дип тә язып куям. Дөнья хәлен кем белгән: бәлки синең белән нидер булыр, ә төнәтмәне кемдер: «Бу нәрсә икән?» – дип, эчеп карар...**

Сарут... Андыз тамыры... Бәбкә үләне... Чирәм... Ул бер үләннән икенчесенә күчә, аннан өченчесенә: кайда, нинди җирдә үсә, кайчан җыярга, нинди чирдән файдалы... Рушания ханым үләннәр турында, мөгаен, көннәр буе да сөйләп тора аладыр. Аяклы энциклопедия!

– Үләннәр күңелемә бер рәхәтлек бирә... Гел шулар белән генә шөгыльләнер идем. Капчык-капчык дару үләннәре җыюның бер авырлыгын күрмим. Аз гына буш вакытым булды исә урманга чыгып китәм...

Рушания ханым Минсәгыйрованы үзе яшәгән Спас районының Болгар шәһәрендә генә түгел, инде бөтен республикада үләнче дип беләләр. Юк, юк, табиб түгел ул. Казан химия-технология институтында белем алган. Кияүгә чыгып, биш бала тапкан. Мәшәкатьләре гел җитәрлек булган: йорт тулы бала-чага, терлек-туар, бакча... Кунакчыл йортларыннан кеше беркайчан өзелмәгән: Болгарга кем генә килсә дә, ире – Спас районы мөхтәсибе Фәрхад хәзрәт барысын да өенә чакырган. Хәзрәте күпме кешегә дисә, Рушаниясе шуның кадәргә табын корган. Ә дару үләннәре белән мавыгып китүе...

– Олы улымның никахын өйдә генә үткәрдек – бакча янына зур чатыр куйдык, шунда табыннар кордык. Бөтен нәрсәне өйдә генә әзерләдек. Җиңел булмады, билгеле... Хәзрәтнең кунак чакырырга яратуын әйттем инде – никах мәҗлесенә ике йөзләп кеше килергә тиеш иде. Өйдәге плитәләрдә урын калмагач, шулпаны мунча өйалдындагы плитәгә куйган идем. Кәстрүлне күтәреп алганда аягыма нидер булды. Авыртса да, түздем, узар дип уйладым. Озак та үтми, хаҗга киттек. Анда инде аякка баса алмыйча, хәзрәткә тотынып кына йөрдем... Авыртуымның сәбәпләрен эзли башладым. Мин бухгалтер булып эшләгән оешманың офисы элеккеге типография бинасында, хәреф җыю цехы булган урында урнашкан иде. Типографиядә эшләгән апаларны берәм-берәм искә төшердем: кемнеңдер аяклары авырта, кайсынадыр инсульт булды, кемдәдер склероз башланды... Офистагы 25 яшьлек бер

егеттә исә онкология. Әйе, авыр металлар беркая да китмәгәндер, шушы диварларга сеңеп калгандыр… Канны чистартырга кирәк дигән нәтиҗәгә килдем. Тик дарулар түгел, ә үләннәр белән! Китаплар укырга керештем. Дингә килгәч тә, башта китапларны шулай су урынына эчкән идем. Укырга яратам мин! Кемдер алтынга, байлыкка кызыккан кебек кызыгып җыям китапны… Күңелдә сорауларым бихисап иде. Нинди үләннәр канны чистарта, кайсылары сөякләрне, кан тамырларын ныгыта? Инсульт булмасын өчен нинди үләннәр эчәргә?.. Үләннәр белән шөгыльләнә башлагач, үземдә бер яңалык ачтым: күз хәтере көчле икән миндә. Моңарчы кешеләрне генә шулай яхшы хәтерлим дип уйлый идем. Үләннәрне дә истә калдырам, берсен икенчесе белән бутамыйм икән. Кат-кат күрсәткәннән соң да бик күпләрнең тагын: «Ә бу нинди үлән?» – дип сорауларына тәмам аптырадым башта. Аннан аңладым: Аллаһы Тәгалә бөтен кешегә дә бер үк сыйфатларны бирми. Димәк, бу – миңа бирелгән сәләт…

Үләннәр эзләп ерак барасы түгел, урман аларның өсләренә авып тора – өйләре янында ук. Бара, таба, җыеп кайта, киптерә. Дәвалауны, әлбәттә, үзеннән башлый: курслап-курслап эчәргә керешә. Үзе гел күзәтә: файдасы бармы-юкмы? («Мин үләннәрне аерым кулланырга яратам. Булышамы-юкмы дип тикшерү өчен дә шулай җиңелрәк. Ә үләннәрнең булышасына бик ышандым. Аллаһы Тәгалә берсен дә юкка гына яралтмаган».)

Төпчегенә – Фатыймасына бала тудыру йортында инфекция иярткән булалар. Кечкенәдән ике атна саен чирли ул: ангина белән тилмерә. Антибиотик арты антибиотик алыштыралар… Кызын әрекмән һәм андыз (девясил) тамыры белән дәваларга тотына Рушания. Икесен бергә кушып кайната: бер аш кашыгы тамырны ярты литр суга сала. Фатыйма бик тыңлаучан бала – әнисе кушканча барысын да эчә. Бетә бит ангина! Котылалар! Әмма профилактика өчен тамырларын эчертүне дәвам итә Рушания. Кызы институтка укырга кергәч, порошок итеп ясап җибәрә башлый. Каникулга кайткач та, Фатыйманың иң беренче соравы үләннәр турында: «Кайсын эчим?» Әнисе әзерләп эчертә бит! Иртәнге намазга торгач, иркәләп уятып, әнисе эчерткән үләннәрнең дәвалау тәэсире тагын да көчлерәк. («Нәрсә җыярга белмәгән кешеләргә мин шул ике тамырны гына җыярга тәкъдим итәр идем: әрекмәнне һәм андызны».)

Фатыйма терелгәч, канатланып, кыюланып китә ул.

Бер киңәшмәдән хәзрәте бик каты авырып кайтып керә. Сирәк, әмма каты авырый ире. «Температура төшерәм дип, дару эчми тор. Миңа ышансаң, аларсыз да терелтергә тырышам үзеңне», – ди Рушания. Чәй урынына аңа бертуктаусыз нарат бөресе кайнатып эчерә. Хәзрәт өч көндә аякка баса. «Моннан ары дару алмыйбыз», – ди Рушания.

Алар өендә, чынлап та, дарулар юк хәзер. (Йод, водород перекисен санамаганда). Аның каравы, бөтен җир капчык-капчык үлән белән тулган. Яз җитүгә, яңалары белән буталмасын дип, искеләрен тавыклар астына сала икән. (Сүз уңаеннан, үзең җыйганда үләннәрне – ике, тамырларны өч-дүрт ел да кулланырга ярый, ди ул. Спиртлы төнәтмәләрне исә ун ел буе да сакларга була.)

Дарулар урынына кул астында нинди үләннәр тотамы?

Усак каерысы! Әгәр температура икән, аннан да әйбәте юк, ди. Ләкин ул яз башында – яфрак ярганчы, бөреләнгәнче җыелган булырга тиеш. Салкын тигәндә дә иң беренче усак каерысына үрелә. Ашкайнату системасы белән бәйле борчулар (ашказаны авырту, күңел болгану) бар икән, ак әремне берни дә алыштыра алмый. Бер чеметем җитә. Тәмам чәчәкләнгәч, вак кына сары шарлар барлыкка килгәч, сыдырып кына аласың да, кулың белән уасың. Ул ютәлдән дә әйбәт. Үт кудыргыч сыйфатка да ия – күп проблемалар кешенең үт сыекчасы начар киткәннән килеп чыга бит. Ак әрем баш авыртуны да баса, паразитларны куа.

– Утызлап төр үлән җыямдыр. Күкебаштан (медуница) башлыйм. Урманда язын чыккан иң беренче аллы-гөлле чәчәк ул – яз иртә килгәндә апрель ахырында ук очрый. Аны нәкъ менә чәчәк атканда җыярга кирәк. Күкебаш хәтта туберкулезны да дәвалый! Аннан – кыр наратбашы чираты. Әрекмән тамырын да, тузганакныкын да, һиндыба (цикорий) тамырын җир эрү белән җыям – көчле чакта. Гомумән, тамырларның барысын да диярлек иртә язда яки җир туңганчы көздән җыярга кирәк. Шактый мәшәкатьле эш ул… Кайсы елны андыз тамырына да иртә язда барам. Дару үләннәренең күбесе безнең аяк астында ук үсә. Наратбаш, мәсәлән. Известь җитмәгән урыннарда күп очрый. Кан тамырларын гына түгел, безнең бит тиресен дә сыгылмалы ясый. Матурлык үләне! Гомумән, составында кремний булган үләннәрне даими рәвештә эчсәң битләр шомара. Наратбаш – сөякләрне ныгыта, кальцийның үзләштерелүенә булыша. Аны гел куллансаң, тешләрең ныгый. Менә минем яшьтә тешләр елдан-ел тизрәк җимерелергә тиеш кебек, әмма моны сизмим – кыш буе чәйгә наратбаш кушам. Әле оныклар җәйге каникулга кайтты: һәрберсенә чынаякка берәр наратбаш үләне төнәтеп бирсәң, теш табибына йөрергә дә кирәкмәячәк.

Озакламый тигәнәкчек (репешок) дигән үләнне җыячакмын. Ул бавырны, канны чистарта, үтне куа, ютәлне куптара, кимерчәкләрне савыктыра, авыртуны баса, ашказаны-эчәк авыруларына килешә. Гомумән, файдасы тимәгән бер әгъза да юктыр. Сөт кушып, чәй урынына эчәргә мөмкин: битнең төсләренә кадәр үзгәреп китә. Сарут тамыры сөякләр өчен файдалы, кан тамырларын да чистарта, ныгыта, буыннарга тоз утырудан, кимерчәкләрне ашалудан саклый. Аяк астыннан иелеп өзәргә мөмкин булган тагын бер файдалы үлән – бәбкә үләне (спорыш). Аны чәй урынына төнәтеп эчсәң, бөергә, бәвел юлларына таш утырмый: ул ташларны әкренләп эретә, кисәк кузгатмый.

Аир тамырын Идел буеннан җыям. Көчле дәвалау үзлегенә ия! Ялкынсынуларга каршы кулланып була, ирләр өчен файдалы. Ашказаны согының әчелеге түбән булганда бик булыша. Әгәр ашказаныгыз авырта икән, димәк, ул түбән – күтәререгә





тырышырга кирәк. Югары булса, ашказаны тимерне дә эшкәртә.

Будра плющевидная дигән үлән бар. Татарча исемен тапмадым – шуышма бөдрә дип үзем куштым. Бөтнеккә охшаган, әмма исе авыррак. Ул хәтта бавыр циррозын да дәвалый. Аны, гомумән, кырык төрле чиргә дәва (сороканедужник), диләр. Киптереп тә эчәргә була. Спиртка салып, төнәтмә итеп ясасаң, биттәге бетчәләрне дә бетерә. Әмма дозасын бик белеп кенә кулланырга кирәк: бөдрәдә аз гына агу да бар.

Любисток дигән үлән исә бакчаларда үсә – исе сельдерейга охшаган. Аны чәчәк атканнан соң инде кулланырга ярамый. Җыеп, тәмләткеч урынына кулланып, аракы эчә торган кешенең бөтен ризыгына салсаң, организмнан токсиннарны чыгара, чистарта – организм аракыны кабул итми башлый, кеше аңардан бизә.

Ә кара әремне чебиләр өчен җыям – ул аларның паразитларын куа. Тавыкларны яз җиткәч урамга чыгарсаң, алар иң беренче шушы кара әремне эзләп табып чукыйлар. Кычыткан белән кайнатып, чебиләргә суын эчерәм...

Рушания ханым бер үләнне дә календарьга карап җыймый – кайсысы кайсы вакыт өлгергәнен болай да белә. Аның телендә иң еш кабатланган сүзгә өйдәгеләр күптән күнгән: «Менә хәзер шул үләнне җыеп алырга кирәк...» Әмма урынын белсәң дә, үзең генә чыгып китә алмаган чаклар да бар – кайчак 30–40 чакрымга барырга кирәк. Хәзрәтнең эш режимына көйләнми чараң юк... Бик күп үләннәрне Фәрхад хәзрәтнең туган авылына – Татар Такталысына барып җыялар. Болгардан 40 чакрымда – олы юллардан читтә утырган авыл ул.

Андыз тамырын эзләп сазлыклы урыннарга баралар – анда да хәзрәтсез булмый. Язын өлгермәсәләр, көз көне – сентябрь ахырларында, җир катканчыга кадәр җыялар. Рушания андызны көйгән сабагы, тамырының исе буенча да таный. Андыз янында аксыргак дигән бик агулы үлән үсә. Көзен сабаклары кипкәч, җыйганда бутау ихтималы зур. Шуңа күрә дә ул: «Кеше үзе белгән үләнне генә җыярга тиеш. Йә аларны таныган берәрсе белән җыярга барырга, йә үләнне белгән кешедән генә алырга кирәк», – ди.

– Сәламәтлегебез какшауның өч сәбәбе бар дип саныйм, – ди ул. – Беренчесе – дөрес тукланмау (ярамаган ризыклар ашау, витаминнар, йод җитмәү); икенчесе – организмга физик зыян килү (бәрелү, имгәнү, сыну); өченчесе – психоэмоциональ халәт. Шуңа күрә үләннәр белән генә бөтен чирне дәвалап була дип ялгышмаска кирәк. Физик зыян килгәндә, кан составын яхшыртып кына терелә алмыйсың бит, мәсәлән... Иң авыры – психоэмоциональ халәт. Ул кешене эчтән җимерә. Тынычландыргыч үләннәр эчеп кенә котылып булмаска мөмкин. Комплекслы якын килергә – организмны гармониягә китерергә тырышырга кирәк. Стресс вакытында нинди матдәләр организмнан китә – шуларны тулыландырырга. Әйтик, менә андый чакта кортизол дигән гормон бүленеп чыга, ә ул буыннарга җимергеч тәэсир итә. Олы кешегә кальций эчү инде шактый куркыныч. Эремчек, сыр кебек ризыклар даими ашасаң да, кальций сеңми, шуңа составында кремний булган үләннәр эчәргә кирәк. Кремнийга бай кыр наратбашын июль ахырына кадәр дә җыярга ярый.

Үләннәрне вакларга Рушания ханымның махсус тегермәне бар. Читтән караганда бик гади күренә ул: алюмин кәстрүл, «болгарка», ниндидер пычаклар... Үләнченең шундый хыялы барын ишетеп, кулы эш белгән бер оста ясап биргән. Аңа кадәр биш каһвә тарткычын ваткан ул.

Рушания ханымның тагын бер хыялы бар әле. Бурадан салынган келәт! Ниндидер үләннең кирәге чыккан саен чормага менеп йөрү дә читенрәк. Ә келәт башка булыр иде: ул анда үләннәрен таратып куяр иде, капчыкта саклыйсын – капчыкка тутырып, эләсен – элеп...

Ниһаять, гел тел очында торган сорауны бирергә җай чыга: чәйгә нинди үләннәр куша икән ул? Гади чәй генә эчмидер инде үләнче!

– Чәйгә карлыган яфрагы, кышын әле кайвакыт ботагын да алып кереп салам. Карлыган организмнан тозларны куа: аны җәй буе эчсәң дә бик әйбәт. Май аенда җыеп калырга тырышырга кирәк... Бөтнек. Аның бездә әллә ничә төре үсә. Мин үзем «мята перечная» дигәнен яратам. Йөрәк ритмында үзгәрешләр башланса, беренче мәлләрдә ул аны дәвалый. Берәр ай эчәргә кирәк. Чәчәк атканчы җыйсаң әйбәтрәк – аннары көче кими... Чирәм салам – ул да организмда утырган тозларны куа. Даими эчсәң, бөердәге ташларны эретә хәтта... Наратбаш үләне кушам – файдасы турында әйттем инде... Чәйгә салу өчен кыш көне зирек күркәсе җыябыз. Аны бөтен кешегә киңәш итәр идем. Ул организмнан токсиннарны чыгара. Бер уч күркә җитә бер пешерергә. Яшел чакта түгел, нәкъ менә каралгач кына җыярга кирәк, әйткәнемчә, көз ахырында, кыш башында... Мәтрүшкәне вакыт-вакыт кына кушам. Балалар кайткач, мунчадан чыккач... Аларга гел җыеп җибәрәм: шәмәхәсен дә, сарысын да. Сүз уңаеннан, сары мәтрүшкә депрессиядән дә булыша. Менә хәзер озакламый ясмин (жасмин) чәчәк ата: чәчәгенең дә, яфрагының да депрессиядән файдасы зур.

Кайчак гел кырлыганга (иван-чай) күчеп алам. Күп кеше аны чәчәк аткач җыя, әмма чәчәк аткач күп үләннәрнең файдалы сыйфатлары кими. Ә тубылгыны (таволга), мәсәлән, нәкъ менә чәчәк аткач җыярга кирәк. Баш авыртамы, салкын тидеме – чәчәгеннән аз гына чәйгә салып эчәсең. Ул иммунитетны күтәрә.

Июль аенда сырганакның (облепиха) яфрагын ферментлап, чәй итеп ясап куярга мөмкин. Җыйган яфракны иттарткыч аша чыгарып, пыяла яки эмаль савытка салып, өстен тастымал белән каплап кояшка куясың. 3–4 сәгать үз согында торсын. Аннары юка гына итеп җәеп киптерәсең. Иммунитетны күтәрә торган бик файдалы чәй килеп чыга...

Әйе, Рушания ханым хаклы: үлән белән дәвалану өчен бик зур тырышлык кирәк. Дару кабып кына куясы җиңел шул... Әмма үләннәр ярдәмендә чирдән бөтенләйгә арынырга мөмкин – монысы мөһимрәк.

Тагын бер мөһим кагыйдә: үләннәр кулланыр алдыннан табиб белән киңәшләшү мәҗбүри!

# ТАТАР РАДИОСЫНА — 20 ЕЛ

Татар халкы гомер-гомергә җырга-моңга гашыйк. Гасырлардан килә ул. Безнең әби-бабайларыбыз шатлыгын да, сагышын да җыр аша белдерә торган булган. «Кара урман», «Гөлҗамал», «Тәфтиләү» җырлары буыннан-буынга күчеп, хәзерге көннәргә килеп җиткән. Шушы көйләр әле дә күңел кылларына кагыла, күзләрдән яшьләр тамыза. Җырлаучысы булганда, җыр яши, диләр. Җыр – халыкның җаны. Замана үзгәрү белән халыкта җырга карата зәвык та үзгәрә. Бүгенге җырлар элеккеләренә караганда шактый аерыла: цивилизация үсеше белән җыр индустриясе дә барлыкка килә. Совет чорында һәр өйдә радио нокталары эшләп тора иде. Без рәхәтләнеп татар җырчылары, аларның тормышы, эшчәнлеге белән танышып бара идек. Интернет челтәре барлыкка килсә дә, радиолар эшен туктатмады. Хәзерге көндә жанр, эш стильләре белән бер-берсен кабатламый торган радиолар эшләп килә. Машинада да, телефон аша да яраткан радиоларыбызны тыңлап ләззәтләнәбез.

Татар җырларын көне-төне халыкка җиткереп торучы «Татар радиосы» – иң популяр радиоларның берсе. Ул үз эшен 2000 елда башлап җибәргән иде. 26 майда Казанда «Татнефть Арена» боз сараенда «Татар радиосы» үзенең 20 еллык юбилеен зурлап билгеләп узды. Журналистлар өчен узган матбугат конференциясендә радионың баш мөхәррире Рамил Шәрәфиев чарага барлык билетларның да сатылып бетүен, тамашага җиде мең тамашачы җыелуын хәбәр итте.

Радионың алып баручысы Назлыгөл Сөнгатова хәбәр итүенчә, «Татар радиосы» – Россиянең иң зур милли радиостанцияләре бишлегенә кереп, татар телендә эшләп килүче беренче радиостанция. Бүгенге көндә «Татар радиосы» үзенең бай архивы белән горурлана ала: фондта меңнән артык җырчының 15 мең җыры саклана.

Татар милләтенең танылган күп җырчылары, шоуменнары иҗат юлларын «Татар радиосы»нда алып баручы булып башлап җибәрде. Тамашачылар арасында бик тә популяр Булат Бәйрәмов радионың беренче алып баручысы булды. Эфирда иң беренче яңгыраган җыр – Татарстанның һәм Башкортстанның атказанган артисты Айдар Галимовныкы. Халыкның яраткан радиостанциясе кумирларның тулы бер буынын үстереп кенә калмады: Алмаз Миргаязов, Әбри Хәбриев, Булат Бәйрәмов, Зөлфәт Зиннуров һәм башка алып баручылар «Татар радиосы» ярдәме белән зур сәхнәгә чыгып танылды. Татарстанның атказанган артисты Гөлназ Сәфәрова – 2004 елдан бирле радиода. Ул «Татар радиосы»на студент елларында ук урнашып, төнге эфирларны алып барды. «Радиога бер килеп эләккән кеше эфир тәмен белеп ала һәм аннан китә алмый. Хәзер туры эфирларда эшләмим. Ләкин радио составында кала бирәм», – дип сөйләде ул журналистларга.

«Татар радиосы»ның юбилей концерты да символик рәвештә Айдар Галимов чыгышы белән башланып китте. Татар эстрадасы мэтрлары Зөлфәт Хәким, Салават, Айдар Галимов, Элвин Грей, Әнвәр Нургалиев, Иркә, Рифат Зарипов, Данир Сабиров, Филүс Каһиров, Ришат Төхвәтуллин һәм башкалар чыгыш ясады. Концертны Гөлназ Сәфәрова, Айрат Ильясов һәм радионың баш мөхәррире Рамил Шәрәфиев алып барды.

РЕКЛАМА ХОКУКЫНДА







Шагыйрь Роберт Миңнуллинның «Килен төшкәндә» шигыренә композитор Рөстәм Яхин музыка яза. Һәм искиткеч матур җыр туа! Аны Татарстан радиосыннан беренче тапкыр Римма Ибраһимова яңгырата. Ул җырны инде кырык елдан артык җырлыйлар. Бер генә туй да ул җырсыз узмыйдыр!



Эльмира ЗАКИРОВА



# КИЛЕН ТӨШӘ БҮГЕН АВЫЛГА

Шагыйрьнең хатыны Клара Миңнуллина сөйли:

– Бу җырның ничек язылуы турында Роберт белән сөйләшкәнебез булмады. Алай да бер вакыйга һаман-һаман күңелдәге якты хатирәләрне яңарта. Көннәрдән бер көнне җыр булып яңгыраячак шигырь юлларын язарга ниләр тәэсир иткәнен дә, Робертны нәрсә җилкендергәнен дә беләм бит инде!

1967 елда таныштык без. Роберт Илеш районы газетасы «Маяк»та әдәби хезмәткәр иде ул чакта. Шигырьләре, язмалары чыгып тора. Аны бөтен Яркәй белә! Ничектер бер көнне Роберт миңа үз итеп, шаярткан булып, сүз катты. Якыннан аралашып, сөйләшеп йөри башладык. Язмышлар да бертөрлерәк: ул – Уфага, мин Пермьгә укырга дип китеп, икебез дә беренче елны керә алмыйча кайткан булганбыз икән... Аралашып киттек шулай. Җитмәсә, ул комсомол секретаре да әле. Комсомол укуларында очрашабыз, эштән кайтканда да, киноларда да «ялгыш» кына урыннар бергә туры килә башлады. Ипле, тыйнак, кайчак юмор белән, җиңелчә төртмә телләнеп сөйләшә торган бу егет, мине үртәп, «шәһәр кызы» дип йөрткән була. Мин Яркәй (Илеш районы үзәге) кызы булгач, авыл кызларыннан аерылыбрак торганмындыр, күрәсең. Роберт кичләрен мине Пушкин урамына – өйгә кадәр озатып куя. Шагыйрь кешегә Пушкин урамында яшәвем дә үзенчә шигырь кебек тәэсир иткәндер, мөгаен. Бер кичне шаярткан булып: «Туфлиләреңнең табаны бигрәк каты бугай. Тавышы бөтен урамны яңгырата», – димәсенме. Гарьләнүләрем! Үч иткәндәй әни туфлиләрен кигән идем. «Синең анда ни эшең бар!» – дидем үпкәләп...

...Клара сөйләгәннәрне Роберт абый Миңнуллин язып калдырган хатирәләр тагын да баета:

«Мин инде ул чакта районның иҗтимагый тормышында актив катнашучы, үземне җитди бер кеше итеп тоючы 19 яшьлек егет идем. Клара исә әле генә мәктәпне тәмамлаган, шактый беркатлы, балалыгы да чыгып бетмәгән бер сабый, кулга ияләшмәгән кыргый бер болан баласы. Мине үзе белән таганда атындыра, коймалар аша сикертерә, минем белән качышлы уйный. Кычыткан чыпчыгы инде менә! Нишлисең, олы башыңны кече итеп, бала-чага кебек йөрергә туры килә. Әмма кеше алдында култыклашып түгел, җитәкләшеп йөрү дә юк. Ә минем аның белән урам буйлап бөтенесен көнләштереп, култыклашып узасым килә... Киноларда шулай йөриләр бит. Ул ялындырырга ярата, ә миңа, холкым каршы килсә дә, ялынырга туры килә. Мин ул чакларымны – мәхәббәт белән мөлде-

# *Килен төшкәндә*

Роберт Миңнуллин сүзләре
Рөстәм Яхин музыкасы

*Ак күбеккә баткан юргалар*
*Кышкы юлдан ярсып чабалар.*
*Чак-чак кына аумый калалар*
*Салулаган чакта чаналар,*
*Арттан чаба бала-чагалар.*

*Мамык мендәрләргә төренеп,*
*Килен төшә бүген авылга.*
*Борынгыдан калган гадәт ул –*
*Авыл чыга каршы алырга,*
*Яшь кәләшне күреп калырга.*

*Җилкендереп ять-яшь кызларны,*
*Килен төшә бүген бер өйгә.*
*Кайда калды шундый чагым, дип*
*Авыр сулап куя әниләр,*
*Авыр сулап куя әбиләр.*

*Күптән инде ачып куйганнар*
*Килен төшкән өйнең капкасын.*
*Килен төшкән өйнең капкасын*
*Күтәргә дип кире япмасын,*
*Кайгы җиле килеп какмасын.*

рәмә тулы көннәремне сагынып искә алам. Аның ул карашлары, озын калын толымнарының исләре, аның елмаюлары, ялындырулары, көттерүләре, үпкәләүләре...»

Аннары инде дүрт-биш ел буена Сак белән Сок булып яшәүләр. Роберт абыйның Казан университетында, Кларaның Бөре педагогика институтында укып йөргән еллары. Ике арадагы сагыну хатлары, мәхәббәт хисләреннән телефон чыбыклары өзелер дәрәҗәгә җитеп кайнарланулар... Казан белән Бөре арасын таптаулар. Җае чыкса, чыкмаса да Робертның самолетта Казаннан Уфага, автобуста Уфадан Бөрегә ашкынып барулары... Институт тәмамлаган Клараның, аспирантурада калырга теләмичә, Илеш районы Исәмәт мәктәбенә рус теле һәм әдәбияты укытучысы булып кайтулары...

Әйдә, кабат Кларaны тыңлыйк әле.

– 1972 елның декабре. Яңа ел алдыннан, кышкы бер матур көндә Исәмәттән Аккүзгә дус кызым Ириналарга кунакка киттем. Безнең якларда Ирина, Лена, Светлана дип исем куюлар бар инде ул. Мин дә Клара бит... Урамда тымызык кына кар ява, агачларны бәс сарган. Авыл кышкы әкияткә чумган! Шунда ярымбозланган тәрәзәләрдән капка төбенә килеп туктаган... «кошёвой» чананы, җигүле атны шәйләп алдык! Иринаның егете Илфас һәм... Казаннан Яңа ел каршыларга кайткан Роберт! Ни уйларга белми торганда, битләре суыкта алланып янган егетләр капкадан килеп тә керделәр.

– Кызлар, сезне алырга килдек! – дип мутланалар.

– Киттек тизрәк! – дип, ике уйларга урын да калдырмыйлар.

Безгә ни, маҗара гына булсын! Кайчан әле арка терәп «кошёвка» чаналарга утырып җилдерер идек! Ялт кына киендек тә чыгып та утырдык! Егетләр куа гына! Атлары да ярсып чаба! Тизлектән чанабыз чак аумыйча салулый, үзебез карга мәтәлеп төшәрдәй булып очабыз гына! Мәзәк сүзләр сөйләп көлешәбез. Җырлап та җибәрәбез. Ул арада, томырылып, Шәммәткә барып та кердек! Арттан авыз ерып кул изәгән бала-чага, кызыксынып карап калган апалар күз алдыннан йөгерешеп узды. Карлары көрәп куелган капка янына килеп туктадык. «Кайтып җиттек, – ди Роберт елмаеп. – Әнкәй көтәдер...» Аһ иттем! Башта ук безгә барабыз дигән булса, үлсәм дә ризалашмас идем. Оялмыйча! Илфас белән Ирина серле елмаеп торган булалар. Алдан ук белгәннәр инде. Шулай итеп, Роберт, авыл күрсәтәм дигән булып, килен төшерү хәстәренә әзерләнә башлаган, мине әнисенә – киләчәктә кайнанам булачак Гөлҗәүһәр апага күрсәтергә алып кайткан булып чыкты. Ә язын – Роберт университетны тәмамлаганда без инде өйләнештек.

...Хыял офыкларын киңәйтеп, йола-гадәтләребезне гүзәл манзараларда тасвирлаган «Килен төшкәндә» җырының тарихы менә шундый икән. Ул һаман яңа, һаман популяр!




Фотолар: гаилә архивыннан.



# ЧҮЛЛӘГЕ ӘКИЯТ ДӨНЬЯСЫ



Әлфия САМАТ

**Дөньяның күп кыйтгаларындагы байтак илләренә сәяхәт кылырга туры килсә дә, Берләшкән Гарәп Әмирлекләренә (янәшәсендәге Согуд Гарәбстанына ике тапкыр һәм Мисыр илләренә баруымны исәпкә алмаганда) моңарчы юлым төшкәне булмады. Мөселман дөньясын тагын бер тапкыр күреп кайту теләге җиңеп чыкты – тәвәккәлләдем. Диңгез юлы буйлап зур лайнерда сәяхәт кылып, Гарәбстан ярымутравындагы берничә илдә булу үзе бер могҗиза кебек тоелды. Дубай, Абу-Даби, Катар, Оман – бу җирләргә аерым-аерым бара башласаң, вакыт һәм финанс ягыннан шактый кыйммәткә төшәр иде. Шәхсән үзем кайдадыр бер урында булып, диңгез суында коенып, комлыгында тән кыздырып ятарга сабырлыгым җитә торган кеше түгел – дөнья күреп, гыйбрәт алып йөрү барысыннан да кызыграк миңа. Шуңа күрә күңелемә хуш килә торган юлламаны да ярты ел алдан тәгаенләп куйдым.**

## *Costa Firenze*

Әкияттәгедәй могҗизалы сәфәр көткәнлегенә без баргач кына төшендек. Иң элек Costa Firenze лайнеры үзе шаккаттырды. Озынлыгы – 300, киңлеге 38 метрдан артыграк булган, 16 катлы йорт биеклегендәге бу «пароход»ка сыйган туристларның саны гына да 5 меңнән артык, һәм аларга хезмәт күрсәтүчеләрнең дә шул чама икәнлеген исәпкә алсаң, чыннан да, уш-акылларың китәрлек шул! Тәрәзәле, балконлы каюталардан иксез-чиксез диңгез киңлекләре җәйрәп ятканын күрәсең. Бер диңгез белән икенчесе тоташкан урындагы суның төсе үзгә булып, аларның берберсенә кушылмаганлыгын үз күзләрең белән күргәч, Аллаһы Тәгаләнең нинди хикмәтле илаһ икәнлегенә тагын бер кат инанасың... Ә лайнерның эчке тормышы – нәкъ бер шәһәрчек: ресторан, кафе, кибетләр, театр, казино, сәнгать-фотогалереялар, бию, күңел ачу, спорт мәйданчыклары, диңгез суы салынган бассейн, джакузи, сауна, массаж, матурлык салоннары, балалар өчен клублар, аквапарк һәм тагын әллә ниләр...

Биш йолдызлы отельдәге шикелле ике кешелек иркен каюталарга урнашкач, икенче көнебезне Дубайның чәчәкләр паркыннан башладык. Гектарлаган мәйданнарны биләп торучы (72 гектар икәнлеген соңрак белдем!) бу паркта иң гаҗәпләндергәне без

белмәгән ят исемле чәчәкләр түгел – анда иң күбе бездәге петуния һәм башка гади чәчәкләр, үрмәле гөлләр генә – менә шуларны төрледән-төрле фигуралар ясап, шулар өстендә бизәп үстерүләре сокландырды. Биредә бит ул – тулы бер парк, һәм ул ел саен кыш һәм яз айларында (җәйге 50 градус эсселеккә чыдамыйлар) бөтен дөнья илләреннән килгән ландшафт дизайнерлары тарафыннан яңа композицияләр белән баетыла. Күргән бер чәчәк фигурасына таң калып, фотога төшереп, туристларның агына да, карасына да, инде бер-берсенә генә тотынып йөри торган картқарчыкларга яки бер төркем балаларын ияртеп килгән эреле-ваклы гаилә кешеләренә сокланып йөри торгач, көн узганын да сизмәгәнбез. Менә бер урында «Карак чәй» (Исеме кызыкмы? Басым беренче «а» хәрефенә төшә) дигән язуны күргәч кенә, көндезге аш вакытын уздырып җибәрүебезне искә төшереп, әлеге чәйне татып карарга уйладык. Гадәти булмаган әлеге эчемлек бик туклыклы булып чыкты: составында нинди үләннәр һәм тәмләткечләр барлыгын төгәл генә белмәдек, әлбәттә, әмма ул ашыйсы-эчәсе килүне бик тиз басты.

Ашау-эчү димәктән, аның чутычамасы юк биредә, кайчан өлгерәсең, шул вакытта үзеңә кирәкле тәгам белән туклана аласың. Нинди ризыктан авыз итәсең килә: итальян кухнясымы (чөнки лайнер Италиянеке), Азия яки Кытай ризыкларымы – һәркайсының традицион ашамлыклары һәм эчемлекләре белән туклану өчен лайнерда 15 ресторан, 6 кафебар эшләп тора. Күзең төшкән әйберне үзең сорыйсың, нәрсә кирәк, күпме кирәк – салып бирәләр. Һәр кешенен үз картасы бар. Ә ул карта дигәннәре үз эченә синең турыдагы бөтен мәгълүматны сыйдырган: ул – каюта ишегенең ачкычы да, ут кабыза торган включатель дә, ул – фотолы паспорт та, банк картасы да, синең кайда нишләп йөргәнеңне тикшереп торучы глонасс та. Беркөнне кичен лайнердан соң гына чыгып киткән идем, мине эзләп, каютадагы юлдашларыма шалтыратканнар – корабль кузгалырга ярты сәгать кала кайтып кердем юкса...

# Әкияттәгедәй могҗизалы сәфәр

## көткәнлегенә без баргач кына төшендек.

### *Дубай*

Дубай – Берләшкән Гарәп Әмирлекләре составына кергән җиде әмирлекнең берсе. Шәһәрдәге «күкләргә тиеп торган» йортларны күзәтеп барсаң, бер-берсенә ошаганнарын очратып булмый, 50–60 катлы гына түгел бит алар, 100 дән артык катлы. Дөньядагы иң биек саналган Бурдж-Халифа (Халифа – Дубайның хәзерге җитәкчесе) Дубайдагы иң биек бина – 828 метр биеклектә, 163 катлы. Анда бик затлы отель дә, торак фатирлар да, ресторан, офислар һәм башка төрле күңел ачу урыннары да урнашкан. Туристларны 122, 148 катлардагы күзәтү мәйданчыгына кадәр алып менәләр. Бу – кошлар гына түгел, самолетлар биеклегенә тиң, аннан бөтен ярымутрау уч төбендәге сыман күренә. Ә менә әлеге манара-йорт янындагы музыкаль фонтанны күреп кайткан туристлар хәзер безнең илдә дә бик күп. Бу да – дөньядагы иң матур һәм иң биек фонтан дип санала. Хәер, Гарәп Әмирлекләрендә йөргәндә җир шарындагы «иң-иң»нәрдән саналган могҗизаи урыннар болар гына түгел. Әле былтыр көз генә дөньядагы иң биек Күзәтү тәгәрмәче сафка баскан. 250 метр биеклектәге бу күңел ачу тәгәрмәчен ясау өчен 2400 километр тимер бау, 11200 тонна металл кулланылганын әйтүгә, аның нинди мәһабәт тәгәрмәч икәнлеген аңлау кыен булмастыр! Тагын бер могҗиза: Дубайда метро җир астыннан түгел, күбрәк җир өстеннән, ягъни күтәртелгән күперләрдән уза, һәм ул автопилотка көйләнгән.

Ә бит ярты гасыр элек бу җирләрдә – Дубайда гына түгел, җиде әмирлеккә караган барлык урыннарда да – пальма агачы ботакларыннан ясалган куышларда хәерчелектә яшәгән гарәпләр гомер кичергән. Алар дүртәр айга көймәләр белән чыгып, балык тоткан, диңгез төпләренә чумып, энҗе бөртекләре эзләгән, хөрмә җимеше җыйган. Җирле халык комга тозлы диңгез суы сибеп катырылган юллардан йөргән. Автомобильләр бары тик җитәкчеләрдә һәм хәрбиләрдә генә булган. 170 ел буена ил белән хакимлек иткән инглизләрне җирле халыкның яшәү рәвеше бөтенләй дә кызыксындырмаган. Ниһаять, алардан котылгач кына биредә яңа тормышка юл ачыла башлаган. 1959 елда гарәп җирләрендә нефть ятмалары булуы ачыкланып, беренче тапкыр Европага өч-дүрт зур фура белән нефть сатып, казнага күп кенә акчалар кергәч, илнең беренче җитәкчесе шәех Зәйд Әл-Нахайян аерым яшәгән әмирлекләргә мөрәҗәгать итеп: «Әгәр сез бергә берләшергә теләсәгез, мин сезнең белән бу байлыкны бүлешәм һәм ничек телисез, шулай дәүләтегезне үстерергә мөмкинлек тудырам», – дигән. Шул дәвердән бирле Берләшкән Гарәп Әмирлекләре бербөтен илгә әверелеп (Оман белән Бахрейн гына кушылмаган), бүгенге көндә дөньяның иң гүзәл дәүләте булып яши. Янә шәех Зәйд Әл-Нахайян: «Дөяләрегезне бәйләп куегыз да, комга су сибеп, юллар ясагыз. Йөрергә җиңел булыр», – дигән. Һәрбер гаиләгә автомобиль биргән, йортлар салып керергә кушкан. Хәзер дә җирле халык үз өендә аерым хуҗалык булып яши биредә. Бер гарәпнең берничә хатыны булса, ул аларның барысына да нәкъ бертөрле йортлар төзеткән. Бер генә таләп куела, мөселман гаиләсе мәчет манарасыннан да биегрәк йортта яшәргә тиеш түгел. Кайчандыр нибары 13 автомобиль исәптә торган Дубайда, мәсәлән, бүген миллион ярым кыйммәтле чит ил машиналары җилдерә. Аларның чипчиста һәм конвейердан яңа гына чыккан шикелле, ватылмаган-яньчелмәгән булуы күзгә ташлана. Алай гынамы, биредә урамнарда оекчан йөрсәң дә, бернинди пычрак ияреп кайтмый. Бөтен җирдә яшеллек, чәчәкләр, күз явын алырлык итеп бизәп-матурлап ясалган архитектура күренешләре. Шул ук вакытта кырыс мөселман кануннары белән яшәүче гарәп илл-





# Мөселман гаиләсе мәчет манарасыннан да биегрәк йортта яшәргә тиеш түгел.

бер төре). Күп еллар элек аучылардан качып баручы бу җәнлек аларга үзе эчә торган төче су чыганагына юлны күрсәткән. Шуннан чыгып, шәһәргә дә әлеге җәнлекнең исеме бирелгән диелә риваятьләрдә. Төче су дигәннән, тозлы диңгез сулары әйләндереп алган ярымутрау һәм аның эреле-ваклы утрауларында – ул иң кирәкле ихтыяж, һәм бик кыйммәтле эчемлек санала. Эчәргә яраклы хәлгә китерү өчен, махсус заводларда тозлы суны төчеләндерергә туры килә. Аерым йортларда яки үз фатирлары белән яшәүче җирле халыкка айга бер тапкыр дәүләт исәбеннән бушлай ничәдер кубометр су бирелә. Әгәр артыграк тотасың икән – түлисең. Коммуналь хезмәтләр өчен дә 20 процент чыгымнарны хөкүмәт түли.

Шәех Зәйд мәчетенә мөселманнарга гына түгел, башка диннән булган туристларга да керергә рөхсәт, әмма аяклар, шәрә муеннар күренмәслек озын күлмәкләр кию (ирләр чалбаркүлмәктән), чәчләр капланып бетәрлек итеп яулык бәйләү – төп шарт. Эскалаторлар аша җир асты юлыннан шактый гына баргач, ниһаять, үзеңне көзгедәгедәй күреп торышлы ак мәрмәр идәннәрдән атлап, мәчеткә узасың! «Зур залдагы күз явын алырлык келәмнең мәйданы – 5500 квадрат метр, ә авырлыгы 35 тонна, Германиядә эшләнгән бер люстраның гына авырлыгы 12500 тонна», – дип сөйләп китә гид. Ә аларның матурлыгы! Менә шушы келәмнәрдә намаз укып, Раббыбызга теләк-догаларыбызны җиткерүнең рәхәтлеген аңлатуы да авыр!



■ Дубай Луврлы. Бирeдәге бөтен картиналар билгеле бер вакытта Луврның үзеннән китертелә, ә күчерелмәләре даими рәвештә бирeдә саклана икән.

ренә генә хас тыюлар да гаҗәп: машинаң пычрак булса, аны шундук алып китәләр, кычкырып көләргә, гарәп хатын-кызларын фотога төшерергә, бездәге шикелле ярымшәрә киенеп йөрергә рөхсәт ителми – болар әле кайберләре генә! Шуларга охшаш шактый гына чикләүләр булса да, Гарәп Әмирлекләре – иң куркынычсыз ил, 200 гә хәтле милләт кешеләре яшәгән илнең таләпләре – һәркем өчен дә уртак закон. Полиция бирeдә үз вазыйфаларын бик югары дәрәҗәдә башкара.

Әмирлекләрнең халкы 10 миллион чамасы булса да, шуның нибары 15 процентын җирле халык тәшкил итә, калганнары – чит илләрдән эш эзләп килүчеләр. Бирeдә гражданлык алу мөмкин түгел диярлек. Гомере буена җирле халык исәбендә яшәгән кеше дә, әгәр үз вакытында паспорт алмаган булса, ул рәсми рәвештә җирле кеше статусын ала алмый. Яшәү шартларының авырлыгына карамастан, паспорт алган кешеләр җирле халык саналып, хөкүмәт тарафыннан бирелгән бөтен өстенлекләрдән файдаланып яши бирeдә. Аларга медицина ярдәме, уку – бушлай, балалар туган саен тиешле күләмдә пособие биреп торыла, берничнди белеме булмаса да, эшкә урнашу мәҗбүри итеп куелган. Күпләрнең бизнесы бар. Чит ил кешеләре бирегә килеп, үз эшләрен ачарга теләсәләр, аларга хәзер спонсорлар эзләргә кирәк булмаячак икән. Иң кирәкле һөнәр ияләре – табиб, укытучы, инженер, архитектор, программист. Шундый белгечлеккә ия, инглиз телен яхшы белгән (гарәпчәне белсә, тагын да шәп!) кешеләр биш куллап эшкә алына.


### Абу-Даби

Дубайның берьюлы алты халыкара круиз лайнерын кабул итә ала торган диңгез портындагы Costa Firenze, төн буена хәрәкәт итеп, иртәнгә безне Абу-Даби әмирлегенә китереп җиткергән иде. Тәрәзәгә күз салсак: фирүзә төсендәге яшелле-зәңгәрле су, яхталар җилдерә, җирдә – экскурсантларны көтеп торучы автобуслар. Иртәнге ашка ерак барасы түгел, безнең каюта да ресторан белән бер тирәдә – лайнерның унберенче катында. Балык, диңгез ризыкларыннан әзерләнгән ашамлыкларны авыз итәбез, төрледән-төрле яшелчә, җиләк-җимеш – барысы да искиткеч тәмле. Абу-Дабиның 200 ләп утрауга сибелеп урнашканлыгын һәм нефть ятмаларының бирeдә Дубайдагыга караганда 15 тапкыр күбрәк икәнлеген гидыбыз үзбәк кызы Насыйбәдән белдек.

Абу-Даби гарәпчәдән «газәл-әти» дип тәрҗемә ителә (антилопаның

### Маскат

Маскат – гарәпчәдән «якорь ыргытылган урын» дигән мәгънәне аңлата. Археологлар фикеренчә, ул – ислам дине барлыкка килгәнче, 900 еллар элек нигез салынган борынгы шәһәр. Ил белән имам идарә иткән һәм ул имамат дип йөртелгән. 1944 елда солтанатка әйләнгән. Оман – иң куркынычсыз ил. Берничнди низагларга, сугышларга катнашмый, нейтралитет саклый, шунлыктан дөньяның иң зур илләре монда тынычлыкны яклаучы очрашулар уздырырга килә. Һәр җирдә гөмбәзләр, бизәкләп эшләнгән



Абу-Дабидагы шәех Зәйд (Ак мәчет) мәчете, Мәккә һәм Мәдинәдән кала, дөньядагы иң зур мәчет, берьюлы 40 мең кешене сыйдыра ала.
Ак мәрмәр диварлары, баганалары кыйммәтле ташлар белән инкрустацияләнеп эшләнгән. Мәчет янында – ясалма сулыклар, фонтаннар, чәчәкле, яшел чирәмле бульвар.

тәрәзәләр милли колоритны ассызыклый төсле. Күрше илләрдән Оманны ком чүлләре, таулар һәм диңгез сулары бүлеп торганлыктан, нефть ятмалары табылганчы, бу ил ябык булган. Ил төче су һәм уңдырышлы туфрак җитмәүдән интеккән. Җирле халыкка, тереклек итү өчен, ифрат зур көч куярга туры килгән, бу, билгеле, халыкның холык-фигыленә дә зур тәэсир ясаган: оманлылар – тыныч, бәйсез, үз-үзләрен тәэмин итеп, хисләрен белдермичә, үзгә бер ягымлылык белән сөйләшә торган бик кунакчыл һәм ярдәмчел халык. Ирләре дә, хатын-кызлары да эшли, чөнки тормыш итү кыйммәт. Дәүләт карамагындагы балалар бакчалары юк, аерым кешеләр тарафыннан оештырылган бакчалар гына, әмма алар кыйммәт, өстәвенә, ризыкны үзең китерәсең, йоклату юк, шунлыктан 4-5 яшьтән баланы мәктәпкә бирергә тырышалар. Шулай да хатын-кызга бушлай җир бирелә торган дөньядагы бердәнбер ил булып санала. Бирегә йортсызлар юк, хезмәт хакыннан салымнар тотылмый.

Мәчетләрнең күплеге хәйран калдыра, аларның һәркайсы хәйриячеләр акчасына салынган. Икенче гидыбыз Саша безне мәчеткә алып керде.

Ике рәкагать мәчет намазы укырга да өлгердек, әлхәмдүлилләһ! Аллаһым кабул кылсын! Ләкин вакыт чамалы, экскурсия бик тыгыз планлаштырылган. Саклану крепостьларына күтәрелеп, биектән Маскат шәһәрен күбрәк күреп, фотога алып каласы килә. Диңгезгә аякларны тыгып булса да тозлы су җылысын тойдык менә.

Оманнан тагын бер хикмәтле күчтәнәч алдым. Ул – ладан, ягъни безнеңчә әйткәндә, сагыз. Ладан агачларын, каен суы агызгандагы шикелле кисеп, сутын агызалар һәм киптерәләр. Ул өч-дүрт атнадан сагызга әйләнә. Ладанның күп төрләре бар һәм ул шактый кыйммәтле. Аны яндырсаң, өйдә хуш исләр чыга, антисептик буларак, медицинада, косметологиядә кулланыла. Ладанны сагыз итеп авызда тотсаң яки чәйнәсәң, тамак төбе авыртуын бетерә, авыз эчендәге микробларны үтерә, җәрәхәтләрне төзәтә. Кыскасы, Оманны ладан иле дип тә йөртәләр.

Дубайга кайткач, сәяхәтебезне Дубай-экспо күргәзмәсендә дәвам иттек. Монда инде, чыннан да, могҗизаларның могҗизасы! 200 гә якын ил үзләренең инновацияләрен күрсәтә. Шулай да үзебезнең Россия павильонын тапкач, күңелне ниндидер рәхәтлек хисе биләп алды, илебезнең кечкенә бер кыйпылчыгын тойдык анда. Павильонның төрле төсләрдәге торбаҗепләрдән үзенчәлекле гөмбәз рәвешенә кертеп эшләнгән конструкциясе үзе үк прогрессның бертуктаусыз үсешен чагылдыра сыман. Кешенең баш мие тудырган инновацияләрнең павильонга кергәч тагын да югарырак дәрәҗәдә дәвам итүен күреп тору, һәрхәлдә, миндә көчле тәэсир калдырды. Башта ук әйткәннәр иде, чыннан да, безнеке иң матуры икән!..

Лайнердагы һәм гарәп җирләрендәге могҗизаи сәфәребезнең тиз узып китүе бераз борчылдырса да, туган җиргә кайтасы килү дәрте барыбер көчлерәк булгандыр, мөгаен. Алма корты да шәфталу кортына әйтте ди бит: «Синдә җылы, рәхәт, синең ризыгың да тәмле, суың да татлы. Әмма үз өеңә җитәме соң?..» Минем дә туган илемә, өйкәемә кайтасым килә иде. Хуш, Costa Firenze! Хушыгыз, Әмирлекләр!..

### *Карак чәй*



Кәстрүлгә 1 литр су салып, 1 аш кашыгы кара чәй (яфраклы булса яхшы), 1 аш кашыгы шикәр комы һәм тәмләткечләрдән: чәй калагына элеп кызыл борыч, канәфер, дарчин, 7-8 данә кардамонны ваклап саласың һәм сүрән утта 10–30 минут кайнатасың. Шуның өстенә кәстрүлдәге чәйнең өчтән бере кадәр күләмдә кайнатылган сөт өстәп, кабартып аласың. Утны сүндергәч, ун минуттан чынаякларга бүлеп бирәсең. Эссе җәй көнендә сусауны баса, кышкы салкыннарда салкын тиюдән саклый торган бик шифалы, туклыклы һәм искиткеч тәмле чәй.



Тулысынча укыгыз »



Фото: ru.freepik.com



**Республика балалар клиник хастаханәсе кардиологы Ләйсән АЛИУЛЛИНА җавап бирә**

**? Балага тугач ачык артерия юлы (ОАП – открытый артериальный проток) диагнозы куелды. Зурлыгы – 3 миллиметр. Алты ай тулгач кабаттан УЗИ ясаттык, миллиметр ярымга кадәр ябылган, диделәр. Алга таба үзе ябылыр микән?**

Баланың карындагы үсешендә тайпылышлар булмаган очракта, ачык артерия юлы тугач та ябыла. Нормада ул 2–8 атна эчендә ябылырга тиеш. Ябылмаса, балага бер ай тулганчы аны неонатолог, педиатр, кардиолог контрольдә тоталар. 70–75% очракта балага бер яшь тулганчы ачык артерия юлы үзе ябыла. Кайбер балаларда 1 миллиметрга кадәр кечкенә ачык юллар шул килеш кала. Сездә уңай динамика күзәтелә. Иң мөһиме – ЭхоКГ, йөрәккә УЗИ ясатып, кардиологка күренеп торыгыз. Йөрәкнең үлчәме баланың яшенә, авырлыгына тәңгәл булырга, кан басымы градиенты нормада булырга тиеш. Баланың йөрәгендә, ачык артерия юлыннан кала, башка аномалия күзәтелмәсә, йөрәк үлчәме яшенә һәм авырлыгына туры килсә, аңа операция ясалмый. Бары тик контрольгә алырга киңәш итәбез. Режимны сакларга, саф һавада йөрергә, массаж ясарга, прививкаларны вакытында ясатырга, дөрес тукланырга кирәк. Шулай эшләгәндә ачык артерия юлы тулысынча ябылырга да мөмкин.

**? Соңгы вакытта кызыбыз актив уйнаган җиреннән, арыдым дип, диванга барып утыра. Урамда йөргәндә дә күтәрергә куша, бара алмыйм, ди. Кардиологка күренер өчен сәбәпме бу? Тагын нәрсәгә игътибар итәргә кирәк?**

Ару, ялыгу – гомуми симптомнар, аларны берьяклап кына карап булмый. Алар баланың нерв системасына көч килү нәтиҗәсендә килеп чыга. Сәбәбе дә төрле булырга мөмкин: көн режимы бозылу, саф һавада сирәк булу, тән температурасы югары булу, йокы туймау, бинада тавыш күп булу һәм башкалар... Һәр бала үзенчәлекле, шуңа күрә әлеге тотрыксызлыкны төрлечә кичерә. Бу сәбәпләрне кисәтеп, барысын да җайга салырга тырышыгыз, бала дөрес туклансын, күбрәк һава суласын, ял итсен. Күптән түгел кичергән вируслы яисә инфекцион йогышлы авырулар да үзен сиздерергә мөмкин: бала тиз арый, көйсезләнә, игътибар таләп итә. Бу очракта иммунитетны ныгытырга кирәк. Шулай ук мондый халәткә гемоглобинның түбән булуы, ашказаны-эчәк тракты авырулары да йогынты ясый. Йөрәк-кан тамыры системасы авыруларын да искәртми булмый. Төгәл сәбәбен ачыклар өчен гомуми кан анализы тапшырыгыз, ЭКГ, эхокардиография узыгыз, невропатологка, эндокринологка мөрәҗәгать итегез.

**? Улыбызга 11 яшь булгач кына йөрәгендә 2,5 миллиметрлы ачык овал тәрәзә (ООО – открытое овальное окно) барлыгы билгеле булды. Дүрт ел буе спорт белән шөгыльләнә, беркайчан да йөрәк авыртудан, арудан зарланганы юк. Мондый диагноз спорт белән шөгыльләнүгә киртә түгелме? Улыбызның гомеренә куркыныч тудырмыймы?**

Ачык овал тәрәзә – йөрәк үсешенең еш очрый торган кече аномалиясе. Гадәттә ул бала тугач беренче 3–6 сәгатьтә ябыла. Кайбер очракта процесс берничә елга сузыла, һәм шулай ук норма санала. Бүген 5% кеше шул үзенчәлек белән яши, ул патология дип саналмый. Спортка килгәндә, улыгызны кардиологта тикшертергә кирәк. Ярты ел саен тыныч килеш һәм физнагрузка белән ЭКГ ясарга, елга бер тапкыр йөрәккә УЗИ үтәргә киңәш ителә. Кардиологка күренеп торыгыз. Спортның никадәр интенсив булуын табиб билгеләргә тиеш. Бала зарланмаса, авыру симптомнары күзәтелмәсә, дәвалау да кирәкми. Йөрәк тибеше артса, башы әйләнсә, еш арыса, аңын җую очраклары булса, йөрәгендә тавыш барлыгы билгеле булса, кардиологка мөрәҗәгать итегез. Бала режимны сакласын, саф һавада йөрсен, дөрес туклансын. Физик нагрузкалар артык булса, ачык овал тәрәзә дә зураерга мөмкин. Табиб контроле шуның өчен кирәк. Экстремаль спорт төрләре, дайвинг белән шөгыльләнү дә киңәш ителми.

**Кадерле әниләр!**
**«Яшь әни» рубрикасына сездән сораулар кабул итәбез.**
**Җавап бирүче белгечләр: педиатр, гинеколог, стоматолог, невролог, хирург-ортопед, кардиолог, иммунолог-аллерголог, гастроэнтеролог, эндокринолог, офтальмолог һәм башкалар.**

**Балаларга кагылышлы сорауларыгызны – 8 (843) 2-22-09-77 телефоны аша, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт адресы буенча яисә ssuum@yandex.ru электрон адресына «Сорау–җавап» дип язып җибәрә аласыз.**

# СОРАУ—ҖАВАП



**Республика балалар клиник хастаханәсе педиатры Гөлнара ЗЫЯТДИНОВА җавап бирә**

**? Җәй көне балалар еш егыла. Сыдырылулардан, җәрәхәтләрдән саклап бетереп булмый. Хәзер күп әниләр, составында спирт бар дип, йод һәм яшел су (зелёнка) кулланмыйлар диярлек. Яраны нәрсә белән эшкәртергә кирәк?**

Беренче чиратта, кулыгызны юып, аларны йогышсызлый торган эремә белән эшкәртегез. Аннары яраны спиртсыз антисептик эремәсе белән чистартыгыз. Моның өчен кайнатылган салкын су яисә шешәле су да ярый. Йод йә яшел су ярдәмендә яраның кырыйларын эшкәртегез. Заманча препаратлардан антибактериаль порошок формасындагыларын куллансагыз була. Шулай ук тиз төзәтә торган мазьлар да ярдәм итәр.

**? Бала бөтенләй диярлек су эчми. Морслар, сокларны күбрәк ярата. Җәйге кызуда суны мәҗбүри эчертергә кирәкме? Судан кала, кайсы эчемлекләр кулайрак?**

Баланың төп эчемлеге, әлбәттә, су булырга тиеш. Җиләк-җимештән ясалган эчемлекләрне һәм сокларны чикләргә кирәк. Алар барысы да баланың яшенә карап кына рационга кертелергә тиеш. Сок, морс, компот арасыннан сайлаганда соңгы икесенә өстенлек бирегез. Чөнки сокларда тозлар һәм углеводлар күп. Балалар өчен махсус чәйләр дә бар, аларны да кулланып карагыз. Сау-сәламәт баланы мәҗбүриләп эчертмәгез, тәкъдим генә итегез.

**? Җәй көне температуралы бала белән һавада йөрергә ярыймы? Өйдә болай да бөркү, аңа һава җитми кебек.**


Баланың температурасы булганда һавада йөрүне кичектереп торыгыз. Хәле тотрыклылангач кына иртәнге йә кичке якта урамга алып чыксагыз була. Эчемлекләр күләмен арттырыгыз, һава торышын исәпкә алып, дөрес итеп киендерегез.



**Нәниләргә күчтәнәч! Телефон камерасын QR-кодка якынайтып, аудиоформатта язылган әкиятне балагызга тыңлатыгыз.**

Республика балалар клиник хастаханәсенең матбугат хезмәте җитәкчесе Зәһрә Гыйбадуллина ярдәме белән әзерләнде.

# ГЛЮТЕНСЫЗ ДИЕТА КЕМГӘ ФАЙДАЛЫ?



**Соңгы вакытта глютенсыз диеталар популярлаша башлады. Кибет киштәләреннән составында глютен булмаган азык-төлек эзләүчеләрне дә еш очратырга була. Шулай ук бар кешегә дә зарарлымы ул? Катгый диета тотарга да кирәкме? Шушы сораулар белән дөрес туклану белгече, нутрициолог Чулпан МӨСЛИХОВАга мөрәҗәгать иттек.**

**Нәрсә ул глютен?**

Бөртекле ашлык культураларында була торган үсемлек аксымы ул. Аның исе дә, төсе дә юк. Әмма сыеклык белән реакциягә кергәч, ябышучанга, сузылучанга әйләнә. Аны икенче төрле клейковина дип тә атыйлар. Глютен сүзе «глюта» дигән латин сүзеннән алынган. Клей дип тәрҗемә ителә. Ул бодайда, арышта, арпада күп. Борай, солы, булгурда да бар.

**Организмга ярамаганын нинди билгеләр буенча белергә мөмкин?**

Эч авырту, еш укшыту, газлар җыелу, эч кибү, эч китү, тән тиресе бозыла башлау, бик еш арынганлык хисе, баш, буыннар авырту, бармаклар ою, хәтер саегу, еш депрессиягә бирелү – бу билгеләр организмның глютенны кабул итмәвен күрсәтергә мөмкин. Табибка барырга вакытлары булмаучыларга ике атналык глютенсыз диета киңәш итәм. Бу билгеләр бетсә, димәк, сезгә глютен ярамый.

**Җилемчә (клейковина) онда гына түгел, йогурт ише ризыкларда да бар. Шуңа күрә глютенсыз диета тоту бик авыр һәм кыйммәтле, диләр. Килешәсезме?**

Әйе, кыйммәтрәк. Әмма организм глютенны кабул итми икән, аннан барлыкка килгән авыруларны дәвалау күпкә кыйммәтрәк. Шуңа күрә үз төбәгебездә үскән ризыклардан да витаминнарга бай, файдалы рацион төзергә мөмкин. Шул ук карабодай, тары ярмасы, ит, балык, үз бакчабызда үскән яшелчәләр, җиләк-җимешләр... Глютенсыз дигән язулар маркетинг алым буларак та кулланыла. Андый ризыклар кыйммәтрәк йөри.

**Глютенсыз тормыш модасы безгә кайдан килде, һәм ул дөреслеккә туры киләме?**

Чынлап та, дөрес тукланам, сәламәт яшәү рәвеше алып барам, глютен ашамыйм дип, трендта булырга теләүчеләр соңгы арада арта бара. Ул безгә Европадан керде. Ул анда дәвалану диетасы буларак кулланыла. Ә бездә аны көндәлек диета дип ялгыш кабул итәләр. Организм глютенга реакция бирми икән, мондый диета тотуның файдасы юк дип әйтер идем. Киренсенчә, B, E витаминнары җитмәскә мөмкин. Глютенлы ризыкларда алыштыргысыз аминокислоталар бар. Аларны безнең организм эшләп чыгара алмый. Шуңа күрә бу очракта алтын урталыкны табарга киңәш итәм.

**Глютенсыз ризыклар ашау ябыгуга китерә дигән сүзләр дөресме?**

Минемчә, бу – миф. Ябыгу процессы – ашаган калорийга караганда, кулланылган энергиясенең күбрәк булуы. Шул очракта гына ябыгып була. Глютенсыз диета ябыгу өчен диета түгел, ә дәвалау протоколы.

**Организмы кабул итмәгән кешеләрдә глютен яман шеш авырулары китереп чыгара, диләр. Бу фикер белән килешәсезме?**

Глютен эчәклеккә эләккәч, гади компонентларга таркалмый, шунда утырып кала. Киләчәктә ул яман шеш авыруларын китереп чыгарырга мөмкин. Кабатлап әйтәм: бу бары тик целиакия авыруы булган кешеләр өчен генә куркыныч.

**Глютен булган ризыкларны ашау кемнәргә зыянлы?**

Беренче чиратта, эчәклек белән бәйле целиакия диагнозы куелганнар өчен. Шулай ук ашкайнату системасында проблемалары, аутоиммунлы һәм аутизм авыруы булганнарга, тире авырулы кешеләргә зыянлы.

# БИТНЕ ЧӘБӘКЛӘП ЯШӘРТӘБЕЗ

**Биткә чәбәкләп массаж ясау, ягъни face-slapping Кореяда бик популяр. Хәзер ул безнең җирлектә дә кулланыла башлады. Мондый массаж крем тәэсирен, кан йөрешен яхшырта, бит тиресен тонуста тота һәм җыерчыклар чыгудан саклый. «Кремны бервакытта да ышкып сөртмәгез, – ди матурлык экспертыбыз – массажист Ләйсән САБИТОВА. – Тирене чистартканнан соң, берничә урынга крем тидерегез дә, битне чәбәкләгез. Болай итеп «ике куян койрыгын» берьюлы тотарсыз: крем да сөртелә, массаж да ясала. Моны бары гадәткә генә кертергә кирәк». Билгеле, мондый төр массажның да үз җае бар.**

- Биткә массаж ясый башлаганчы, гадәттәгечә, күкрәк читлегенең өске ягын җиңелчә генә каккалап чыгабыз. Бу лимфа әйләнешен «уятыр» өчен эшләнә. Монсыз массаж ясау файдасыз.
- Муенны да сыпырып алгач, кул аркасы белән ияк астын чәбәкли башлыйбыз.
- Аннан соң бармак очлары белән иякне, бит алмаларын чәбәклибез
- Борын, ирен тирәләрендә дә әкрен генә шул ук хәрәкәтне кабатлыйбыз. Гадәттә, массаж ясаганда иреннәр онытыла. Югыйсә аларга да кирәк ул. Иреннәр каралмаса, иртә картая башларга мөмкин. Җай гына иреннәрне чәбәкләү дә андагы кан йөрешен яхшырта.
- Борын канатлары турында да онытмагыз. Ике яклап имән бармак белән каккалагыз.
- Күз тирәләренә аеруча игътибарлы булыгыз. «Каз тәпие» чыккан урыннарда бармак очларын озаграк «тыпырдатыгыз». Күз тирәләрен массажлап чыгыгыз. Каш астын онытмагыз.
- Ике каш арасында тирән сыр салынучан. Профилактика өчен каш araларын ике бармак белән аерып, икенче кулның имән бармагы белән әкрен генә каккалагыз.
- Ике кул бармаклары белән маңгайны чәбәкләгәннән соң, тагын бер кат бит буйлап узыгыз.
- Мондый төр массаждан соң битегез яна башлар, кызарыр. Димәк, кан ныграк йөри башлый. Эффектны әнә шул бирә дә инде.



QR-код аша кереп, массажны видеодан да карап ясый аласыз.
Фото һәм видео: Анна Арахамия.

# Курник

«Аш-су» сәхифәсенең бүгенге кунагы Эльмира КАМАЛИЕВА – Арча районы Мәмсә авылы кызы. Һөнәре буенча шәфкать туташы ул, ире Азат белән Сәйдә, Нурислам, Динислам исемле бер кыз, ике малай үстерәләр. Эльмира – блогер, социаль челтәрдәге сәхифәсендә берсеннән-берсе тәмлерәк рецептлары белән уртаклаша. Аш-суга осталык – Надирә әбисеннән. Иртәнге дүрттә тимерче алачыгына эшкә китүче иренә кайнар өчпочмаклар тыгып озата торган булган ул. Күз тимәсен, оныгына да әбисенең уңганлыгы күчкән. Шулай булмаса, көненә әллә ничә торт пешерер идеме? «Аена сиксән торт пешергән чакларым бар. Иң зур тортым – биш катлы, 28 кило авырлыкта иде», – дип шаккаттыра Эльмира. Аш-су серләре белән бала ялына чыккач кызыксына башлаган ул. Кайнанасы Мәүҗидә ападан да күп нәрсәгә өйрәнгән. «Көн саен үзем өчен нинди дә булса берәр яңалык ачам. Социаль челтәрләрдән мине карап барган дусларым да кызыклы рецептларын яза. Журнал укучылар белән бүлешәсем килгән менә бу рецептны да Резеда ападан отып алдым. Карап торышка гади генә тоелса да, искиткеч тәмле ул. Өйдәгеләргә дә бик ошады. Балалар яратса, димәк, чынлап та тәмле», – ди уңган хуҗабикә.





**Кирәк** (камыр өчен) / 300 г сөт / 1 йомырка / 100 г үсемлек мае / 1 аш кашыгы тулыр-тулмас шикәр комы / 1 чәй кашыгы тоз / 8 г коры чүпрә / кирәгенчә он.

**Эчлек өчен** 400 г сөяксез тавык ите (бот итеннән сусылрак була) / 4 йомырка / 200 г каты сыр / 200 г атланмай / тәменчә тоз.

**Эш барышы**

- Сөтне җылытып, шикәр комы белән чүпрә салып, туглыйбыз. Өстен каплап, 15 минутлап күпертәбез.
- 1 йомырка, сыек май, тоз, он салып, камыр басабыз. Онны берьюлы күп итеп салмагыз, азлап-азлап кына өсти барыгыз. Камыр йомшак булырга тиеш. Аны куна тактасына төшереп, озаклап басабыз. Камыр уңсын өчен, 15 минутлап басарга кирәк. Басып бетергәч, өстен тастымал белән каплап, сәгать ярым күпертәбез.
- Итне өчпочмакка тураган шикелле шакмаклап турыйбыз. Каты итеп пешкән йомырканы шулай ук ваклыйбыз. Сырны эре угычтан уабыз. Барысын бергә кушып, тәменчә тоз сибәбез.
- Камырны 40–45 граммлы кечкенә шарларга бүләбез. Һәр шарчыкны чынаяк тәлинкәсе кадәр итеп җәябез.
- Җәем уртасына ике аш кашыгы эчлекне салып, җиңелчә генә тигезлибез. Эчлек өстенә берәр чәй кашыгы йомшарган атланмай куябыз.
- Камырның ике читен чираттан күтәреп бөреп, сумсалар ясыйбыз. QR-код белән тәкъдим ителгән видеода бу алымны күрергә мөмкин.
- Сумсаларны төбе майланган табага тезәбез. 1 йомырка сарысына 1 аш кашыгы сөт кушып туглап, сумсаларның өстенә ягабыз.
- Курникны 220 градуска кадәр кызган мичтә 35–45 минут пешерәбез.

Ашларыгыз тәмле, җәйләрегез ямьле булсын!



















Видеоны карар өчен смартфонның камерасын QR-кодка якынайтыгыз.
Фото һәм видео: Анна Арахамия.





# Өйнең яме – гөлләрдә



*Бүлмә розасы*

Бүлмә розасы нәзберек гөл, аны өй шартларында үстерүе җайлы түгел. Урынның иркен булганын ярата, яктылыкка таләпчән. Көньякка караган тәрәзә төпләрендә үзен бик яхшы хис итә, шулай да көндезге челләдән бераз күләгәләргә кирәк. Кышын аны җылылык торбаларыннан ераграк тотыгыз. Көнкүреш техникасыннан бөркелгән электромагнитлы нурланышны да авыр кичерә ул. Җәй көне розаларны якты веранда яки балконга, террасага чыгарырга мөмкин. Җылылык 20–27 градус булганда яхшы үсә. Һаваның алмашынып торганын яратса да, ачык тәрәзә яки форточкадан искән җил аның өчен зарарлы. Җәйге якта туфрагының өске ягы кипшерү белән сугаруны таләп итә. Ләкин туфракны артык юешләргә дә ярамый. Актив үскән чорында өстеннән су бөркегәнне ярата. Коры һавадан яфрак очлары көеп, чәчәк бөреләре коела башлый. Чәчәк бөреләре формалашканда гөл тукландыруга мохтаҗ. Кибеттән розалар өчен махсус ашлама таба алсагыз, бик яхшы. Андый комплекслы ашламалар белән розаларны чәчәк атып бетергәнче һәр атна саен тукландыралар. Яңа туфракка күчереп утыртканнан соң ике ай дәвамында һәм кыш көне ашлауны туктатып торалар. Яшь куакларны – гадәттә ел саен, картларын ике-өч елга бер күчереп утырталар. Розалар өчен калын стеналы балчык чүлмәкләр кулайрак, чөнки бу гөл туфракның артык җылынуын авыр кичерә. Кышкы тынлык чорына кергәндә гөлнең корыган, чирле ботакларын кисәләр. Ул кыш көне температура +6, +8 градус булган салкынча урында ял итәргә тиеш, шул чагында гына яз көне шау чәчәккә күмеләчәк. Февраль урталарында – актив үсеш алдыннан розаны формалаштырып кисәләр, ботак очларын тигезлиләр, карт ботакларыннан аралыйлар.



Башка гөлләр үстерү турында да укыгыз.

Фуксиянең телебездә бик матур атамасы бар – тамчы гөл. Ул салкынча һавада яхшырак үсә. Җәен температура 20 градус җылы, ә кышын 15 градус булса яхшы. Кояш нурларының да иртәнге якта гына караганын ярата, шунлыктан көнчыгышка яки төньякка караган тәрәзә төпләре аңа кулайрак, күләгәне җиңел кичерә. Җәен өйдә бик эссе булса, тамчы гөлне балконга, терраса, верандага чыгарып торырга мөмкин. Суны даими һәм мул итеп сибүне таләп итә. Ләкин туфрагы юешләнеп утырырлык булмасын. Көзен су сибүне киметеп, кыш көне аена бер яки ике тапкыр гына сугаралар. Фуксия туфракның артык җылынганын өнәми, шуның өчен чүлмәкнең калын стеналысын, ә иң яхшысы – балчыктан эшләнгәнен сайлагыз. Җәй көне әледәнәле өстеннән су бөркеп, сафландырып торырга да кирәк. Өй шартларында үскән фуксия комплекслы ашлама белән тукландырып торуга мохтаҗ. Кагыйдә буларак, бу ашламаларда азот бик аз микъдарда була. Кышын исә тукландыру туктатыла. Фуксияне ел саен яңа туфракка күчереп утырталар. Бу эш яз көне башкарыла. Елга ике тапкыр – көзен һәм кыш көне – гыйнвар башында тамчы гөлне кыскартып кисәләр. Беренче тапкыр кискәндә чәчәк атып бетергән тармакларны бөреләрдән 2 сантиметр өстәнрәк кыскарталар. Кышын исә куак формалаштырып киселә. Өй шартларында тамчы гөлне яшь тармакларны тамырландырып үрчетү отышлырак. Моны елның теләсә кайсы фасылында эшләргә була. Тамырландырасы ботакларның озынлыгы 10–20 сантиметрдан артмасын.



*Фуксия*



*Бромелия*

Бромелия. Бу гөлнең алтмышлап төре бар. Бромелия яктылыкны һәм һаваны гел җилләтеп торганны ярата. Шул ук вакытта туры караган кояш нурларын, уталы җилләрне өнәми. Аны көнчыгыш тәрәзә төбендә үстерү отышлырак. Кыш көне өстәмә яктыртуга мохтаҗ. Бромелия һава температурасының 20–25 градус җылы булганын ярата. Кыш көне җылылык 15–18 градус чамасы булса әйбәт. Суны даими сибүне таләп итә, эссе көннәрдә көн саен сугарырга туры киләчәк. Суны яфраклардан хасил булган бүрәнкәгә салалар. Кышын атнага бер тапкыр сугару да җитә. Ләкин су йомшак булырга тиеш. Бромелия һаваның дымлылыгы 70 процenttан ким булмаганда гына яхшы үсә. Шуңа күрә яфракларына әледән-әле су бөркеп, дымландырып торалар. Җәйге-язгы якта 15–20 көнгә бер тапкыр комплекслы ашламалар белән тукландыру таләп ителә. Кышын исә ашлауны ай ярымга бер генә калдыралар. Гадәттә, бромелия җәй көне чәчәк ата. Аны тизләтүнең бер хәйләсе бар: гөл чүлмәге янына берничә алма куеп, барысын бергә полиэтилен белән каплап торырга кирәк. Бромелиянең чәчәкләре карап хозурланырлык түгел, ә менә чәчәк яны яфраклары искиткеч купшылар. Чәчәк атып бетереп, тәмам корыганнан соң чәчәк аткан розетканы кисеп алырга була, ул инде башкача чәчәк атмый. Бу гөлне сирәк, тамырлары савытына сыймый башлагач кына күчереп утырталар. Моны гөлнең интенсив үскән вакытында башкару яхшы. Бромелия агач яки балчык чүлмәкләрдә матуррак күренә. Аны розетка төбеннән үсеп чыккан ян тармаклардан үрчетәләр. Утырту өчен яхшы вакыт февральдән алып апрельгә кадәрге ара. Яңа үсентеләрне кечкенә чүлмәкләргә утыртып, суны чамалап кына сибәләр. Ике айдан ул тамыр җибәрә. Беренче чәчәген ике елдан соң гына көтәргә була әле.

Фото: ru.freepik.com

## тест: сез игътибарлымы?

**Дөньяда бик тә игътибарлы, бернәрсәне дә күз уңыннан ычкындырмый торган кешеләр була. Андыйлар барысыннан да хәбәрдар, кыен хәлләргә сирәк тарыйлар. Таркау, игътибарсыз кешеләр – аларның киресе. Гадәти генә хәлләрдә дә болар югалып калучан. Ә сез үзегез нинди кеше, әйдәгез, тикшереп карыйк! Сорауларга «әйе» һәм «юк» дип җавап бирегез.**

**1.** Үзегезнең игътибарсызлыгыгыз аркасында еш оттырасызмы?
**2.** Дусларыгыз яки танышларыгыз сезне шаяртып кына алдый аламы?
**3.** Сез бер үк вакытта ниндидер эш белән дә шөгыльләнеп, тирәягыгыздагыларның нәрсә сөйләшкәннәрен дә тыңлый аласызмы?
**4.** Урамда акча яки ачкычлар тапканыгыз бармы?
**5.** Юл аша чыкканда як-якка игътибар белән карыйсызмы?
**6.** Ике көн элек караган фильмны вак-төяк детальләре белән искә төшерә аласызмы?
**7.** Кемдер сезне китап яки газета укуыгыздан, телевизор каравыгыздан бүлсә, ачуыгыз киләме?
**8.** Кибеттә сатучы кайтарып биргән акчаны касса янында ук тикшерәсезме?
**9.** Өегездә үзегезгә кирәкле әйберне тиз табасызмы?
**10.** Урамда барганда кинәт кенә кемдер эндәшсә, сискәнеп китәсезме?
**11.** Бер кешене икенчесе белән бутаган очраклар булгалыймы?
**12.** Берәрсе белән сөйләшеп барып, үз тукталышыгызны үтеп киткәнегез бармы?
**13.** Якыннарыгызның туган көннәрен тиз генә әйтеп бирә аласызмы;
**14.** Йокыдан җиңел торасызмы?
**15.** Бер тапкыр булган шәһәрдә башкалар ярдәменнән башка гына үзегезгә кирәкле урынны таба аласызмы?

**Әгәр дә 2, 3, 4, 5, 6, 8, 9, 13, 14, 15 нче сорауларга «әйе» дип, 1, 7, 10, 11, 12 нче сорауларга «юк» дип җавап бирсәгез, һәр җавап өчен 1 балл куегыз.**

**11 балл һәм аннан күбрәк.** Сез бик игътибарлы һәм сизгер кеше. Мондый хәтер һәм мондый игътибарлылык сирәк очрый.

**5 тән алып 10 баллга кадәр.** Сез шактый ук игътибарлы, кирәклесен онытмыйсыз. Ләкин шулай да ара-тирә игътибарыгыз җитеп бетмәве аркасында кыенлык та кичерәсез. Мондый гына таркаулык куркыныч түгел, аның каравы, сез кирәк вакытта бик игътибарлы була беләсез.

**4 балл һәм аннан да кимрәк.** Дөресен әйтик, сез – таркау кеше. Тормышыгыздагы күп кенә кыенлыкларның сәбәбе – әнә шул. Сезнең игътибарсызлыктан якыннарыгыз да интегә. Алып торган китабыгызны хуҗасына вакытында кайтарырга, чыгып киткәндә утны сүндерергә еш кына онытасыз. Игътибарны арттыра торган махсус күнекмәләр бар, шулар белән кызыксынсагыз, бу кимчелектән берникадәр арына алырсыз.

## йолдызнамә август

***Кучкар.*** Ай башында ук яңа эшләргә гайрәтләндерүче уңай энергия ташкынын тоярсыз. Вакыйгалар үзәгендә булу теләгегез көчле, амбицияләрегез югары. Бу вакытны тиешенчә файдаланып калырга тырышыгыз.

***Үгезбозау.*** Айның беренче яртысы тыныч кына узар, ә менә калган яртысы шактый ыгы-зыгылы булырга охшаган. Акча белән бәйле кыенлыклар килеп чыгарга мөмкин, артык чыгымнардан тыелып торыгыз.

***Игезәкләр.*** Сәфәргә чыгу, яңа кешеләр белән танышу ихтималы зур. Мондый танышулар сезнең өчен яңа мөмкинлекләр ача. Шуның нәтиҗәсе буларак, хезмәт өлкәсендә уңай үзгәрешләр көтелә.

***Кысла.*** Көчегез артуын үзегез үк сизәрсез. Эш потенциалыгыз бик югары, авыр, катлаулы мәсьәләләр чишүне шушы вакытка планлаштырсагыз, отарсыз. Ләкин акча белән бәйле эшләрдә сак булыгыз.

***Арыслан.*** Уңыш үкчәгезгә бастырып килә. Элеккеге танышларыгызның ярдәмен тоярсыз. Алдыгызда көтелмәгән перспективалар ачылыр, финанс ягыгыз җайланыр. Бу ай сезнең өчен алгарыш чоры.

***Сөмбелә.*** Көчегезнең бераз кимеп китүен тоярсыз. Шулай да айны уңышсыз дип әйтеп булмый, бигрәк тә иҗади эш белән шөгыльләнүчеләр өчен. Мөһим һәм катлаулы эшләргә хәзер алынсагыз яхшырак.

***Бизмән.*** Кәефегез шәп, егәрегез дүрт кешегә бүлеп бирердәй. Эшлекле килешүләр, киләчәккә планнар кору өчен моннан да яхшырак вакытны табуыгыз икеле. Мөмкинлекне кулдан ычкындырмагыз.

***Чаян.*** Үз позицияләрегезне ныгыту өчен тырышырга туры килер. Оригиналь идеяләр белән рухланырсыз, ләкин башта финанс якны уйлап бетерегез, бу чорда әлеге мәсьәлә бераз кискенрәк торырга охшаган.

***Укчы.*** Хезмәт өлкәсендә зур нәтиҗәләр күрсәтерсез, абруегыз артыр. Эшлекле сәфәр көтелә. Аеруча игътибарлы булу сорала, бигрәк тә җитәкче урыннарда эшләүчеләргә. Яңа эш башлау өчен кулай чор.

***Кәҗәмөгез.*** Язмыш сезгә хәерхаһлы, планнарыгызны тормышка ашырыр өчен җае чыгып кына торыр. Бу айда кешеләр белән килешү, үзара хезмәттәшлек итүнең нәтиҗәсе уңышлы булачак.

***Сукояр.*** Уңышлы, энергияле, эшлекле ай. Моңарчы алынырга курыккан эшләрне дә җиңел генә башкарып чыгарсыз. Карьера үсешен кайгыртучыларга уңыш елмаер. Сезнең өчен бәхет капкалары ачык чор.

***Балыклар.*** Күңелегез яңа үрләргә әйдәр. Нәтиҗәсе дә озак көттермәс – көтелмәгән җирдән керем алырсыз. Ай сезнең өчен бераз ыгы-зыгылы булырга мөмкин, юк-барга игътибар итмәскә тырышыгыз.

«Хатын-кыз галәме» сәхифәсен Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА, Лилия ГӘРӘЕВА, Алсу ШАКИРОВА әзерләде.







# ИЛДАРНЫҢ СӘНГАТЬ ДӨНЬЯСЫ

Рәссам Илдар Гыйльманов 1970 елның 1 сентябрендә Уфада туган. «Балачактан ук иҗатка омтылып, сынлы сәнгать мәктәбенә йөрдем, соңрак Башкортстанның «Агыйдел» промыселы каршында миниатюра ясау сәнгатенә өйрәндем.
М. Акмулла исемендәге Башкортстан дәүләт педагогика институтын тәмамлагач, 1997 елдан алып 2018 елга кадәр әлеге институтның сынлы сәнгать-графика факультетында укытучы булып эшләдем», – дип сөйли үзе турында рәссам. Укытучы эше күп вакыт таләп итсә дә, барлыгы 600 гә якын картина язган, 151 гомуми күргәзмәдә катнашкан һәм 19 шәхси күргәзмәсен ачкан талантлы тырыш иҗатчы ул Илдар!

Бүгенге көндә аның әсәрләре М. В. Нестеров исемендәге Башкортстан дәүләт сынлы сәнгать музеенда, Башкортстанның милли әдәбият музеенда, Татарстан дәүләт сынлы сәнгать музеенда, Мәрҗани фондында (Мәскәү), Томск өлкәсе сынлы сәнгать музеенда, Чаллы шәһәре галереясында, Алабуга дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы тупланмаларында, шулай ук ТЮРКСОЙ һәм GAU – Американың Гирне университеты сәнгать тупланмаларында саклана. Рәссамның эшләре, Россиядән кала, Германиядә, Италиядә, Төркиядә, Төньяк Кипрның Төрек Республикасында да бар. Ул әлеге илләрдә һәм Алабугада узган Халыкара иҗади лабораторияләрдә катнаша. Күп кенә бәйгеләрдә дә җиңеп чыга.

Илдар Рәшит улы пейзаж жанрына өстенлек биреп, табигать күренешләрен яратып тасвирлый. Аның Болгар, Башкортстан табигате һәм аеруча Чиләбе өлкәсе Миньяр бистәсендәге хозурлы ландшафт сурәтләнгән картиналарын гади тамашачылар гына түгел, оста рәссамнар да югары бәяли. «Әлеге картиналарда без бик сусыл төсләр, җете һәм шул ук вакытта үзара камиллектәге төсмерләр күрәбез!» – дип ихлас соклана алар. Илдар Гыйльмановның әлеге әсәрләре ничек язарга кирәклекнең чын үрнәкләре дип санылйлар. Рәссам исә үзенең илһамлы иҗаты, уңышлары өчен хәләл җефете Ләйсәнгә рәхмәтле. Алар бер ул үстерә. Талантлы педагог Ләйсән Гыйльманова шулай ук иҗат кешесе, киездән сәнгать әсәрләре ясау остасы, декоратив-гамәли сәнгать буенча Бөтенроссия һәм Халыкара бәйгеләр лауреаты.




Илдар Гыйльманов иҗатында «Атлар», «Вакыт – мохит», «Бояр гөлләре», «Ирәмәл» серияләре бар. Соңгы елларда ул төп игътибарын классик ысулдагы татар шәмаилләрен язуга юнәлтеп, пыялага шәмаилләр язу техникасын камилләштерә бара.

«Рәссам булырга укучылар гаять күп, әмма чын рәссамнар бик аз. Рәссам ничек итеп язса чын уңышка ирешә ала?» – дип кызыксынуыма каршы, абруйлы иҗатчы ярым шаяртып, ярым җитди итеп җаваплады: «Күп язарга, бүгенге көн символларын тупларга, формаларның шартлы-яссылыклы яисә күләмле чишелешләренә омтылырга, композицияне тигезләргә, мохит-фон төзегәндә төсле тапларның ритмлы алмашынуына, төсләр белән иркле эшләргә, колорит төзегәндә исә киң диапазон кулланырга, төс тапларын күләм һәм конфигурация буенча дөрес тоемларга өйрәнергә генә кирәк... Гомумән, рәссамлык сәләте тумыштан булырга тиеш».

Илдар Рәшит улының әсәрләре Татарстан тамашачысына яхшы таныш. Казан Кремлендә дә шәхси күргәзмәсен ачып, күпләрне шатландырды инде ул.

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА



ИЛДАР ГЫЙЛЬМАНОВ

12+




# «КИТАП» ТЫҢЛА!




АО «ТАТМЕДИА» Адрес: 420066, г. Казань, ул. Декабристов, д. 2 ГРН 1071690057834

РЕКЛАМА

